# Казан утлары

ДЕКАБРЬ № 12 1965

# Казан утлары

**АЙЛЫҚ ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ**

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*ҚЫРЫҚ ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

ДЕКАБРЬ **12**

РЕСПУБЛИКА ГАЗЕТА ҺӘМ ҖУРНАЛЛАРЫ НӘШРИЯТЫ
КАЗАН 1965

## Бу санда:


**Г. Тукай исемендәге премияләр турында КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы карары.** . 3

### ШИГЫРЬЛӘР, ДРАМА, ХИКӘЯЛӘР

С. Хәким. **Лирика.** . . . . . . . . 4
Н. Фәттах. **Артта калган юллар.** Хикәя . . . . . . . . 12
Яшь шагыйрьләр тавышы. . . . . . . . . 54
Г. Мөхәммәтшин. **Авылда бер...** Хикәя. . . . . . . . 62
Л. Топчий. Шигырьләр. . . . . . . . . 70
Ф. Хөсни. **Бертуган Таһировлар.** Драма. . . . . . . . 72

### ОЧЕРКЛАР

Д. Сирай. **Төрле язмышлар** . . . . . . . . 110

### ДАНТЕНЫҢ ТУУЫНА 700 ЕЛ

Данте. **Илаһи комедия.** Өзекләр. . . . . . . . 121

### СӘНГАТЬ

Ф. Вәлиев. **Казан татарларының ювелирлык сәнгате.** . . . . 125

### Г. ИДЕЛЛЕГӘ 60 ЯШЬ

Г. Минский. **Алтмышны каршылаганда.** . . . . . . . 129

### КИТАП КҮЗӘТҮ

А. Сайганов. **Татар совет әдәбияты тарихы рус телендә.** . . 132
Г. Ахунов. **«Хәсрәт дәрьясы»ның татарчасы һәм тәрҗемә практикабыз турында.** . . . . . . . . 135
А. Яхин. **Начар әсәр ничек дөньяга килә.** . . . . . . . 140

### М. ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛАП

М. Фәйзуллина. **Ул ярдәмчел кеше иде.** . . . . . . . 146

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . 148

«Казан утлары»нда 1965 елда басылган әсәрләр исемлеге. . . . . . . . . 153


***Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.***


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 52. Редакция «Казан утлары».*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘР ТУРЫНДА КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ ҺӘМ ТАССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ

КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы партиянең XXII съезды, КПСС Үзәк Комитетының Октябрь һәм аннан соңгы Пленумнары карарлары иҗади фикер өчен зур киңлекләр ачканлыгын, әдәбият һәм сәнгать үсеше өчен бай мөмкинлекләр тудырганлыгын билгеләп үтәләр.

Соңгы елларда республика язучыларының, композиторларының, художникларының һәм театр работникларының иҗади эшчәнлеге шактый активлашты. Алар идея ягыннан өлгергән һәм художество ягыннан җитлеккән күп кенә әдәби, музыкаль, сынлы сәнгать һәм сәхнә әсәрләре тудырдылар. Хезмәт ияләре массаларының әдәбият һәм сәнгать белән кызыксынуы шактый артты, аларның рухи ихтыяҗлары киңәйде. Художество интеллигенциясенә һаман саен югарырак таләпләр куела бара.

1966 елның апрелендә татар әдәбиятына нигез салган Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулу уңае белән һәм әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә киләчәктә иҗади активлыкны тагын да күтәрү, аларда халыкчанлык һәм партиялелек, революцион гуманизм, совет патриотизмы һәм интернационализм принципларын һәрьяклап үстерү максаты белән КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы

### КАРАР БИРӘЛӘР:

1. Идея эчтәлеге һәм художество дәрәҗәсе аеруча әһәмиятле булган әдәбият, музыка, сынлы сәнгать әсәрләре һәм иң яхшы башкару эшчәнлеге өчен һәркайсы 1000 сум күләмендә Габдулла Тукай исемендәге ике республика премиясе билгеләргә.

2. Габдулла Тукай исемендәге премияләр 1966 елдан башлап, республика премияләре Комитеты карары буенча, Габдулла Тукай туган көндә һәр елны бирелә.

3. Габдулла Тукай исемендәге премияләргә кандидатлар күрсәтү хокукын Татарстан культура министрлыгына, иҗади союзлар идарәләренә, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегенә, Татарстан китап нәшриятына һәм җәмәгать оешмаларына бирергә. Премияләрне бирүгә ике ай кала, күрсәтелгән кандидатларның исемнәрен һәм хезмәтләрен, киң итеп тикшерү өчен, матбугатта яктыртырга.

4. Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре Комитетын расларга.

Казан, 11 октябрь, 1965 ел.

*Сибгат Хәким*

# *Лирика*

● ● ●

Урләреңне менгәч, туган ягым,
Рәшәң белән битем юдың син,
Һәрвакытта бергә уртаклаштың,
Уртаклаштың барын-югын син.

Үрләреңне менгәч, туган ягым,
Җилфердәде яшел кулмәгем...
Ни өчендер башка төштә түгел,
Үрләреңдә яшем түгәмен...

Үрләреңне менгәч, туган ягым,
Әкрен дәшеп, мине туктаттың...
Бар җылысын тоеп ятармын күк
Үлгәч тә мин синең туфракның.

● ● ●

Коенып үскән су буе.
Шылт та итми як-якта...
Яшәргә риза мин монда
Әйләнеп бер яфракка.

● ● ●

Әбиләрнең иске сандыгында
Намазлык һәм яңа уган кер...
Анда тарих, анда бер почмакта
Тукай үзе ята, «Туган тел».

● ● ●

Син мал дисең, миңа малың нигә,
Бер кырыйга әнә өй барын...
Иманлының йолдызлары якты,
Сынмасын тик шул нык иманың...

● ● ●

Җыр язмышы кош язмышы кебек,
Бер тирәдән үтә юллары;
Җыр да кайчак егылып төшә җиргә,
Күтәрелә кайчак югары...

● ● ●

Упкәләгән, үз күршесен тирги карчык:
Безнең йортның алды ачык, арты ачык,
Ләкин минем намусымның капкасы бар,
Туры булсаң, шул капкадан йөре, бар,
чык...

● ● ●

Көтүчеләр тапкан чишмә кебек,
Җырым минем, син дә улаксыз.
Шул чишмә күк син дә тыныч актың,
Шул чишмә күк син дә гөнаһсыз.

● ● ●

Язгы офык, карыйм, бар да зәңгәр,
Күзгә димен нәрсә иярсен?
Мин көтәмен, хәзер күренер димен
Җир юлдашы — берәр иярчен...

Мин аларга күнегеп беттем инде,
Ялганыннан хәзер чыннар күп.
Дугалы ат килеп чыгар төсле,
Җиз кыңгырау кинәт чыңлар күк.

● ● ●

Бала чакта әнкәй белән икәү
Ерак кырда урак урганда,
Лев Толстой кебек картны күреп,
Керми идем куркып урманга.

Хәзер дә мин барып чыгам, урман
Элеккечә шаулый, тавышлый,
Ул мәһабәт, ләкин нидер җитми,
Җитми төсле нәкъ шул «Толстой».

## Көтүчеләр

Көтүчеләр... Дөнья көтүчеләр...
Кырда алар яздан көзгәчә...
Чоры башка... нинди көтүче син
Хыялларың өстә йөзмәсә...

Көтүчеләр кырда... Аларга да
Өстәмә бер яңа эш чыкты:
Көне буе көтүеңне кара,
Күзәт җирне, күзәт бушлыкны.

Кайтыр вакыт җитә, күзәтәләр:
Кайсы сыер алдан юл башлар?
Кайта көтү, көтүләргә безнең
...рсәтеп оча «юлдашлар».

● ● ●

Йөрдем белгән таныш урманымда,
Ышанычлы, сине ул саклар...
Шул ук урман, шул ук тынлык дисең...
Тик усаклар, ләкин усаклар...

Имәннәре... имәннәр дә шул ук,
Шатлыгыннан сине кочаклар...
Шул ук кош-корт, җәнлекләре дә шул,
Тик усаклар, ләкин усаклар...

Бүтәннәргә ияргән дә киткән
Монда үскән ап-ак шомыртлар,
Алар күптән загс залларында...
Эх, шул яшьлек, сүнмәс шул утлар...

● ● ●

Кич. Идел... Пароход ашыкмый,
Мичкәләр, капчыклар өйгәннәр...
Кемнәрдер су керә... юк, алар
Кайчандыр без кискән имәннәр...

Бер полк атлылар йөзә күк,
Әйтерсең командир — читтә төп...
Пароход шикләнә, борыла,
Үтәбез тын гына читләтеп...

Артымда кычкырган тавышлар...
Аларны төпкә мин батырган...
Кич, Идел... Калкалар әкренләп,
Калкалар тирәннән батырлар...

● ● ●

Наполеонны куган, өенә
Кайткан солдат, күнел шат та соң...
Кайткан исән, тирәк утырткан:
Йортын аның уттан сакласын.

Солдат — вафат... Тирәк — картайган,
Каныгалар аңа яшеннәр...
Тирәк тирәсендә солдатның
Оныклары инде яшиләр.

Олыларда курку, борчылу;
Үгетләп тә кара, тиргәп тә,
Үч иткәндәй яшен вакытында
Бала-чага җыела тирәккә.

Куышына аның керәләр,
Коя яңгыр, тирәк чылана.
Юк, чыкмыйлар, шунда тирәкне
Әйләндерсен давыл чырага.

## Елганың борылган төшендә...

*Г. Халитка.*

Елганың борылган төшендә,
Бик хәтәр төшендә елганың
Тал тора, таза бер тал тора,
Еламый, көтмә син елавын...

Ташыган язгы су, бозлары
Шул талга бәрелгән, сугылган,
Зур бозлар кысканнар — иңрәгән,
Кайчакта җиргәчә сыгылган.

Җилкәсе суелган, күп түзгән
Калын, киң җилкәсе яралы,
Яшәгән шушында, үстергән
Шушы җир һәм шушы яр аны.

Тамырда төрле чүп, тамырлар
Ачылган, яфракка ярлы ул...
Күпме ел бер үзе саклаган,
Саклаган куркыныч ярны ул.

Елганың борылган төшендә,
Тугайда чәчәкләр — сабыйлар
Ишәя яз саен, тик талга
Нигәдер бер күз дә салмыйлар.

## Кыргый

Авылдан читтә алмагач
Үсә ялгыз, кыргый ул...
Язны да каршылый ялгыз,
Чәчәк ата, кормый ул.

Буранда чаңгычы яшь кыз
Калган кебек адашып,
Туңмасын, чакыр авылга,
Коткар үзен, ал дәшеп...

Төскә дә урта, уртача,
Буйга артык үсми ул...
Ялынам безгә күчәргә,
Ялынсам да күчми ул.

Авылда күп алар, бик күп,
Тарта ләкин кыр мине,
Үзем дә белмим ни өчен
Яратам шул «кыргый»ны.

## «Крестьян йөрәге»

„Крестьян йөрәге» дип аны
Атаганнар, күптән аталган...
Борчулы кыр... хәсрәт кенә анда...
Ишеткәнем шулар атамнан...

Анда кемдер ятып елаган, ди,
Аты үлгәч, атын, йөгәнен
Камытлары белән бергә күмгән,
Күмгән, диләр, үзенең йөрәген.

Ул калку кыр һаман сулап тора,
Мин тыңларга аны кызыгам...
Карабодай чәчәкләре көйгән
Күкрәгеннән типкән кызудан...

Анда тагын кемнәр еламаган...
Икмәгеңнең юкмы артыгы?
Эш эзләп тә... күбрәк сугышларга
Киткәннәр шул йөрәк аркылы...

Ул һәрвакыт калкып, сулап тора,
Беләм аны кече яшемнән...
«Крестьян йөрәге»ндә уйный,
Җәй буена уйный яшеннәр.

Җил дә ярган, су да ярган аны,
Үткән-сүткән каты бәрелгән...
Миңа газиз, мин бит өзелеп төшкән
Шул йөрәктән, шул бер бәгырьдән.

## Бер тауда ун чишмә...

Бер тауда ун чишмә,
Унысы ун төстә,
Югыйсә бер үк тау,
Югыйсә бер үк җир,
юлы бер...

Бер тауда ун чишмә,
Тынмыйлар бер кич тә,
Чәчәкле җәй әле,
Атлы һәм җәяүле
юлыгыр...

Бер тауда ун чишмә,
Унысы ун төстә:
Берсе тиз болгана,
Берсе тиз моңлана,
ком-ташта...

Бер тауда ун чишмә,
Юлларын син кисмә,
Агышы ун төрле,
Тавышы ун төрле,
мон башка.

Бер тауда ун чишмә,
Ун яшь кыз — ун төштә,
Сөйләшеп туймыйлар,
Туй диләр, туй диләр
чибәрләр...

Бер тауда ун чишмә,
Серенне син чишмә,
Серенне чибәрләр
Дөньяга сибәрләр,
сибәрләр...

●●●

Тәрәзәләр ачып бер сызгырдым,
Чапкан печәннәрем кипсен дип,
Пакусларым буйлап сагышларым
Сезнен якка таба китсен дип.

Тәрәзәләр ачып бер сызгырдым,
Сагышымнан җилләр кунсын дип,
Тал бөгелгән саен искә төшер,
Минем кебек син дә юксын дип.

## Әптери

Ул чабата ясап көн үткәрде,
Һөнәре шул, һөнәр ярата...
Мич башында, сәкедә һәм чөйдә,
Аягында анын чабата.

Кешеләргә тугызлыдан үрде,
Үзе өчен ярар җиделе.
Кулы җинел, чабатасы җинел,
Ә тормышнын кайда җинеле?

Җырладылар кызлар: Әптеринен
Өе тулы юкә-курыпса.
Без чабата киеп йөрмәс идек
Әптерине әгәр җир упса...

Базар көнне җиде баласын ул
Уятырга кыймый аптырый...
Бер рәт итеп, балаларын тезеп,
Чабаталар сата Әптери.

Акчасына бөтен күмәч алыр,
Базар аны әллә күрмәсме,
Сынап карар, таралырмы токым:
Тәгәрәтер чаттан күмәчне.

Яшел чирәм буйлап очар күмәч,
Очар күмәч җирдән туп кебек.
Үзе дә тук, өе дә тук гүя,
Бөтен дөнья аңа тук кебек...

Шатлыгыннан тавышы урам ярыр,
Балалары чибәр, көләчләр,
Балалары аның әйтерсең лә
Мичтән генә чыккан күмәчләр.

Болай гына яздым, сүз булсын дип,
Базардан соң сөйләп куярлык.
Балалары... Әптери соң үзе
Үлгәч хәтта сөяп куярлык.

● ● ●

Әй, мәктәбем, очкан оям минем,
Үз оясын һәрбер кош табар...
Бик ерактан күренсен дип, үргә
Юри салган сине осталар...

Озак уйлап бер сүз әйткән алар:
Монда укыр кеше, бел шуны;
Дүрт ягында — дүрт олы юл әнә,
Дүртесе дә булыр борчулы...

Дүрт ягында — дүрт озын юл ята,
Тәрәзәләр синең томанлы;
Кайчан гына кайтмыйм, үрдән миңа
Шул сагышлы күзләр төбәлде.

## Мулланур

Казан чите, таңда Казан чите,
Таш стена, ап-ак стена.
Таш стена түгел, истәлекләр
Ишелә күк минем өстемә.
Ак стена, салкын таш стена,
Я ул бер дә дәшми, я — дәшә.
Күрәм узган юлны,
Күрәм Мулланурны
Ленин белән бергә, янәшә.

Мулланурны аткан мылтык тавышы
Стенада калган, монда ул.
Ак стена, таш стена салкын,
Йөрәкләрдә безнең Мулланур.
Ак стена, салкын таш стена,
Я ул бер дә дәшми, я — дәшә.
Күрәм узган юлны,
Күрәм Мулланурны
Ленин белән бергә, янәшә.

# Беренче тау

Беренче тау...
Анда ятмый томан,
Үз вакытында шаулый яз анда.
Беренче тау
Беләсеңме кайда?
Без яшәгән данлы Казанда.

Беренче тау...
Җирдә беренче тау...
Торган чакта дөнья уйланып,
Караган шул таудан Идел аша,
Караган яшь, батыр Ульянов.
Беренче тау...
Таулар биек, текә,
Ул менмәгән таулар юк алар...
Беренче тау
Ульяновны көтә,
Көтә анда тын, карт юкәләр.

Беренче тау...
Анда ятмый томан,
Үз вакытында шаулый яз анда.
Беренче тау
Беләсеңме кайда?
Без яшәгән данлы Казанда.

● ● ●

Туган якта һәр тал җырлый
Үз-үзенә, тын гына...
Җырлый һәр тал, җитә эңгер
Тынмый алар, төн була...

Туган якта һәр тал җырлый,
Иркен монда һәр талга...
Җырлый һәр тал, батырлыкның
Билгесе күк һәр тамга...

Туган якта һәр тал җырлый,
Җырлый ярга нык басып;
Монда бар да үз дигәнчә,
Монда һәр тал Некрасов.

*Нурихан Фәттах*

# АРТТА КАЛГАН ЮЛЛАР

Хикәя

I

Су өстендә тирбәлеп торган көймәгә Хәмдия иплэп кенә, курка-курка гына керде. Керде дә борындагы аркылы тактага утырды.

— Менә монысына... уртага күчеп утыр, — диде аңа көймәче карт. — Көймәгә утырганың юкмени?

— Юк шул, бабай, — диде Хәмдия.

Башына командирлар фуражкасы, аягына исә ыштыр урап чабата кигән көймәче карт Хәмдиянең урнашуын гамьсез генә көтеп торды. Балалы хатын җайлап утыргач, ул ишкәк очы белән яр читенә төртеп алды, һәм балык исе, сумала исе аңкытып торган иске көймә җиңел генә, шома гына кузгалып китте.

Алар кыйгачлап агым уңаена бардылар. Көймәче карт, кыска саплы ишкәген бер кулыннан икенче кулына күчергәләп, салмак кына иште дә иште. Елга шактый киң иде. Уң яктагы яр каршы яктагысына караганда текәрәк иде. Күккә таба үрелеп, бер-берсенә нык сыенып, яр өстендә баһадир агачлар утыра һәм шуңа күрә елганың ул як чите тагын да биегрәк, тагын да шомлырак булып тоела иде. Бөтен киңлегендә елга аермачык күренми иде, шулай да як-якта, якында гына салкын, тыгыз су барлыгы, аның каядыр ашкынып акканлыгы һәм бик тирән икәнлеге яхшы сизелә иде.

Хәмдиянең баштагы шүрләве тиз арада юкка чыкты. Менә шулай кара ярлар арасыннан, салкын су өстеннән әкрен генә тирбәлеп бару аңа хәтта күңелле булып, сәер һәм рәхәт булып тоела башлады. Ләкин искәрмәстән көймә борыны белән җиргә төртелде, алга таба бераз шуышкандай итте дә тукталып калды.

— Менә чыгып та җиттек, кызым, — диде карт басынкы гына. — Карабрак чык. Шунда сукмак булыр. Ботакка тотынып мен.

— Рәхмәт инде, бабай... рәхмәтләр яусын, — диде Хәмдия, кинәт авырайган тәнен көчкә кузгатып.

Учына йомарланган бер сумны ул көймәчегә сузды, шәлгә төреп җилкәсенә аскан баласын яхшылап тотты да ярга таба атлады.

— Рәхмәт инде, бабай, рәхмәтләр яусын! — диде ул тагын да, көймәчегә борылып.

— Хуш, кызым. Юлың уң булсын, — диде көймәче карт.

Ул янә дә ишкәге белән яр читенә төртеп алды. Көймә кире шуып китте, һәм бераздан караңгы елга өстендә көймәченең алмаш-тилмәш селтәнгәне күренде дә, ишкәк очына шап-шоп бәрелгән су тавышы ишетелде.

Хәмдия бераз вакыт яр буенда тын гына басып торды һәм бары шуннан соң гына, агач ботакларына тотына-тотына, югары менеп китте. Менеп житкәнче аның сулуы капты, аяк буыннары хәлсезләнде — ни әйтсәң дә, бала авыр иде, шуның өстенә, аркасында аның кечерәк кенә капчыгы да бар иде. Менгәч ул яр өстендәге юан гына карамага сөялде дә киң итеп, озын итеп бер тын алды һәм төз, юан каусәләр арасыннан чак-чак кына беленгән елгага карап тора башлады. Сихерләнгән кебек ул бик озаклап карады, яратып, сокланып карады.

Аның өчен иң авыры, иң куркынычы менә шушы елга иде. Тегендә чагында ук — ерак юлга әзерләнә башлаган чакта ук аның өчен Бүә соңгы киртә булып, киртәләрнең дә иң биеге, иң яманы булып тоела иде. Язгы Бүә белән, ярларына тулып аккан кыргый дәрья белән чагыштырганда, кайтасы юлның озынлыгы да, юлда көтелгән һәртөрле азаплар, мәшәкатьләр дә аның өчен, әйтерсең, берни түгел иде.

Менә хәзер ул бу якта... Ул Бүәне кичте! Хәзер инде аны кайтып житте дияргә дә була. Менә моннан, менә шушы текә ярдан аның туган жире башлана. Җир шарының менә шушы өлешендә, тулып аккан шушы елга үзәнендә ул дөньяга килгән. Монда аның әбиләре-әниләре туган, аталары-бабалары туган. Бала чактан аның барлык әгъзасына шушы якның суы сеңгән, тыны сеңгән; бала чактан зиһененә шушы якның горефләре, гадәтләре сеңгән; күңелендә шушы якның сурәтләре: язы-көзе, җәе-кышы, урманнары, болыннары, зәңгәр күге... — барысы да, барысы да катлам-катлам булып сеңеп калган; бала чактан аның барлык тамырлары шушы якның туфрагына берегеп үскән.

Һәм менә ул чит җирләрдән монда кайтып төште. Мәңгегә, гомергә кайтты. Инде хәзер беркайчан да аерылмаска, беркайчан да чит якларга китмәскә дип кайтты. Алда җәелеп яткан кара урманны чыгасы да, Сакат тавын менәсе дә... кырлар-басулар аша, чокыр-чакырлар аша, такыр юлдан, такыр сукмактан туган өйгә кайтасы да кирәсе...

Аһ, нинди иркенлек, нинди гүзәллек! Никадәр хыялланды ул менә шулай яр буенда... урманда... карангыда шаулап аккан Бүәгә карап торырга! Никадәр хыялланды ул туган якның туган һавасын суларга!

Менә ул монда... менә җиргә басып тора. Күрәсеңме, урман, күрәсеңме, Бүә?! Баба-ай!.. Бабака-ай, ишетәсеңме, Хәмдия иленә кайтты!

## II

Ул яр буендагы бер ауган агачка килеп утырды. Утырды да аркасындагы капчыгын салды, баланың «бишеген» ычкындырды. Шул рәвешчә туарылгач, аңа тагын да җиңелрәк булып китте. Изрәп йоклаган баласын ул күкрәгеннән аскарак шудырды, аны тәгәрәп төшмәслек итеп урнаштырды да үзе агач ботагына башын сөяде.

Аны шундук йокы басты. Ул тынычлап, онытылып йоклады. Яр буендагы ауган агачка кырын-ярын яткан килеш, язгы салкынча һавада, урманда, Бүә буенда ул шушылай, ихтимал, төн-көн йоклый алган булыр иде, кырын ятып кына түгел, бәлки баскан килеш тә, теләсә нинди рәвештә, теләсә нинди урында да йоклый алган булыр иде. Ләкин аның баласы бар иде. Бала өчен исә аның гүя аерым нервылары, аерым йөрәге, аерым зиһене бар иде. Һәм шул аерым нервылары ярдәмендә ул йокы аралаш улының көйсезләнә башлаганлыгын сизеп алды. Сизеп алды да күзләрен ачып җибәрде. Бала уянган иде һәм үзенә чорналган чүпрәк эченнән кулларын чыгарырга тырышып ята иде.

Хәмдия башын калкытты, агачка җайлап утырды да «бишек» бавын бөтенләй чишеп җибәрде һәм баланы кулына алды. Баланың асты юеш иде. «Булдыксыз әннә! Оныткан бит карарга... улын оныткан!» диде ул



күңеленнән, үз-үзен тиргәп. Тышта, төнге салкын һавада баланың астын алыштыру никадәр кыен булмасын, шулай да ул аптырап тормады. Башына иске шәлен бөркәнде дә, бала өстенә иелеп, чатыр сыман бер нәрсә әмәлләде. Чатыр эчендә ул баланың тәпиен тотты, киемнәрен алыштырды, аннары аны җылыга — куенына алды да мәммәм каптырды. Бала, песи кебек мыр-мыр килеп, ашыгып-кабаланып имәргә тотынды. Яшь ананың бөтен тәненә рәхәт бер чемердек йөгерде.

Төн уртасы инде узган иде бугай. Агач араларындагы караңгылык сыеклана төшкән сыман иде, ләкин шул ук вакытта агачлар тагын да караебрак, бер-берсеннән аерылыбрак күренә иде. Өстә, ботаклар арасында, йолдызлар җемелдәшә иде, аста, кара кәүсәләр артында беркайчан да йокы белми торган, тынгы белми торган ташкын елга ага иде. Пыяладай салкын, чиста һава шундый тын, тыныч иде — суның яр читенә бәрелеп-бәрелеп агуы да, аяк астындагы коры чыбык-чабык сынганы да, баланың авызын чупылдатып-чупылдатып имүе дә олы тавыш булып, шау-шу булып ишетелә иде.

Бала имгәч, ананың да ашыйсы килеп куйды. Кузгалып киткәнче әзмекүпме көч җыярга кирәк иде. Капчыгын актарып ул бер сынык икмәк алды... солдат икмәген... Куяды станциясендә баласын кызганып аны солдатлар үзләре янына утырттылар. Яңавылга чаклы ул алар белән бер вагонда кайтты. Татарча бераз сукалый торган казакъ карты ана төшеп киткәндә бер телем икмәк белән бер шакмак шикәр бирде. «Минем дә шундый балам калды», диде ул, Хәмдиянең улын сөеп.

Икмәкнең яртысын Хәмдия Яңавылда ашады, яртысы менә капчык төбендә. Үзенә бер төрле хуш ис аңкып торган йомшак икмәк. Бераз катысы да бар... Элек ул икмәкнең йомшагын бер дә яратмый торган иде. Бервакытны бәләкәй чагында ул яңа пешкән бер бөтен икмәкнең катысын ашап бетергән иде. Күргәч әнисе бик ачуланган иде, әтисе исә көлеп кенә куйган иде. Балаларының шундый шуклыкларыннан ул шулай көлеп кенә куя торган иде... Ә бервакытны, әнисе кибән башын бирмәгәч, күз яшьләрен агызып елап утырган иде. Бар иде дивана чаклар, бар иде ипекәйнең кадерен белмәгән чаклар! Нинди тәмле, нинди кадерле икән ул йомшак булып пешкән арыш икмәге!

Кулындагы сыныгын озаккарак җиткерергә тырышып, ул ашыкмыйча гына, тәмен белеп кенә ашады. Ләкин икмәк сыныгы күз алдында кечерәя барды. Ниһаять, ул соңгы кабымын капты да, авызындагы икмәк тәменнән аерыласы килмичә, күпмедер вакыт тып-тын гына утырды.

— Әзрәк булды шул, улым, — диде ул аннары, кечкенә улына эндәшеп.

Күрәсең, балага да әзрәк булды — «имезлеген» авызыннан чыгарды да, шыңшып, ашыгып яңадан эзләнә башлады.

— Син дә туймадыңмыни, улым? — диде ана, борчылып. — Туймассың шул — әннә ач бит. Ничә көн инде без ачлы-туклы. Түз инде, түз, бәбчегем. Күп калмады, түз. Үзебезгә кайтып егылсак, беләсеңме, аннан соң инде кытлык дигән нәрсә кырык чакрым артта калачак. Кырык чакрым дип, улым, болай гына әйтелә ул. Кырык чакрым гына түгел, биш йөз чакрым артта калачак. Калды инде. Кытлык та, барысы да артта калды. Менә, улым, без Бүә буенда. Үзебезнең Бүә ярында. Син йоклап калдың, бернәрсә дә күрмәдең. Без көймә белән чыктык, улым. Кайткач без, беләсеңме, нәрсәләр ашарбыз? Кү-үп итеп ит ашарбыз, ипи ашарбыз, бәрәңге ашарбыз. Их, шундый иттереп ашарбыз! Тавыклар инде йомырка салалардыр — йомырка ашарбыз. Картыкай синең белән мин кайтуга, бәлки, берәр тавыгын кых итәр. Картый бик юмарт ул безнең. И ашарбыз тавык ите, и ашарбыз тавык шулпасы! Инде синең үзеңә дә ашарга вакыт. Әннәгә генә салгашырга ярамый. Тегендә булмады, монда булыр. Монда инде син үзең ашый башларсың. Бит әннәгә монда да эшкә йөрергә туры киләчәк, улым. Без икәүләп синең белән җиләккә барырбыз. Җиләк пешүгә син тәпи йөри башларсың. И күңелле булыр шул чагында, улым!

Ул аның йөзенә иелде, күзләренә карады. Бала инде йоклый иде.

Ана кеше юлга әзерләнә башлады: аркасына капчыгын асты, алгы яктан «бишеген» асты. Шуннан соң ул таякка дип коры ботак сындырып алды. Бу вакытта чит кеше, ихтимал, Сакат урманына аяк басарга да куркыр иде. Хәмдия курыкмады. Уйлап та бирмәде! «Әлли-бәлли бәү итте, улым йокыга китте... Аю, бүре килмәгез, улым йокыга китте», дип такмаклады ул күңеленнән, караңгы, тар сукмак буйлап атлый-атлый.

## III

Сакат тауларын һәм калын урманнарны артта калдырып, ул таң беленә башлаганда ялан кырга килеп чыкты. Күк йөзе ачылып китте, дөнья иркенәйде һәм тапталмаган каты юл да кинәт киңәеп, тураеп калгандай булды.

Кояш әле чыкмаган иде. Туган җир — кырлар-басулар, әрәмәләр, калкулыклар... томансу элпәгә төренеп, тын гына йокымсырап, оеп ята иде. Табигать әлегә соргылт-кара төстә иде. Күктә әле бернинди зәңгәрлек юк иде, җирдә әле бернинди яшеллек юк иде. Хәер, беренче карашка гына бу шулай иде, ахрысы.

Як-ягына карап бара торгач, Хәмдия Нуркай бакчасы ягында, калкулыкта яшел уҗым басуы күреп алды. «Арышны менә кайда урачакбыз икән», дип уйлады ул күңеленнән. Ә бераздан, әрәмәләрне үтеп, тагын да иркенрәк җиргә килеп чыккач, аның күз алдында икенче төрле күренешләр ачылды. Алда, еракта — әле анда, әле монда — сөрелгән җирләр караеп ята иде. Шулай да сөрелгән җирләр аңа нишләптер бик әз булып күренде. «Шулай бик соңга калдылар микәнни?» дип уйлады ул, гаҗәпләнеп. Дөрес, Урал якларында да... ул узган авылларда да әле яңа гына сөрә башлап калганнар иде. Ләкин бит аларда яз да соңгарак калып килә!

Аннары аны бераз гына шунысы да гаҗәпләндерде: күз күреме җиткән киңлектә ул бер генә җирдә дә трактор күрмәде. Шулай ук беркайда да аның тавышы да ишетелмәде. Кырларда, басуларда — сөрелгән һәм сөреләсе җирләрдә, әрәмә өсләрендә, чокыр-чакырларда, калкулык башларында — бөтен тирә-якта серле бер тынлык, торгынлык саклана иде. Бу минутта хәтта тургайлар да сайрамый иде, хәтта чыпчыклар да чыркылдамый, тилгәннәр дә очмый иде. Күңелле дә, күңелсез дә тынлык иде бу.

Ә бит сугышка чаклы бу вакытта көн-төн тракторлар гөрли иде! Сугышка чаклы гына түгел, кырык икенче елны да — Хәмдияләр ду

китереп соңгы мәртәбә колхозда эшләгән язны да — басуларда корыч атлар сөрә иде. Исең китәр — аларны да сугышка алдылар микәнни? Уйлап карасаң, аз гомер үтмәгән шул. Кырык дүртенче ел бит хәзер! Кырык дүртнең мае. Шул кадәр вакыт эчендә ниләр генә булмагандыр монда!..

Хәмдия авылга якынлашып килгәндә, Вәрәшнең Чаган тавы артыннан, аксыл күк кырыеннан беренче кызгылт-алтын нурлар тишелеп чыкты. Әкрен генә җил исеп куйды, һәм шул чакны авыл ягында сузыпсузып этәч кычкырган тавышлар ишетелде. Хәмдия туктады, үз алдына елмаеп җибәрде.

— Улым, карале, без авылга кайтып җиттек! — диде ул, тәэсирләнеп. Иртәнге саф һавада алсуланган битләренә аның кайнар яшьләр тамып төште.— Әннәнең туган авылы менә шушы инде, улым. Синең әле күргәнең юк. Син, улым, күп авыллар күрдең, күп шәһәрләр күрдең. Синең үз авылыңны гына күргәнең юк. Ул синең дә туган авылың, улым. Әнә безнең йорт күренә, әнә безнең яшен суккан карт чыршы утыра. Әнә безнең ындыр артта, чокыр аръягында Корт-бакчабыз... Корт-бакча астында безнең Салкын чишмә ага. Вәрәш якта, юл буенда әнә ялгыз нарат тора... Ач күзеңне, улым, күр дөньяны!

Үз алдына шулай сөйләнә-сөйләнә, дөресрәге, шулай уйлана-уйлана ул такыр юлдан бераз барды да читкә чыкты, сөрелмәгән җиргә керде. Үзләренә ул әйләнгечтән — чокыр эчләп, болын буйлап һәм ындыр артлап кайтып кермәкче булды. Аңа әле туры юлдан йөрергә бик үк ярамый иде.

## IV

Салкын чишмә чокырыннан менеп килгәндә ул үзләренең бакча капкасы янында бер сәләмә хатынны күреп, ирексездән туктап калды. «Кем булыр бу? Нишләп йөри анда?» дип уйлады ул, аптырап. Шул ук секундта сәләмә хатын да аны күреп алды һәм шулай ук танымыйча, исе китеп карап тора башлады.

Ләкин шулай да алар бер-берсен таный алдылар. Танып алдылар да, тагын да ныграк гаҗәпләнеп, куркып һәм шатланып, икесе дә берьюлы диярлек аһылдап җибәрделәр.

— Хәмдия! — диде сәләмә хатын, зәгыйфь бер ыңгырашу белән.

— Әнкәй... әнкәчкәем! — диде Хәмдия, йөрәк өзгеч бер өн чыгарып.

Алар кабаланып бер-берсенә каршы атладылар.

— Әнкәй, бәгырем! — диде Хәмдия.

— Кайттыңмыни, кызым? — диде әнисе.

— Әнкәй... әнкәчкәем! — диде Хәмдия, еламсырап.

Ул аны кочаклый алмады, улы белән икәүләп ул бары аңа сыена гына алды. «Нинди беткән, нинди беткән! — дип уйлады ул, әнисенең йөзенә карарга да куркып. Өстенә әнисе кырык ямаулы иске сырма кигән, башына чүпрәк сыман ниндидер яулык бәйләп куйган, ә яулык өстеннән иске бүрек кигән иде. Аягында аның чабата, ә кулына ул төреп капчык тоткан иде. Аның яңаклары, борыны, ияк очлары тире белән сөяктән гыйбарәт иде. Кайчандыр шаян очкыннар чәчеп торган кара күзләре хәзер нурсызланып каядыр эчкә — сөяк куышына кереп поскан иде.

— Киткәч бер хатыңны алдык та, хат язмадың, — диде ул, иреннәрен әкрен генә кыймылдатып. — Ут булдың да су булдың. Исәнсең икән ләбаса!

— Язмадым шул, әнкәй. Шундый җирдә эшләдем, — диде Хәмдия.

— Ярый инде, үзең кайткансың — анысына шөкер, — диде әнисе, тыйнак кына.

Корышкан бармаклары белән ул күз төпләрен сөртеп алды, аннары кызының кулындагы балага карады да тотлыгып калгандай булды.

«Нинди бала? Кем баласы?» — диде аның аптыраулы күз карашы. Хәмдия эндәшмәде. Ул эндәшмәгәч, әнисе дә төпченеп тормады һәм кире борылды да сукмак буйлап бакча капкасына таба юнәлде.

— Бу вакытта кая барырга чыктың, әнкәй? — диде Хәмдия, аның капчыгына игътибар итеп.

— Көшләбидә кибәк бар, — диде әнисе. — Кеше сизгәнче барып кайтыйм дигәнием.

— Нинди кибәк, әнкәй? — диде Хәмдия.

— Карабодай кибәге, — диде әнисе.

Хәмдия берни аңламады һәм кинәт туган бер шомлану белән, борчылу һәм пошыну белән, әкрен генә әнисе артыннан атлады.

Өй эчендә якты гына иде. Түрдә, зур сәкедә, иске-москыга төренеп, кемдер йоклап ята иде. Мич башында иренеп кенә соры песи юынып утыра иде. Барлык почмаклардан, барлык кием-салымнардан, савыт-сабалардан гади, аңлаешлы бер җылылык һәм туганлык хисе бөркелә иде. Шул ук вакытта барлык почмаклардан, барлык кием-салымнан, савыт-сабадан, котсыз күзләрен зур ачып, мохтаҗлык һәм ярлылык карап тора иде.

Бусагадан атлау белән, өй эченең әчкелтем, җылымса һавасын сулау белән, Хәмдия моны бик яхшы сизеп алды, һәм бу сизенү әнисе белән очрашканнан соң туган шомлану, аптыраш тойгысын тагын да ныграк көчәйтеп җибәрде. Шулай да сагыну һәм ярату тойгысы әле андагы барлык башка тойгылардан көчлерәк тә, чыдамрак та иде. Ул әле күңелен төшерергә ашыкмады. Җиңел генә атлап ул түргә узды, баласын сәкегә салды да аның чүпрәкләрен таратып ташлады. Шуннан соң ул аркасындагы капчыгын салды, өстен-башын салып ташлады һәм җиңеләеп, иркенләп үзенең яраткан урынына — почмакка, өстәл янына терәп куелган сандык өстенә менеп утырды.

Элекке чаклардагы кебек ул аркасын стенага терәде, аякларын сандык өстенә сузып җибәрде. Чүпрәк-чапрактан, авыр киемнәреннән арынгач, ул яшәреп, чибәрләнеп киткәндәй булды. Аның юлдан алып кайткан алсулыгы әле булса бетеп җитмәгән иде. Ул гәүдәгә таза, әнисе кебек үк эре сөякле иде. Аның зур кара күзләреннән, күлмәк аша беленеп торган таза иңбашларыннан, күкрәкләреннән көч һәм яшьлек дәрте ташып тора иде.

Ул игътибар белән тагын бер мәртәбә өй эчен күздән кичерде, башын борып тәрәзәгә карап алды һәм, аякларының рәхәт сулкылдавын тойган хәлдә, тып-тын гына шулай утыра бирде.

Менә сиңа туган йорт... сандык өсте... тәрәзә төбе... Барысы да артта калды, еракта, бик еракта калды. Мең тугыз йөз кырык икенченең октябрь таңында Яңавыл вокзалында елашып аерылышулар да, Урал таулары һәм Урал урманнары да, такта бараклар һәм торф сазлыклары да — барысы да, барысы да кайчандыр төштә күргән кебек кенә булып калды. Әллә булган, әллә юк. Чыннан да, әллә булган, әллә юк. Күз алдында шул ук түшәм, шул ук мич, шул ук җиз самовар, шул ук тынлык һәм шул ук исләр. Шул ук уйлар... Юк, юк, уйлар шул ук түгел. Менә нәрсә генә үзгәргән икән бу өйдә!

Ләкин шул чакны үз-үзен онытып җибәргән яшь хатынны айнытып, түр сәкедә бала шыңшып куйды.

## V

Хәмдия әнисенең төпченә башлавын көтте. Ул инде аны күптән көтте һәм үзенчә әзерләнеп тә куйды. Ләкин әнисе нишләптер берни сораштырмады. Бөтенесен алдан белгән кебек, ул, гомумән, берни белән кызыксынмады һәм, авыр гына кыймылдап, казан тирәсендә булашты.

«Әллә аңа дөресен әйтергәме соң?» дип уйлады Хәмдия, энисе тышка чыгып киткәч. Ник әйтмәскә — ана ич ул аңа! Аңа да әйтмәгәч, тагын кемгә әйтергә? Әмма тыштан чыбык-чабык күтәреп кергән энисенең йончылган, кызганыч йөзен күрү белән, аның фикере шундук кирегә үзгәрде. «Болай да беткән кешене нигә тагын бетерергә?» диде ул үз-үзенә. Шулай да нәрсә булган аңа? Авырыймы, әллә тормыш авырлыгы шулай басканмы?

— Син нәрсәдер пешерергә йөрисең бугай, әнкәй? — диде ул аңа, йомшак кына итеп. — Мин бик арыдым, йокы килә. Минем өчен булса, мәшәкатьләнмә хәзергә.

— Ярар, алайса, — диде энисе, бик тиз килешеп.

Шулай диде дә, тамырлары бүртеп торган ябык кулларын салындырып, сәкегә, бала янынарак килеп утырды. Аны бөтенләй күрмәгәндәй ул аңа кырын күз дә ташламады. Энисенең мондый кыланышы Хәмдиянең эчен тырнап куйды. Берни эндәшмичә ул сандык өстенә урын җәйде һәм баласын алырга дип сәке янына килде.

— Улым, җитәр инде, күп йокладың, — дигән булды ул. — Әйдә, тор, энә картый белән исәнләш.

Картый исә авыр гына борылды да, ниһаять, балага карагандай итте һәм нык кысылган иреннәрен көчкә ачып:

— Икәү булдыгызмыни, кызым? — диде.

— Икәү булдык, әнкәй, — диде Хәмдия.

— Ярый инде... Каяле, күрсәт әле — кем соң ул? — диде энисе, кызыксына төшеп.

Хәмдия биләүләрне таратып җибәрде.

— Сөбханалла! Җегет кеше икән ләбаса! — диде картый, кинәт ачылып китеп. — Күз генә тимәсен, тфү-тфү! Бәхетле сабый булсын.

— Исәнләш инде, исәнләш, улым, — диде бәхетле ана, елмаеп.

— Исәнме, улым, исәнме! — диде картый, күзләрен ачар-ачмас яткан сабыйга эндәшеп. — Күз тимәсен. Ярый инде... бәхетле бала булсын.

Шулай да ул карау белән генә дә канәгатьләнмәде — баланы иплән кенә күтәреп алды да хәлсез куллары белән аны күкрәгенә кысты, яратып, тансыклап аның чүпрәкләрен иснәде, битен, кулын иснәде.

— Бигрәк тәмле икән шул, бигрәк татлы икән шул! — диде ул, такмаклап. — Бәхетең, куанычың белән... иминлек-тынычлык белән... Ярый инде... Үзенә охшаган икән. Ир бала анасына охшаса, бәхетле була диләр... бәхетле генә булсын инде.

Селкетә-тирбәтә торгач бала ныклап торып уянып китте, дәү энисенә исе китеп бер карады да, авызын зур ачып еларга да тотынды. Тын, моңсу өй эче сәер тавышка тетрәнеп китте.

— Менә шулай, менә шулай! — диде картыйсы, балага дәрт бирен. — Шайтаннарны качыр! Качыр мәлгуньнәрне!

Хәмдия, куанычыннан нишләргә белмичә, елмаеп әле балага, әле энисенә карады.

— Ничә айлык? — диде картый, баланы анасына сузып.

— Сигез ай тулды, әнкәй, — диде Хәмдия.

Чынында бала ун айлык иде, ләкин ана кеше бераз гына ялганларга кирәк тапты.

— Исеме ничек соң? — диде энисе.

— Мин аңа Ирек куштым, әнкәй, — диде Хәмдия.

— Үзең генә куштыңмыни, кызым? — диде энисе, бераз тынлыктан соң.

Хәмдия каушап, тотлыгып калды.

— Анда аңа кемнәр исем кушсын инде, әнкәй, — диде ул аннары, күңелсез генә. — Әттәсе белән ярты ел гына тордык та, сугышка алдылар.

— Ярый инде, хәерле булсын, — диде әнисе, авыр гына көрсенеп. — Агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри. Исән-имин кайткансың — шунысына шөкер. Хаты киләме соң?

— Кемнең?

— Кияүнең хаты киләме? — диде әнисе, төпченеп.

Һы, кияүнең!.. Кызык... кияү, имеш!..

Хәмдия бу турыда уйлап житкермәгән иде. Ул бары үзенең алдануын гына белә иде, ул бары үзенең жилдән тапкан бала белән кайтуын гына белә иде, һәм аның барлык ихтыяры, барлык осталыгы, хәйләсе, омтылышы әнисеннән, күршеләрдән, барлык кешеләрдән шуны яшерүгә генә юнәлтелгән иде.

— Хаты килми шул, әнкәй,— диде ул кыюсыз гына.— Баштарак атна саен килде. Менә хәзер икенче ай инде: берни юк.

— Алай икән, — диде әнисе. — Кайсы якныкы соң — үзебезнең якнтанмы дигәндәй?..

— Юк, читтән... Көнгер ягыннан.

— Алай икән, — диде әнисе янә дә коры гына.

## VI

Ана кеше уйга калды. Шулай берниндi хәрәкәтсез тын гына утырды утырды да ике кулы белән битен сыйпап алды һәм, юри генә кыланган сыман, бер дә юктан борынын тарта башлады.

— Атаңның да хәбәре юк, кызым, — диде ул, күз яшьләрен агызып. — Синең кебек китте дә югалды.

— Мин югалмадым бит, әнкәй, — диде Хәмдия.

— Син дә бер-ике хат яздың да юкка чыктың, ул да бер-ике хат язды да юкка чыкты, — диде әнисе, аның сүзен тыңламыйча.

— Ул да минем кебек кайтып килер әле, әнкәй, — диде Хәмдия.

— Югароч Мәттин малае язган... Жәгъфәр... Нигъмәт абзый белән бергә кердек сугышка дигән, бунбы төште өстебезгә дигән... Шуннан соң Нигъмәт абзыйны күрмәдем, үлеп калды бугай дигән...

— Язганыегыз шул, әнкәй, — диде Хәмдия, авыр тынлыкны бозып.— Шул язганнан бирле берни юкмыни?

— Юк. Китте дә юкка чыкты. Ут булды да су булды. Кешеләрнең, ичмасам, хатлары килә. Аяксыз-кулсыз булса да... тере сөяге кайтса да...

Сүнгән учакка карап ул тагын тынып калды.

— Абыйныкы киләме соң? — диде Хәмдия, беравык эндәшми утырганнан соң.

Әнисе кисәк кенә башын калкытты, аптырап кызына карады.

— Син әле белмисеңмени — синтәбернең бишендә жыл тула үле хәбәрен алганга, — диде ул. — Сиңа язмаганбыз икән шул. Хатың килмәде бит — кая язасың... Сине дә үлгәндер дидек. Исән булгач кайттың менә. Абыең инде кайтмас... атаң да... Узган көзне Зарифжанны да алдылар.

— Зарифжанны? Сәкедә ул кем ята соң — Зарифжан түгелмени?

— Хаты килә,— диде әнисе, тыңламыйча.— Озакламам, кайтырмын дигән, аякны кистеләр дигән.

— Аягын?! — диде Хәмдия, коты алынып. — Аягын дисеңме, әнкәй? Зарифжанның?! Юкны сөйләмә, әнкәй!

— Хаты килде... үз кулы белән язган... укырсың.

— Кая, күрсәт! Булмас, ышанмыйм! — диде Хәмдия, урыныннан атылып торып.

Баласын кочаклаган көе, үз-үзенә урын тапмыйча ул ишекле-түрле йөренергә тотынды. Зарифжанның аягын кискәннәр! Шундый яшь, шундый таза Зарифжанның!.. Бала гына бит әле ул, сабый гына. Ул бит аның куенында — апасы куенында үсте. Зарифжанкаем, энекәчкәем, туганкаем! Кемнәр шулай итте сине?! Кемнең кулы барды шуңа?!

Карт ана да урыныннан торды, көчкә кыймылдап, иске шүрлек янына килде, шүрлек башына үрелде.

— Менә, укы, — диде ул, саргаеп беткән өчпочмаклы хат сузып. — Пуле тиеп яраладылар да, шешә башлады дигән, шуннан соң кисәргә булдылар, дигән.

— Укымыйм, әнкәй... укый алмыйм... — диде Хәмдия, пышылдап, хәлсезләнеп.

Көйсезләнә башлаган баласын ул сандык өстенә илтеп салды.

Ташкын булып, дәрья булып аның күкрәгенә яшь килде, әрнү килде, ачу һәм нәфрәт килде.

Сугыш! Нишләттең син безне?! Ләгънәт кенә төшсен сиңа!.. Ләгънәт, ләгънәт!..

Тыела алмыйча йөзе белән ул өстәлгә капланды. Әнисенең елавыннан куркып бала да шыңшырга тотынды. Картый аны тиз генә кулына алды, яңадан үзенең сәкедәге урынына килеп утырды да, кызының беркадәр тынычлангандай итүен көтеп торды да, әүвәлгечә шомлы бер тынычлык белән яңалыкларын тезә башлады.

— Җингәң төрмәдә, — диде ул, бала тирбәткән уңайга. — Биш елга утырттылар.

— Ник?!

— Бер кесә яшел кузак өчен. Урактан кайтканда кесәсенә яшел кузак салып кайткан булган. Баласы өчен инде... Тотканнар да, утыртып та куйдылар. Былтыр җәй. Әлтәфне үз яныма алдым.

— Әлтәфмени ул?

— Әлтәф. Тор, улым, менә Хәмдия апаң кайтты.

Башыннан иске юрган бөркәнеп яткан малай, үз исемен ишетү белән, шундук торып утырды. Ул, күрәсең, күптән инде уяу иде һәм бары тик әдәп сакларга мәҗбүр булган өчен генә торырга кыймыйчарак ята иде. Җирән чәчле, аксыл кашлы малай ялан аяклары белән туп итеп идәнгә басты да, йокылы күзләрен уа-уа, Хәмдия апасы янына килде һәм күрешмәкче булып аңа чыбыктай нечкә беләген сузды.

— Әлтәфкәем, җаныкаем! — диде Хәмдия, уникe-унөч яшьлек малайны күкрәгенә кысып. — Нинди үскән, нинди зур булган!

— Үсәсең инде дөнья булгач, — диде малай, белдекле генә кыланып.

— Нишләсен ул анда бер үзе? — диде Хәмдиянең әнисе, башлаган сүзен дәвам итеп. — Менә шулай торып ятабыз. Җингәңнең өенә бик салдылар, әйберләрен конфискайть иттеләр. Баланы каядыр озатмакчы булганнарые — бирмәдем. Ярый инде, рәхмәт — укытучы апалары булышты. Яңавылга ул барды бала хакында.

## VII

Хәмдия телсез-өнсез калды. Ярсыган, аптырашлы уйлары белән ул сандык өстендә тораташтай катып калды.

— Китим әле, вакыт үтә, — диде әнисе, урыныннан кузгалып. — Бер ниятләгәч барып кайтыйм инде. Син, алайса, йокла. Әлтәф үзен үзе карар.

Хәмдия эндәшмәде. Эндәшә алмады. Аның теле бәйләнде, аның барлык ихтыяры, барлык яшәү сәләтләре тоткарланып калды. Башыннан бөркәнде дә йомшак урынга сузылып ятты. Чыгып киткәндә әнисе Әлтәф белән нәрсә турындадыр чыш-пыш килде, аннары ишек ачып япкан тавышлар ишетелде, аннары өйдә Әлтәф кенә калды: идәнгә чүмечне төшерде, ашарга сорап йөдәткән песине тибеп җибәрде. Хәмдия керфек тә калкытмады.

Моңарчы ул бары улы белән генә яшәде. Әтисе-әнисе алдында, туганнары алдында ул үзен коточкыч гаепле итеп тойды. Алар алдында

гына түгел, һәрбер авылдашы алдында, һәрбер танышы алдында ул үзен төзәлмәслек җинаять эшләгән кеше итеп тойды. Әтисе, энисе, туганнары турында ул уйларга да курыкты. Аларны ул бары төшләрендә генә күрә алды һәм еш кына йокысыннан кызарынган күзләр белән торды.

Башта шулай булды. Тора-бара аны бүтән төрле кайгы-мәшәкатьләр күмеп китте. Анда инде юк-бар нәрсә уйланырга вакыты да, мөмкинлеге дә булмады. Аның өчен хәзер бөтен дөнья, бөтен галәм үзенең улы булып, йодрыктай кечкенә, нәни генә улы булып калды.

Әйе, ул бары аның өчен генә яшәде. Шуның өчен ул дуслары, танышлары белән бозылышты, шуның өчен мең төрле азаплар кичерде. Дөньяга килүенең беренче көннәрендә бала бараклагы һәркем өчен тансык булды. Аны яраттылар, кулдан кулга йөрттеләр. Ләкин озакламый аның тавышы да ишетелә башлады, кибәргә эленгән чүпрәк-чапраклары да күренә башлады.

Аһ, никадәр телгәләнде ул чакларда аның йөрәге! Никадәр йокысыз төннәр, никадәр әрнүле, газаплы көннәр кичерде ул шул чакларда! Артык түзәр чамасы калмагач, ул шунда конторада идән себереп, су җылытып торучы бер карчыкны белеште. Баланы фәлән сәгать карап торган өчен карчык көненә өч йөз грамм икмәк сорады. Өч йөз грамм ул алты йөз граммның яртысы дигән сүз иде... алты йөз граммның, ягъни олы кешегә — көне буе кар ярып, хәлдән таеп эшләгән кешегә бирелә торган көнлек пайның яртысы дигән сүз иде. Ул берсүзсез риза булды. Ләкин калган өч йөз грамм аның кече теленә дә йокмады. Хәлсезлектән еш кына аның башы әйләнде, күз аллары караңгыланды. Ә бер көнне ул аңын югалтты. Эштә. Шунда бүрәнәләр арасында... Аннан да яманрагы шул булды — аның сөте кимеде. Бала туймый башлады. Ябыкты, начарланды. Шуның өстенә, карчыгы да аждаһадай явыз нәрсә булып чыкты. Аның ярты гомере төрмәләрдә узган иде, һәм анда инде кешелек дигән нәрсәнең тамчысы да калмаган иде. Ул бары үзенең өч йөз граммын гына кайгыртты һәм баланы алырга килгәндә бирәр минутка соңгардыңмы, кырык төрле сүзгә җитеште.

Кая анда өй турында, ата-ана турында уйланулар! Төннәр утырып ул иске-москыдан баласына күлмәк-ыштан текте, качып-посып аның еш чылана торган чүпрәкләрен юды, качып-посып киптерде, ә кайчакта... ә кайчакта... Я алла, ниләр генә эшләмәде дә, нинди генә хурлыкларга төшмәде ул аның өчен!

Быел язга таба аның хәле чамадан тыш көйсезләнеп китте. Аждаһа карчык баланы караудан баш тартты, баракта калдырып йөрү кыенлашты, ә инде аерым бүлмә даулау турында башка да китерерлек түгел иде. Һәм көннәрдән бер көнне ул бәхетсез улы белән упкын кырыена килеп терәлде. Андагы шартларда ул упкыннан котылу өчен бары бер генә юл бар иде: олырак хатыннар аңа баланы балалар йортына бирергә киңәш иттеләр. Бу инде аннан мәңгегә аерылу дигән сүз булачак иде. Хәмдиянең ишетәсе дә килмәде.

Ләкин уйлана торгач ул моннан башка тагын икенче бер юл эзләп тапты. Сугыш елы законнары никадәр каты булмасын, атасыз туган бала белән халык күзенә күренү никадәр хурлыклы булмасын, бернәрсәгә карамыйча, ул качарга булды. Бу турыда ул бары дусты, сердәше Фәүзиягә генә әйтте. «Безне монда көчләп тоталар. Үз авылыгызга кайтып егылсаң, колхоз сине яклар, — диде Фәүзия, аның бу ниятен хуплап. — Колхозда да кеше бик кирәк хәзер. Юлда гына тотыла күрмә».

Һәм ул качты. Баласын, киемен-салымын күтәреп, караңгы бер төндә ул шау-шулы, сасы һәм явыз бараклан иркен кырга чыгып китте. Ул гомергә белмәгән-күрмәгән юллар белән кайтты, гомергә белмәгән-күрмәгән авыллар, шәһәрләр аша кайтты. Кайбер җирдә поездга утырды, кайбер җирдә җәяүләп элдерде. Рәхмәтле бәндәләр кайвакытта үзләре

бирделәр, кайвакытта сорап алырга туры килде. Ничек итсә итте, шулай да менә туган йортына кайтып егылды.

Әйе, өйдәге хәлләр турында ул берни белмәде. Баксаң, әнә ниләр бар икән дөньяда!

Ләкин дөньяда ул белмәгән бик күп нәрсәләр бар иде әле. Әнисе белән икенче сөйләшүендә аңа тагын да күңелсезрәк яңалыклар ишетергә туры килде.

## VIII

Ул көне буе йоклады һәм кич караңгы төшкәч кенә уянды. Авыр күз кабакларын ачу белән ул чатнап башы авыртканлыгын тойды. Аннары аның өзелеп-өзелеп ашыйсы килеп куйды. Түзсә дә түзә бит кеше — кайчаннан бирле ашаганы юк инде аның! Туктале, улы нишләде икән соң аның әннәсе йоклаганда? Ул да көне буе ач булды микәнни?

Ана кешенең йөрәге жу итеп китте. Ул шундук башын калкытты, якягына каранып алды. Учакта дөрләп ут яна иде. Түр сәкегә, идәнгә һәм идән уртасындагы аркалы урындыкка кызгылт ут яктысы төшкән иде. Сәкедә әнисе белән Әлтәф утыра иде. Алар арасында аның улы да бар иде. Алар никтер әкрен генә көлешәләр иде.

Улын күрү белән, аның куанычлы тавышын ишетү белән Хәмдиянең күңеле тибрәнеп куйды. «Ярый әле Зарифҗанкаебыз исән калган, — дип уйлады ул гаҗәеп бер канәгатьләнү белән. — Сугыш бит... нишлисең, бер ул гына түгел бит...»

Торып ул сәке янына килде.

— Минем улым әннәсеннән иртәрәк өлгергән! — диде ул, идәнгә улы каршысына тезләнеп.

— Без аңа аш ашаттык, Хәмдия апа! — диде Әлтәф, шатланып.

— Белми шул әле, — диде картый. — Ашаткаламадыңмыни соң син аңа?

— Туры килмәде шул, әнкәй, — диде Хәмдия.

— Менә... икәү булдылар инде... ике малай, — диде әнисе, балаларның аркасыннан сөеп.

— Ике туган... ике бертуган, — диде Хәмдия, әнисенең сүзләрен куәтләп.

— Әткәйгә алмашка! Үскәч мин әткәй өчен сугышка китәм, — диде Әлтәф, мактанып.

— Авызыңнан җил алгыры! — диде карт ана, ачуланып. — Әзерлән! Син генә калдың менә... Инде сугышны бүтән ишетергә дә туры килмәсен, диген... әйттем исә кайттым, диген!

— Әлтәфләр, Иреклар үсеп җиткәнче әле! — диде Хәмдия һәм кинәт үзенең улын Әлтәф кадәр үскән итеп күз алдына китерде дә көлеп җибәрде.

— Тиресен тегеп куймаган, — диде әнкәсе. — Аларның үскәнен күрми дә каласың. Үсәләр дә, китеп юкка да чыгалар.

Ул авыр гына торды да казан янына китеп барды. «Нәрсә пешә икән соң анда?» дип уйлады Хәмдия, өйгә чыккан буны иснәштереп. Тавык шулпасы микән, әллә каклаган ит кенә микән? Ләкин казаннан чыккан ис нишләптер тавык шулпасы исенә охшамаган кебек иде. Бу ниндидер әчкелтем, буш һәм тәмсез ис иде. Хәмдиянең бер дә юктан эче пошып куйды. Ә инде өстәл янына утыргач һәм әнисе казаннан бүлеп китергән тәлинкәне болгатып карагач, аның чын-чынлап кәефе кырылды. Аның... аларның кайтуы хөрмәтенә әнисе аны... умач белән сыйларга исәпли иде! Чынында бу умач та түгел иде — бу бары кайнар су гына иде һәм шул кайнар суга беркадәр бәрәңге дә, беркадәр он сыман нәрсә салынган иде.

Ул теләр-теләмәс кенә «тавык шулпасын» ашарга тотынды. «Күрәсең, кызганадыр. Хәлләре шәптән түгелдер», дип уйлады ул, мондый ярлылыкка үзенчә аклану эзләп.

Аш янында беркем сөйләшмәде. Аларның өендә гадәт шундый иде. Ашаганда сөйләшмәгез — туймассыз, ди торган иде әтиләре. Тик шулай да утыра торгач мондый изге гадәт көтмәгәндә истән чыгып китте. Әлтәф үзенә бүлеп бирелгән тәлинкәне күз ачып йомган арада ялт итеп куйды да ач күзләрен елтыратып картыйсына карады.

— Бетердең дә мени әле? — диде картыйсы.

— Ыы, — диде малай, тирләгән маңгаен сөртеп. — Куерагын сал әле, картый?

— Куесы алла кулында, — диде картый тыныч кына, Әлтәфнең тәлинкәсен алып.

Иренеп кенә ул урыныннан торды, иренеп кенә казаннан аш бүлеп китерде. Хәмдия, йөрәге әрнеп, караңгы чырай белән, бәрәңге суын болгатуында булды. Юк, ни генә булмасын, өендә ул һич тә мондый болганчык су эчәрмен дип уйламаган иде! Хәтта тегендәге кәбестә суы да, юлда авыз итәргә туры килгән башка кәбестә сулары, бәрәңге сулары да моннан куерак һәм туклыклырак шикелле иде. Бөтен илдә ачлык, ялангачлык хөкем сөргәнлеге аның өчен һич тә сер түгел иде, ләкин шулай да ул ачлыкны бары иген үсмәгән җирләрдә генә — шәһәрләрдә һәм Урал якларында гына дип уйлый иде.

— Нәрсә, шулай алла кулына калдыгызмыни, әнкәй? — диде ул киеренке бер тынлыктан соң.

— Калдык, кызым... менә шушы көнгә калдык, — диде әнисе. — Күрмисеңмени — коры таякка калдык. Яр якасына җиттек инде, аяк сузасы гына калды.

— Нишләдегез? Ни булды?! — диде Хәмдия, ачынып. — Син бит бер дә мондый түгелиең, әнкәй! Каклаган итең дә буладырые, балың да, маең да... Нишләдең, чирләдеңмени? Эшкә йөрер рәтең калмадымыни?

— Белмәссең инде, — диде әнкәсе, көрсенеп. — Чирләгәнеңне дә белмәссең — ярым үлек кебек мыштырдыйсың шунда. Эшкә йөрим, кызым.

— Мин былтыр тырмага йөрдем, Хәмдия апа! — диде Әлтәф.

— Менә хәзер мин дә йөри башлармын, — диде Хәмдия, әнисен сөендермәкче булып. — И сагындым, әнкәй, колхоз эшләрен! Тегендә бернинди болын юк, иген чәчкән басу юк. Саз да урман, урман да саз. Җәй дә шунда, кыш та шунда. Тоткындагы кебек.

— Күрә инде адәм башлары, — диде әнисе, уфтанып, беркемгә дә карамыйча. — Алда тагынниләр күрәсе бардыр инде... бер алла белә. Менә шушы көнгә калдык, кызым. Сез киттегез дә югалдыгыз. Хат та язмадыгыз. Сезгә рәхәт... ялгыз башка... менә монда барысы да миңа өелеп калды. Җитмәсә, сорап утырган буласың. Күктән төшмәгәнсеңдер бит — күргәнсеңдер, ишеткәнсеңдер...

Аның сүзләрендә, әрнүле, сыкранулы тавышында Хәмдиягә шелтә һәм үпкә сизелде. Үзенә карата әйтелгән бу шелтә һәм үпкәнең хаксыз, урынсыз икәнлеген бик яхшы белсә дә, шулай да ул әнисенә әз генә дә ачулана алмады.

— Әйтеп торам бит, әнкәй, мин анда тоткындагы кебек яшәдем, — диде ул, мөмкин кадәр йомшаграк булырга тырышып. — Анда бернинди авыл юк, колхоз юк. Урман эче. Сазлык. Җәй көне торф чыгардык, кыш көне урман кистек. Эт кермәс, кош җитмәс җир.

— Күрә инде адәм башлары, — диде әнисе тагын да. — Мин дә шушы көнгә калырмын дип уйламаганыем, кызым. Өйдә күзгә кырып салырга бер уч он юк. Орлыкка дип калдырган ике-өч поттай бәрәңге барые, хәзер шуңа тотындык. Менә шулай, кызым. Яшерен-батырын түгел. Каклаган итләр хәзер сагынып сөйләргә генә калды.

— Сыер бозауламадымыни? Мал-туар, кош-корт... исәнме?... бармы?

— Юк, кызым, бетте... берсе дә калмады, — диде энисе әкрен генә, агач кашыгын ялаштырып. — Быел күз өч тавык белән бер әтәч куйганыем... бичаракайларым, туңып үлделәр. Ашарларына да булмады, абзар да суык булды. Дүртесе беркөнне үлгән. Утырып җыладым. Кисәк кенә суытты. Кырык биш градыска җиткән диделәр. Бүрәнәләр шартлады. Былтыр күз ике сарыкны ит планына бирдем... салымга... Калдырмадым. Каравы да авыр. Быел килеп менә сыерга чират җитте. Саклый алмадым, кызым, булмады. Колак кактым... колак кактыгыз, балакайларым! Сыер барында болай ук түгелие, акмаса да тамадырые. Бичаракаемның бозавын фермага биргәнием... пот ярым арышка. Озак тормады, үзеннән дә колак кактым. Саттым... ит планына, заемга, налукка, страхка... маена, тиресенә түләдем... Барысын да шул каплады. Котылдым.

Хәмдиянең кинәт кулыннан кашыгы төшеп китте. Шакылдап кайнар сулар түгеп, идәнгә төшеп китте. Аның тәмам төсе качты, аптыраудан коты алынудан авызы ачылды.

— Әнкәй! — диде ул, тыны бетеп, пышылдап.— Әнкәй... чынмы?!

## IX

Ул төнне беркемнең дә күзенә йокы кермәде. Алар төне буе сөйләшеп, кайгырышып чыктылар. Әнисе сөйләгәннәрне Хәмдия куркыныч әкият кебек тыңлады. Базарда онның поты өч мең ди, бәрәңгенеке биш йөз, алты йөз ди... Кесәдә нибарысы йөз сум чамасы акча бар. Ел ярым вакыт эчендә эшләп алган акча... Колхоз күтәрәмдә ди... Җирне сыерлар белән сөрәләр ди... Басуда утырып калган ашлыкны ашаучылар агуланып үләләр ди... Авылда инде өч-дүрт кеше үлгән. Бәрәңге басуларын актарып бетергәннәр... бер черек бәрәңге табарлык түгел ди...

Туган авылы, туган колхозы тегендә чагында Хәмдия өчен байлык, муллык чыганагы булып, барлык газаплардан, барлык михнәтләрдән котылу урыны булып тоела торган иде. Караңгы төндә такта баракны ташлап чыгып киткән минутта да, баласын кочаклап салкын, шыксыз вокзалларда төн уздырган чакларда да, ашханәләрдә, рестораннарда кешеләрдән калган тәлинкәләрне ялап йөргәндә дә — һәркайда да, һәркайчан да туган өе, туган авылы бик еракта җемелдәгән өмет йолдызы булып күренә иде. Авыр юллар, авыр көннәр хәзер инде артта калды, хәзер инде алда юллар да юк, үзенә өндәп җемелдәгән йолдыз да юк. Йолдыз түгел, хәтта тычкан уты да күренми!

Ничек яшәргә, ничек җан асрарга болай булгач?

— Әнкәй, Көшләбигә бардыңмы? — диде ул караңгыда әнкәсенә эндәшеп.

— Бардым. Бетергәннәр. Кемдер җитешкән миңа кадәр, — диде әнкәсе.

— Әнкәй, әйдә икәүләп барабыз тагын? Ындыр табаклары бардыр әле бүтән җирдә.

— Әйбәт булырые да соң... — диде әнисе, теләмичә генә.

— Нәрсә, рөхсәт итмиләрмени? Тоталармыни? — диде Хәмдия, сагаеп.

— Әлегә тотканнары юк, — диде әнисе.

Беравык тынып ятты да ничектер шикле итеп, шомлы итеп сорап куйды:

— Син соң, кызым, ничек кайттың... берәр төрле язу беләнме дигәндәй, әллә болай гынамы?

Хәмдия тып-тын калды. Бала кебек бу да аның өчен иң авыр мәсьәлә иде. Авыр гына түгел, томанлы да иде.

Авылдан алар дүртәү киттеләр. Өч кыз, бер егет. Кәримне ике-өч ай эшләгәч тә армиягә алдылар. Мәрхәбә белән Нурия, язга чыгу

белән, чыдамыйча качып киттеләр. Ул калды. Ул түзәргә булды. Ул авырлы иде, аның кайтыр юлы болай да киселгән иде. Төптән уйлап караганда, ул һич тә качып кайтмады. Чынында ул үзенекен эшләп, тутырып кайтты. Моннан киткәндә аларны алты айга дип алып китте-ләр. Ләкин ярты ел эшләгәч, тагын ярты елга калдырдылар. Анысын да тутыргач, әйттеләр: сез монда сугыш беткәнче эшләячәксез, диделәр.

Әйе, ул үзенекен эшләде. Кыш көне урман кисте, җәй көне торф чыгарды. Кыш көне... чатлама суыкта, буранда. Кар ярып. Кулларын-аякларын туңдырып. Ирләр аудармастай агачларны аудардылар. Баш-та авырлы көе азапланды, аннары балалы көе... Җәй житкәч торфка кудылар... сазга, черки арасына... Ул үзенекен тутырды. Аны беркем дә: эшләмәде, дип әйтә алмаячак. Үзенә тиешлесен ул көн дә бер ярымга, икешәргә тутырып барды. Аның кебек таза, көчле беркем дә юк иде анда. Аңа хәтта ирләр дә көнләшеп карыйлар иде. Ул анда аттай эш-ләде, үзен үзе аямыйча эшләде. Ләкин киткән чакта аңа язу бирмәде-ләр. Язуны ул сорап та тормады. Шулай туры килде..

— Күңелем сизенгәние лә аны! — диде әнисе, көрсенеп. — Ярый әле башта ук малайны ныгытып куйдым сүләнеп йөрмә дип... Нишләрбез инде, кызым?

— Нәрсә «нишләрбез?» — диде Хәмдия, тагын да ниндидер яман нәрсә буласын сизенеп.

— Нәрсә булсын — сине әйтәм. Алай качып та кайткач, балаң да булгач, нишләрбез икән димен шул.

— Мин инде күп уйладым, әнкәй, — диде Хәмдия, гамьсез булырга тырышып. — Иртәгәдән кантурга барам, сөйләп бирәм барысын да. Эшкә йөри башлыйм. Баланы син карап торырсың. Нинди эшкә кушса-лар, шуңа. Сагындым, әнкәй. Ни әйтсәң дә, ударник Хәмдия бит әле мин! Ни әйтсәң дә, үз авылым, үз колхозым.

— Белмим шул, — диде әнисе.

— Нурия белән Мәрхәбә кайтып җиттеләрме соң? Алар нишләде икән? — диде Хәмдия.

— Кайттылар, — диде әнисе авыр гына. — Синең турында сораш-тырыйм дип барганыем, туры китерәлмәдем. Алып киткәннәрие.

— Кая?

— Кая булсын — Яңавылга! Җиде елга утырттылар бичаракайла-рымны.

— Җиде елга?!

— Җиде елга, кызым,— диде әнисе.— Карт башыма ялганлап ятар хәлем юк: җиде елга.

— Алар эштән качтылар, эшлиселәре килмичә! — диде Хәмдия, үр-тәлеп.

— Син нәрсәдән качтың соң, кызым? — диде әнкәсе.

## X

Шулай итеп, көтелгән оҗмах көтелмәгән тәмугка әйләнде. Бала мәсьәләсе, бала хурлыгы рәхимсез чынбарлык каршында бик кечкенә булып калды. Бер көн эчендә бер-бер артлы ишелеп төшкән коточкыч яңалыкларга тагын бер яңалык өстәлде. Монысы да шулай ук искәр-мәстән ишелеп төште, күмеп китте, изеп ташлады, һәм бәхет, куаныч турындагы татлы уйлар мәңге упкынга атылды.

Инде нишләргә хәзер? Туктале, чынлап та, нишләргә соң хәзер? Күрәләтә башыңны төрмәгә илтеп тыгаргамы, әллә соң, әнкәсе әйткән-чә, сугыш беткәнче өйдә качып ятаргамы. Ярый ла сугыш тиздән бетсә! Тиз бетмәсә, ничек түзәргә? Гомумән, мөмкинме ул өйдә качып яту? Таза баштан, бер гаепсез көйгә... карак кебек... үз өендә, үз авылында качып яту мөмкинме ул?! Тирә-якта күршеләр бар, өйдә балалар бар.

Берсе кермәсә икенчесе керер, берсе күрмәсә, икенчесе күрер. Хәмдия качып кайткан диярләр, өендә яшеренеп ята икән диярләр. Кайсы Хәмдия? Соң теге... сугыш алдыннан Мәскәүгә күргәзмәгә барам дип масаеп йөргән Хәмдия! Бичаракаем, күрә инде адәм башлары, диярләр. Аны бит уйнаштан тапкан баласы белән кайткан дип сөйлиләр, диярләр...

Менә ул кайда мәсхәрә, менә ул кайда хурлык!

Ләкин әле хурлыктан да зуррак, хурлыктан да яманрак икенче бер нәрсә бар. Ул да булса — балаң белән, анаң белән, бөтен өй эчең белән ачка үлү куркынычы... Бетеп беткән бер әнисе ничек туйдырсын аларны?!

Шулай да бернәрсә дә эшләп булмый микәнни соң? Юк, нәрсәдер эшләргә кирәк. Качып ятарга ярамый. Һич тә ярамый! Таза баштан, бер гаепсез көе...

Ул төне буе уйланып чыкты.

Таң алдыннан аны йокы басты. Ләкин көтмәгәндә урам якта нииндидер шакылдавык тавышы ишетеп ул кисәк кенә уянып китте. Тавышка әнисе дә уянды һәм йокылы күзләрен кечкә ачыштырып, битенә төшкән аксыл чәч бөртекләрен артка сыпырыштырып, тәрәзә янына килде.

«Әллә килеп тә җиттеләрме?» дип уйлады Хәмдия, телсез-өнсез калып.

— Җәмиләттәй, Җәмиләттәй! — дип кычкырды тышта ниндидер талапчән хатын-кыз.

«Кем соң әле бу?» диде Хәмдия үз алдына. Тавышы таныш. Тукта, Факия түгелме соң? Әйе, Факия. Кара, нинди! Гомергә Факия дип уйламассың.

— Тәмле йокы вакытында килә дә уята шул нәрсә,— диде Җәмиләттәй, үз алдына сукранып.

«Бригадир микәнни?» дип уйлады Хәмдия. Исең китәр — ялкау Факия бригадир булган!

— Нәрсә бар, ни булды, Факия? — диде Җәмиләттәй.

— Хәзер үк киен, амбар алдына бар, — диде Факия. — Капчык алырга онытма. Яңавылга барачаксыз.

— Яңавылга? Бүәгә күпер салмаганнар диләр бит әле, Факия.

— Күпер салынганны көтеп ята торган чак түгел. Кимә белән чыгарсыз. Ике тәңкә акча да алыгыз... кимәчегә... баруына-кайтуына...

— Белмим шул, Факия, — диде Җәмиләттәй, теләмичә. — Нәрсә алып кайтырга соң?

— Бодай алып кайтырсыз. Чәчү орлыгы. Кеше башына җегерме кило чамасы тия. Бездән ун кеше бара.

— Җегерме кило! — диде Җәмиләттәй, шаккатып. — Беткәнмени яшьләр? Шул тикле җирдән... җегерме кило ашлык күтәреп... Аяк атлар хәлем дә юк, Факиякаем.

— Кеше юк,— диде бригадир.— Яшьләр дә бара, картлар да: Газимәләр, Санияләр, Хәким кызлары... Атларга салгашып ята торган заманнар узды инде — үзең беләсең... Ул җирне чәчми калдырыйкмыни! Кичәгенәк Яңавылдан хәбәр алынды: бер көн эчендә ташып бетерергә диләр. Хөкүмәткә рәхмәт инде — ул бирмәсә, каян алырыең бу вакытта!

— Рәхмәт инде, рәхмәт, — диде Җәмиләттәй, ашыгып, ярарга тырышып.

— Шулай, Җәмиләттәй, — диде Факия, нык итеп. — Күп сөйләнмә, хәзер үк киен. Халык амбар алдына җыела.

— Һай алла, бер дә хәлләрем юк бит әле, Факиякаем,— диде Җәмиләттәй, нишләргә дә белмичә. — Ничек соң, ичмасам, бераз ашарга бирмиләрме... аяк ялына?

— Булыр диделәр. Ике йөз грамм чамасы он диделәр кеше башына.

— Бигрәкләр юк икән шул, — диде Җәмиләттәй, башын селкеп. — Ярар, барырмын инде, алайса. Аяк атлар хәлем дә юк шул, Факиякәем.

— Менә минем дә аяк атлар хәлем дә юк — шулай да йөрергә туры килә, — диде бригадир һәм амбар янына хәзер үк барып житү турында тагын бер мәртәбә кисәтте дә китеп барды. Ләкин бераз җир киткәч тә ул, нәрсәдер онытып калдыргандай, кире борылды, янадан тәрәзә каршысына килде.

— Карале, Җәмиләттәй, — диде кычкырып, — кайтканда кесәгезгәнигә сала күрмәгез. Бодае агуланган. Аннары, тотыла калсагыз...

— Аллам сакласын! — диде Хәмдиянең әнисе.— Бөртеге дә кирәкми. Безгә харам мал килешәмени! Ачтан үлсәм үләрмен, кешенекенә кул сузмам.

Факия китеп баргач, ул лып итеп урындыкка утырды һәм, ябык кулларын тез өстенә салган килеш, аптырап тынып калды.

— Яңавылга түгел, теге очка барып кайтканчы да аяк буыннарым калтырый, — диде ул, үз алдына сөйләнеп. — Сигез чакрым бит әле ул! Барасы, кайтасы белән уналты чакрым. Тау менәсе, тау төшәсе. Житмәсә кесәңнән ике тәңкә чыгарып түлә!

— Әнкәй, синең өчен әллә үзем барыйм микән? — диде Хәмдия, башын калкытып. — Үзем теләп эшләп китсәм... кайткач та кеше күзенә күренә башласам?..

Җәмиләттәй корышкан куллары белән битен сыйпап алды да, авызын кыйшайтып, еламсырагандай итте.

— Күрсәтте бу сугыш безгә... картаймыш көнемдә...

— Әнкәй, чынлап, барыйм әле үзем?! — диде Хәмдия, дәртләнеп, урыныннан торып.

— Рәхмәт, кызым, — диде әнисе коры гына.

## XI

Җәмиләттәй шулай бер урында һушы китеп утырды-утырды да, аякларын көчкә өстерәп, тышка чыгып китте, утынлыктан чыбык-чабык алып керде һәм көндәгечә казан астына ягып җибәрде. Бераздан Әлтәф тә сикереп торды.

— Улым, бар әле су алып кайт, — диде картый.

Малай ашык-пошык битен-кулын юды да, чыгып та китте.

— Ярый әле бу бала бар, — диде Җәмиләттәй. — Ул да булмаса, нишләриең? Чишмәдән кайтканда тыным кысыла, аяк буыннары калтырый. Элекке әнкәң юк инде ул хәзер, кызым. Сезнең кайгыдан агармаган чәчләрем агарды, саргаймаган йөзләрем саргайды. Зарифҗанымны исән-сау күрсәм, инде үлсәм дә үкенмәм.

Ул әле һаман тынычлана алмаган иде, ул әле һаман да күңеленнән ярсый иде, үртәлә иде, ләкин шул ук вакытта аның эчендәгесен тышка чыгарырга артык теләге дә юк иде шикелле. Бәрәңге пешеп, чәй кайнагач һәм барысы да өстәл янына җыелгач, ул бөтенләй юашланып китте.

— Ике йөз грамм бит әле ул, кызым! — диде Хәмдиягә карап, үзенчә бик канәгать бер төс белән.— Ике йөз грамм күктән яумый хәзер. Җылап эзләсәң дә табалмыйсың аны. Атлар, бичаралар, аякларына да басалмыйлар. Нишлисең, дөрес сүзгә җавап юк: җирне шул көе калдырырсыңмыни?! Ярар, аллага тапшырдык, балалар.

Шулай сөйләнде-сөйләнде дә, иртәнге ашыннан канәгатьлек белдереп, амин тотып куйды, яулыгын рәтләде дә юлга әзерләнә башлады.

— Әнкәй, Әлтәфне иярт, ичмасам, — диде Хәмдия, әнисенең сүлпән хәрәкәтләрен күзәтеп. — Икегезгә бүлеп күтәрерсез.

— Ярар, шул кадәр җиргә бала интектереп йөрисем генә калганые! — диде әнисе, кинәт ачуланып.

Ул үзе югында нишләргә кирәклеге турында киңәшләр бирде дә, үзе өчен кайгырмаска, борчылмаска кушты да, кичәгенәк Көшләбигә алып барган капчыгын биленә кыстырып, амбарга китеп барды.

Хәмдия аны тәрәзәдән карап калды. «Нинди беткән! Нинди беткән!» дип уйлады ул ул әнисе турында, аның ничек атлавына игътибар итеп. Кызганудан аның күзләренә яшь килде. Ләкин күңелендә туган яңа бер тойгыны — үз өендә үзен чит итеп, кирәксез һәм гаепле итеп сизү тойгысын ул күз яшьләре белән дә бетерә алмады. Аның бернәрсәгә кулы бармады, бернәрсәгә күңеле бармады. Ә бераздан ул тиктомалга куркаөркә башлады. Аңа кемдер көтмәгәндә килеп керер дә, аның йөзен ертып, тирә-якка ишетелерлек итеп: «Менә, тотылдыңмы?!» дип кычкырыр шикелле тоелды.

Укырга киткәндә Әлтәф ишекне тыштан йозак белән бикләп киткән иде. Аңа гына ышанмыйча, Хәмдия чолан ишеген дә, өй ишеген дә эчтән бикләп куйды, әледән-әле урам якка, ишегалды ягына карап-карап алды, бала кычкырып елый башладымы — тизрәк аны тынычландырырга ашыкты. «Я раббем, үз өеңдә үзең куркып яшә икән!» дип уйлады ул әледән-әле, үзенең мондый хәленнән чиксез бер уңайсызлану тоеп.

Баласын кочаклап ул тәрәзә янынарак килеп утырды. Менә капчык тотып урамга Газимә дә килеп чыкты. Аның артыннан ук диярлек Шакир бичәсе күренде. Ә аның әнисе барысыннан да алдарак кузгалды. Ул һәрвакыт шундый булды. Үлмә хәлендә дә ул аяк өстендә булды, эштә булды, кырда-басуда булды. Ул һәрвакыт шундый. Аның балалары да шундый... булдылар...

Капчыклы хатыннардан соң күп тә үтмәде, елга буена, калкулык астына урнашкан ат фермасында да хәрәкәт башланды. Ат караучыларның кем беләндер кычкырышканнары ишетелде, ат чакырганнары ишетелде; кемдер, янбаш сөякләре очлаеп торган ябык сыерын житәкләп, түбән очка таба юнәлде. «Шәрифә, ахрысы», дип уйлады Хәмдия. Дөрес икән, чыннан да сыерлар белән сөрәләр икән. Бичараның муенына камыт кидерелгән, сыртына ыңгырчак салынган. Әйе шул, ферма утарында биш-алты аттан башка берни күренми. Дөрес икән...

Озакламый ферма ягыннан урам буйлап болай таба кыймылдаучы көтү күренде. Сыерлар, сарыклар бергә, бер көтүдә иде. Алар да, кешеләр кебек, хәлсез иде, ябык иде. Бөтенләй тавыш-тынсыз диярлек алар өй турысыннан шыбырдашып уздылар да, калкулык астына төшеп, күздән югалдылар. Бары тик көтүче малайның: «Чыгарыгыз!» дип кычкырган моңсу тавышы ишетелде дә, кайдадыр авыл читендә эт өргәне ишетелде.

Авыл уянды, авыл күзен ертты. Хәмдия, баласын кочаклаган көе, туган авылын күзәтте.

## XII

Котын алып, җанын өшетеп аның күз алдына әледән-әле дәһшәтле сораулар килде.

Нишләргә? Ничек яшәргә? Ничек балаңны карарга?

Әйе, көн дә шулай була торган булса, нишләргә, ни кыларга?

Әнисенең сүзенә ышанмаска аның хакы юк. Ул сиңа юри әйтмәс. Шулай булгач, кеше күзенә күренү турында, колхоз председателенәме, авыл советынамы барып ялыну турында уйларга да мөмкин түгел. Шулай булгач, аңа чыннан да... качып, яшеренеп ятарга гына кала! Ләкин ничек торырга, нәрсә белән туенырга? Карт анаңның соңгы сыныгына өлешкә кереп, эрәм тамак булып күпме яшәргә? Таза баштан, бер гаепсез көе...

Әллә соң сиздермичә генә кире тегендә китеп барыргамы? Эше таныш, жире таныш, кешеләре таныш.

Лэкин анда эшкэ алырлармы? Качып киткэн өчен, эшкә килми йөргән өчен судка бирмәсләрме? Әлбәттә, бирерләр! Бер көн эшкә чыкмаган өчен дә удмурт егете Илчебайны өч елга хөкем иттеләр. Бер көн өчен өч ел. Бер ай өчен күпмегә утыртырлар? Бер көн өчен өчәр ел бирсәләр, бөтен гомерең буе төрмәдә черерсең. Аннары, баланы нишләтергә? Аны монда калдырып булмый. Ул монда ачтан үләчәк. Монысы инде көн кебек ачык. Шуның өстенә, ул монда карт анага чиксез авыр йөк һәм газап булачак. Шулай ук аны тегендә алып китәргә дә булмый.

«Әгәр бөтенләйгә икенче бер җиргә китеп барсам?» дип уйлады ул бераздан, мәсьәләгә башка яктан карарга тырышып. Илдә чыпчык үлми. Берәр җиргә эшкә керер иде... Лэкин тагын шул ук балык башы: язу юк. Язусыз кем сине эшкә алсын! Кайда да язу кирәк, паспорт кирәк. Аның исә берние дә юк. Тегендә аларга паспорт бирмәделәр. Паспорт булса, кеше тизрәк качу ягын карый. Авыл советы биргән язу да аларда калды.

Шулай булгач... шулай булгач, аңа беркайда да юл юк. Шулай булгач, аңа кайда да төрмә.

Төрмә...

Ул инде күрде. Чын төрмәне күрде. Үз күзләре белән. Көн саен. Тегендә, урман эчендә... аларның бараклары янында гына, йөз метр чамасы җирдә генә... биек койма белән, тимер чыбыклар белән уратып алган төрмәне күрде. Аларның барагы да башта төрмә өчен дип салынган булган. Лэкин нишләптер анда иреклеләрне китереп тутырдылар. Барысы да авылдан, барысы да юаш... Ни кушсаң, шуны эшлиләр, кая кусаң, шунда баралар. Барысы да хатын-кыз. Ир затыннан ике-өч бүлтерек тә, солдатка ярамаган гарип-горәбә. Күршедә, тимер чыбык артында исә — барысы да ирләр. Эшкә алар еш кына янәшә атлап бардылар. Ирекләләр аерым төркем-төркем булып бара, алар — җыелып, команда белән. Алдан да, арттан да сакчылар. Ян яктан да сакчылар. Бүре чаклы этләр белән, автоматлар белән. Барысы да ябыклар, хәлсезләр. Коры сөяк тә тире. Аякларын көчкә өстериләр. Чыкмаган җаннары гына. Урман кисәләр, вагоннарга бүрәнә төйиләр. Баракларын җылытырга үзләре йомычкалап утын ташыйлар... куеннарына тыгып, күрсәтмичә... Койма почмакларында каланчаларда төне буе ут яна, автомат белән сакчылар йөреп тора. Төннәрен шарт-шорт аткан тавышлар ишетелә. Бараткагы кызлар котлары алынып уяна торганнар иде. Ә иртән, томанланып торган чатлама суыкта, чанага салып биек капкадан үлекләрне алып чыгалар иде. Таш булып, агач булып каткан, башларында чәчләре күренеп торган, җилфердәп торган кешеләрне... ничек туры килә шулай салып... өсләренә чыбылдык та япмыйча... туп-туры бараклар арасыннан, котлары алынган хатын-кызларның күз алдыннан... шыгырт-шыгырт китеп баралар иде. Аларны кайдадыр урман эчендәге тирән чокырга илтеп ташлыйлар дип сөйлиләр иде.

Менә шундый иде андагы төрмә. Ул үз күзләре белән күрде. Инде тагын күрергә язармы? Тфү-тфү, шайтан колагы саңгырау булсын!

## XIII

Җәмиләттәй Яңавылдан кичкә таба гына кайтып житте. Ишектән керде дә ян сәкегә ауды.

— Картый үлгән! — диде Әлтәф һәм кычкырып еларга да тотынды.

Хәмдия тиз генә әнисенең изүен, яулыгын чишеп җибәрде, биленә буган бавын чиште.

— Үлмәдем әле, балалар, — диде Җәмиләттәй, йомык күзләрен ачкандай итеп.

Шуннан башка ул бүтән берни әйтә алмады — башын артка ташлап, кулларын, аякларын хәлсез салындырып, как сәкедә хәрәкәтсез ята

бирде. Хәмдия тиз генә түр сәкегә урын җәйде, әнисенең өстен чишендерде дә күтәреп диярлек аны урынга илтеп салды.

— Әнкәй, бәгырем, нишләден? — диде ул, өзгәләнеп.

Ул анын кан тамырларын тотып карады, әле күкрәгенә, әле авыз турысына колагын куеп тыңлады, анын хәрәкәтсез калган аякларын, кулларын сыйпалады. Кисәк курку анын башына чыкты. Әнисе аңа чыннан да үлгәндер шикелле тоелды, һәм анын болай да өркетелгән күңелен кинәт дәһшәт биләп алды.

— Әнкәй! Ач күзеңне, әнкәй! — диде ул, әнисенең күкрәгенә капланып.

— Кызым, синмени? — диде Җәмиләттәй, каны качкан, бер-берсенә нык ябышкан иреннәрен авыр гына кыймылдатып. — Чәй бир... кайнар чәй.

Хәмдия, күзенә ак-кара күренмичә, җилтерәтеп сәкедән җиз самоварны алды, өстендәге тузанын өрде дә шап иттереп идәнгә, мич алдына утыртты, шаулатып су салды, күмер салды. Күп тә үтмәде, күңелсез өйгә җан кертеп, самовар гөрләргә тотынды. Беркадәр тынычлангандай иткәч, Җәмиләттәй яңадан күзләрен ачты, тормакчы булып башын калкытты. Хәмдия шундук анын янына килеп җитте — ике куллап тотты да урынга утыртты, утырырга җайлы булсын өчен, аркасына мендәр кыстырып куйды.

— Баш әйләнә, — диде Җәмиләттәй.

Озакламый чәй дә кайнап чыкты. Хәмдия тиз генә әнисенә кайнар чәй ясап бирде. Капчык төбендә тузанланып беткән бер-ике шакмак шикәре бар иде — шуны алып куйды. Күптән инде онытылган тансык тәм-том белән куе чәй эчкәч, Җәмиләттәйнең йөзе ачылып китте.

— Ярый әле син бар, кызым, — диде ул беренче сүзе итеп. — Рәхмәт. Болай булгач рәтләнермен инде.

— Алып кайттыгызмы соң? — диде Хәмдия.

— Кайттык, — диде Җәмиләттәй. — Бөртекләп тутырдык, кызым. Кимә тоткарлады. Шунда вакыт үтте. Чәчәрбез, иншалла. Җиркәй кысыр калмас. Бөртеген дә калдырмадык...

— Картый, Хәмдия апа, быел сугыш бетә! — диде Әлтәф кинәт кенә, утыра торгач. Күрәсең, анын да олылар сүзенә катышасы килә иде.

— Син нәрсә... каян ишеттең? Ничек? Кайчан?! — диде Хәмдия, каушагандай итеп.

— Рәхмәт яугыры,— диде Җәмиләттәй, Әлтәфне мактап.

— Ишеттем инде, — диде малай. — Баягынак Матнур бабай әйтте. Безнекеләр кичә Севастопольне алганнар. Куалар Гитлерны! Телефоннан наушниктан тыңлаганнар. Матнур бабай әйтте: быел көзгә сугыш бетәр инде, диде.

— Ә-ә! — диде Хәмдия, мәсьәләгә төшенеп. — Чынлап әйтәләрме әллә дип торам.

— Ник чынлап әйтмәсен, чынлап әйтте! — диде малай.— Матнур бабай кантурда ишеткән. Авыл буенча ялган таратып йөрмәс инде.

Алар шулай сөйләнгәләп утырганда, кемдер килеп, иртәнге кебек, урам як койманы шакылдата башлады.

— Җәмилә! Җәмилә килен! — дип кычкырды ниндидер ир кеше.

— Әнә ич Матнур бабай! — диде Әлтәф, урыныннан сикереп торып. Ул тиз генә тәрәзә каршысына килде.

— Нәрсә, Матнур бабай? Нәрсә бар?

— Җәмилә килен! — диде шул ук ир тавышы, ашыкмыйча гына. — Кантурга чакыралар. Яңавылдан кеше килгән. Заем хакында. Хәзер үк килергә куштылар... Җәмилә килен...

— Ярар, барырбыз! — диде Әлтәф, бар тавышына кычкырып.

— Кат-кат әйттермәгез, килен... барып кайтыгыз әйдә, — диде Мат-

нур бабай, артык кыстамыйча гына, ләкин шул ук вакытта тиз генә китәргә дә җыенмыйча. — Миннән әйтү, сездән бару, Җәмилә килен...

— Ярар, ярар! — диде Әлтәф тагын да.

Матнур бабай «килен»нең барачагына шулай да ышанды бугай — бүтән кычкырмады, өрәк кебек тавыш-тынсыз күршеләргә таба китеп барды.

— Әнә Матнур бабаңның хәбәре! — диде Җәмиләттәй Әлтәфкә. — Туксан ике тәңкә түлисем калганые. Өстә һаман бурыч булып тора. Болай гына булса да барып кайтмый булмас.

— Барырсың менә! — диде Әлтәф, картыйсына кычкырып. — Күзен дә ачалмый утыра үзе. Барырсың менә!

— Бармый ярамас шул, улым, — дигән булды картыйсы күндәм генә. — Тагын килеп җитәр инде ул. Дуамалга кеше интектереп йөрергә... Әлерәк кенә чакыртканнарые да соң, бер атнадан акчаңны әзерләп тор дигәннәрие. Бурыч бит, барып күренми ярамас.

— Иртәгә барырсың, әнкәй, — диде Хәмдия дә, киңәш итеп. — Миндә бераз акча бар — илтеп бирерсең.

Ләкин мондый сүзне ишеткәч, Җәмиләттәй чын-чынлап җанланып китте.

— Һай, кызым! Шул туксан ике тәңкәне каян алыйм икән дип башым катканые, илтеп түлим тизрәк! — диде ул, урыныннан торып. — Котылыйк, кызым. Өстә бурыч тормасын. Хәл керде инде. Барып кайтыйм әле.

Һәм ул мыштырдап өстенә киенә дә башлады.

— Мин дә синең белән барам! — диде Әлтәф, еларга җитешеп. — Үзеңне генә җибәрмим. Әнә шундый инде ул, Хәмдия апа — һич кеше сүзен тыңламый!

## XIV

Өйгә кайтканнан бирле баланың рәтләп тамагы туймады. Ана кешенең сөте бөтенләй диярлек юкка чыкты. Күкрәккә кушу белән бала һәрвакыт комсызланып имәргә тотынды һәм һәрвакыт үртәлеп, ачуланып ташларга мәҗбүр булды. Хәмдия, аптырагач, аңа үзе ашаган бәрәңге суын биргәләп карады, ләкин ят азыкка бала һич тә күнегә алмады. Ул күзгә күренеп начарланды. Аның хәзер елавы да елауга түгел, бәлки хәлсезләнеп шыңшуга, ыңгырашуга охшап калды.

Үзенең куркыныч хәле турындамы, әнисе турындамы, әллә баласының әкренләп ачка үлә баруы турындамы — Хәмдия нәрсә турында да кайгырырга белмәде. Бер кеше өчен бу бик күп иде, чамадан тыш күп иде. Шулай да аның өчен иң якыны, иң газизе бала иде.

Икенче көнне әнисе белән аның арасында шундый сөйләшү булды.

— Әнкәй, карале, — диде Хәмдия, — минем сырмага күпме бирерләр икән?

— Нинди сырма? — диде әнисе.

— Тегеннән киеп кайткан сырма соң. Ничә литр сөт бирерләр икән шуңа?

Әнисе аңлап алды, берни әйтмичә, чөйдәге сырманы кулына алды да аның эчен-тышын әйләндергәләп карады, кесәләрен актарды. Сырма әле яңа иде. Ул бары юлда кайтканда бераз керләнгән генә иде.

— Бигрәк җиңел! Мамык белән сырган бугай, — диде әнисе, сырманы мактап.

— Мамык белән бугай шул, — диде Хәмдия.

— Бигрәк әрәм инде сатсаң да, — диде әнисе. — Сөт дип... кем сиңа сөт кенә бирер икән хәзер?

— Әрәмен әрәм дә, нишлисең? — диде Хәмдия уйчан гына. — Балага сөт кирәк. Ашата башларбыз. Болай булмый, әнкәй.

— Бүтән нәрсәң юкмы соң? — диде әнисе, сырманы кызганып.

Хәмдия әнисенең тел төбен бик яхшы сизенде. Өченче көнне дә ул сырманы мактый-мактый караштырып торган иде. «Бүтән нәрсәм бар соң минем?» дип уйлады ул, күңеленнән кием-салымын барлап. Күлмәкнең рәте юк. Аякка киеп кайткан ирләр ботинкасы да сырган чалбар кала. Анысы да ирләрнеке. Урман кискәндә биргәннәр иде. Ләкин алар искерәк шул.

— Ярар, әнкәй, сиңа булсын сырма, — диде ул, тәвәккәлләп. — Җылы өстеңдә тузсын. Рәхәтен күр. Мин инде сырган чалбарлар, ботинкалар киеп йөрмәм — шуларны сатарбыз.

— Рәхмәт яусын инде, кызым, — диде әнисе, балалардай куанып. — Саклап кына тотармын инде, кадерен белеп кенә. Өстемдә бер нәрсәм калмады бит, кызым, кеше арасына чыгарга оят.

— Ник сакларга — киярсең, әнкәй, — диде Хәмдия.

— Белмим шул, — диде әнисе, кинәт сүрелеп. — Белмим шул кызым. Дөньялар иминләнмичә киеп булыр микән? Күрсәләр шикләнүләре бар.

Хәмдиянең шундук йөзе караңгыланып китте. Бала онытылды, әнисе онытылды, һәм йөрәкне урталай ярырлык бөтен дәһшәте белән күз алдына икенче бер хакыйкать килеп басты.

— Юкка куркасың син, әнкәй! — диде ул, ачынып. — Котың алынып беткән синең. Үз кимеңне үзең киеп йөрергә дә куркып яшә икән! Нинди тормыш бу?! Нинди заман бу?! Менә күрерсең, хәзер үк урамга чыгып китәм, хәзер үк кантурга барам, фермага төшәм! Нинди эш бу?! Сабый балам белән ачтан үләргә тиешмени мин?!

— Кызмале син, — диде әнисе ачусыз гына. — Өй турысыннан кешене узган чак булыр.

— Булсын! — диде Хәмдия, ярсып. — Узсын, теләсә кем узсын!

— Яңавылга барсаң, он-фәлән алып кайтырга булырые да, юлга чыгарга йөрәгем җитми, — диде әнисе тыныч кына. — Кем алыр икән соң боларны? Мәликә корткага барып карыйм микәнни?

— Теләсәң кемгә бар, әнкәй, — диде Хәмдия, беркадәр басыла төшеп.— Сөт сора, сөт... Балам бетә, балакаем бетә бит, әнкәй!

## XV

Мәликә кортка әйберләрне теләмичә генә алды: кирәкми, диде, иске, диде. Ялына торгач, шулай да риза булды. Җәмиләттәй алып барган әйберләр өчен ул «кызганып» бер пот бәрәңге, биш кадак он һәм бер литр сөт бирде.

Кичен ярлы өйдә ярлы гына, тыйнак кына бәйрәм булды. Хәер, бу бәйрәм күбрәк балаларга кагылды. Күңеле күтәрелеп киткән Әлтәф Хәмдия апасы белән картыйсына көндәгечә сугыш яңалыклары сөйләде һәм кичәге хәбәренә үзенчә төзәтмә ясап: сугыш быел көзгә дә калмас әле, җәй урталарына бетәр, дип куйды. Ирек җылыткан сөтне яратып эчте һәм тамагы туйгач та кинәт кенә үзгәреп китте: көлде, «әннә» диде, «мәммәм» диде, кулларын бутап, идәнгә төшәргә сорады.

Балаларның куанычы олыларга да йокты. Ашап туйгач алар, өстәл яныннан кузгалып китәргә иренеп, канәгать бер кыяфәттә, елмаешып балаларны күзәтәләр.

— Менә ул кемнәр яши! — диде Җәмиләттәй, үз алдына сөйләнеп. — Барып кердем өйләренә — яңа пешкән ипи исе чыккан. Сәкедә ипи... өстәлдә ипи... күзгә алучы да юк. Мәликә кортка ашамый, кем ашасын! — Факиясе бригадир, чулак малае амбарда эшли, ире — ат караучы. Менә шуларны утыртыргае да төрмәгә, юк, көчленеке замана.

— Сөйләмәле, әнкәй, шул төрмәләр турында,— диде Хәмдия, чырае бозылып. — Болай да инде... Дошманыңа да күрсәтмәсен.

— Дошманыңны да утыртмагач, ник ясаганнар аны? — диде Җәми-

ләттәй. — Син мендә монда ачка шешенеп ят, ул анда калхузныкын урлап, баеп ятсын — алай да тигезлек түгел шул, кызым.

— Шулай да соң...— диде Хәмдия, килешкән сыман итеп.

Шуннан башка ул сүз озайтып тормады. Хәзер аның бәхәсләшәсе дә килмәде, зарланасы да килмәде. Аның шулай тыныч кына, оеп кына өстәл янында балаларга карап утырасы килде. Бер уйлаганда, адәм баласына әллә ни күп тә кирәкми инде. Өстәл янына утырган саен көн дә шулай тамагың туйганчы ашый алсаң, көн дә шулай аяк астында куанышып балаларың уйнап йөрсә, шуннан башка тагын нәрсә кирәк? Эх, һәрвакыт шулай булсачы!

Ләкин, кызганычка каршы, һәрвакытта алай була алмады. Ярлы өйдәге ярлы бәйрәм көннәрдән бер көнне тәмам булды. Базда бары орлыкка дип кадерләп саклаган, уршып беткән, үреп беткән өч-дүрт чиләк чамасы бәрәңге калды да, өй эчендә һич тә туя белми торган олыкече өч-дүрт тамак калды.

Ул көнне Әлтәф укырга кайнар су гына эчеп китте, ләкин бер-ике сәгать узмады, ашыйсы килә дип, баш әйләнә дип кире кайтты. Ирек исә әнисенең буш янчыкларын суырды-суырды да, берни килмәгәч, гадәтенчә еларга тотынды. Ул бик озак елады — әле усалланып таләп итте, әле хәлсезләнеп үксергә тотынды, әле күзләрен йомган килеш, ярым йокыга киткән килеш, уймак кадәр иреннәрен чупылдатып-чупылдатып алды.

Хәмдия нишләргә дә, нәрсә кыларга да белмәде. Ул акылдан шашуга якын бер гамьсезлек һәм өметсезлек кичерде. Эчтән аның йөрәгендә кан сауды, күкрәгендә ялкын дөрләде, тау-ташлар актарылды, тыштан исә ул катып калган шикелле күренде. Әйе, ул бернәрсә дә эшли алмады. Улына да, Әлтәфкә дә, әнисенә дә ул берничек тә ярдәм итә алмады. Бу минутта ул үзе турында уйламады да.

— Туктале, кантурга барып карыйм әле булмаса,— диде Җәмиләттәй, үзенчә бер фикергә килеп.

— Барып кара, әнкәй,— диде Хәмдия дәртсез генә.

Җәмиләттәйнең анда барганы бар иде инде. Көн саен бармаса да, атна саен бара иде. Әмма монысында ул иң соңгы өметләр белән, иң изге догалар белән китте. Шулай да аңа дога ярдәм итмәде. Гадәттәгечә, көченнән килмәде. Колхоз идарәсендә җавап бик кыска булды: юк, берни юк, диделәр аңа.

Җәмиләттәйнең кире өйгә кайтасы килмәде. Сөмсере коелып, күңеле кырылып ул шунда идарәгә җыелган хатын-кыз арасында таптанып тик торды. Тора торгач, үзе өчен ул шунда бер яңалык белде.

— Түбән очлар әлмә кабыгы ашыйлар икән,— диде ул, өйгә кайткач.— Мин дә барып карыйм әле.

— Бар, әнкәй,— диде Хәмдия, дөньядан ваз кичкән бер гамьсезлек белән.

Җәмиләттәй кулына балта алды, Әлтәфне ияртте дә урманга китте. Бер-ике сәгатьтән алар яшь әлмә чыбыклары өстерәп кайтып та җиттеләр. Чыбыкларны туп-туры өйгә алып керделәр, җыйнаулашып кабыгын телделәр, турадылар, вакладылар. Юдылар да казанга салдылар.

Әлмә боткасы бик озак пеште. Кайный-кайный ул, чыннан да, ботка сыман аксыл нәрсәгә әйләнде. Ләкин ул ботканы кабып карагач, лайлалы кабык тәменнән башка аннан бүтән бернинди туклыклы тәм килмәде.

— Кеше белми ашамыйдыр әле,— диде Җәмиләттәй, балаларның күңелен күтәрмәкче булып.

«Әлмә кабыгын бәрәннәр дә ашый бит... сарыклар да...» дип уйлады Хәмдия, үз-үзен ашарга мәҗбүр итеп. Алар ашагач, ник кеше ашамаска тиеш? Барыбер тамак бит... барыбер җан иясе.

## XVI

Элмә боткасы ашалды, ләкин кешеләрне ул барыбер ачлыктан коткара алмады. Кичкә Җәмиләттәй баздан орлык бәрәңгесен алып чыкты. Бәрәнге суы өлгергәнче беркем берни сөйләшмәде. Һәркем түземсезлек белән казан ягына караштырды. Хәтта Ирек тә, олыларның хәлен аңлагандай, шыңшуыннан туктап торды. Хәер, аның инде тавыш чыгарырлык рәте дә калмаган иде. Ул, әйтерсең, бары әнисенең тән жылысы белән генә җан асраштыра иде. Әмма олылар өстәл янына җыелгач, бала ныграк шыңшырга тотынды.

— Хәзер, улым, хәзер! — диде ана кеше, аңа ашатырга бәрәнге суы әзерләп.

— Үлсә, ичмасам, оҗмах кошы булырые,— дип куйды шул чакны Җәмиләттәй.

Бу ничектер бөтенләй көтмәгәндә, уйламаганда әйтелде. Хәмдия, яшен суккан кебек, кинәт калтыранып китте. «Карале, нинди дошман икән бу әнкәй! Юри генә яраткан булып кылана икән баланы», дип уйлады ул, күңеле өшеп.

— Син нәрсә... әнкәй... уйнап сөйлисеңме, уйлапмы? — диде ул тыелып кына, ләкин усал һәм явыз итеп.

Өйгә кайтканнан бирле бу аның әнисенә беренче мәртәбә каты орынуы булды.

— Шул кадәр газапланганчы димен шул,— диде әнисе ачу китергеч бер тынычлык белән.

— Әнкәй, ишетсен колагың, икенче әйтәсе булма! — диде Хәмдия, бурлаттай кызарынып.

— Күз алдында үлеп бара бит, сабыйкаем,— диде әнисе.

— Әнкәй! — диде Хәмдия.— Әйтмә! Әйтмә шул сүзне!

— И, кызым,— диде әнисе.— Үлсә, ичмасам, котылырыең... Ничек күмәрбез — менә шул турыда кайгырам әле мин.

— Әнкәй! — диде Хәмдия, тагын да дәһшәтлерәк итеп.— Кансыз! Оятсыз! Шул сабыйны... бичараны... ничек... ничек?..

Әйтәсе килгәнен әйтергә ул сүз тапмады, сүздән бигрәк, көч-куәт тапмады. Кинәт килеп койган яңгыр булып, кинәт ишелеп төшкән кыя булып аның күңеленә ачу-ярсу һәм тилелек килеп ябырылды. Ул әйтергә сүз тапмады. Баласын кочаклады да, урыныннан атылып торды да, тыелудан тәмам тәкатьсез калып, читлектәге җанвар сыман, әрле-бирле идән буйлап йөренергә тотынды.

«Юк, юк, болай булмый! Болай яшәргә мөмкин түгел! — диде ул үз-үзенә, күз яшьләренә буылып.— Мөмкин түгел! Туйдым-җиләдем... Житәр! Ярамый болай... нәрсәдер эшләргә кирәк. Нәрсәдер уйлап табарга кирәк!»

— Ярар, утыр инде,— диде әнисе юаш кына, иплән кенә.—Аптыраганнан әйтәм, кызым. Утыр, аша. Бер дә үтерәсем килеп тормый. Аптыраганнан...

— Хәмдия апа! — диде Әлтәф, өстәл башында утырган жиреннән, нечкә муенын сузып.— Хәмдия апа! Сукачыларга ике йөз грамм ипи бирәләр, аш пешерәләр. Иртәгә үзем сукага китәм! Ипине алып кайтам, Ирекка чәйнәп ашатырбыз.

— Һай, рәхмәт яугыры! — дигән булды Җәмиләттәй. — Сукага сыерлы кешеләр генә йөри шул. Сыер урынына мине жигәрсең микәнни соң?

Мондый сүзгә малай аптырабрак калды.

— Актауда әнә хатыннар көрәк белән казыйлар ди жирне,— диде ул шулай да, җавапсыз каласы килмичә.

— Бәрәңге бакчасын казыйсы да бар әле,— диде Хәмдия, сүзгә катышып.

— Белмим инде, — диде Җәмиләттәй. — Бар карап торган шул бакча. Ходай ни язды инде — утырта алырбызмы, юкмы.

Шулай сөйләнеп утырганда алар чолан ишегенең дә, өй ишегенең дә ачылганын ишетмичәрәк калдылар.

— Исәнмесез. Нәрсә шаулашасыз? — диде кинәт ишек төбендә нинди дер ят кеше.

Өйдәгеләр, куркып, котлары алынып, шундук ишек ягына борылып карадылар һәм шул чакны ярым караңгыда елмаеп басып торган юан гына, тәбәнәк кенә бер хатын-кызны күреп алдылар.

— Ә-ә.. Бибехәят икән! — диде Җәмиләттәй, каушавын сиздермәскә тырышып.— Әйдә, түрдән уз.

Әлтәф күзләрен акайтып картыйсына бер карап алды да уктай атылып тышка чыгып китте. Тиз арада ул чолан ишеген бикләп тә керде һәм авызын күптереп:

— Бикләмәгән! Үзе арттан керде — бикләмәгән! — диде картыйсына.— Ышан син а!

— Җә, утыр тик кенә! — диде Җәмиләттәй, малайга ачуланып.— Кеше кергәч шулай сөйләнәләрмени?

— Нәрсә булган? Әллә караклардан курка Әлтәф? — диде шат күңелле Бибехәят апа, берни аңламаган булып.

— Йөри шунда! — диде Җәмиләттәй.— Утыр урыныңа, ташбаш.

— Кара! Үзләре әйттеләр! — диде малай, үпкәләп.

Шул чакны күрше хатыны ишеккә арты беләнрәк, башын иебрәк торган Хәмдияне күреп алды. Күреп алды да, улмы, түгелме дигән сыман, беравык күзләрен зур ачып карап торды һәм бары шуннан соң гына, түргәрәк узып:

— Хәмдия түгелме соң? — диде.— Исәнме, Хәмдия. Кайчан кайттың? Исәнме-саумы...

— Исәнме, Бибехәяттәй,— диде Хәмдия, кызарынып.

Башын калкытты да, күрешер өчен, керүчегә таба атлап куйды.

— Дөнья булгач, югалган кешеләрне дә күрәсе бар икән,— диде Бибехәяттәй.

Шулай диде дә, телен йоткандай, кисәк кенә сүзсез калды, каушап калды һәм тәрәзә янындагы артсыз урындыкка утырды да, яулык очы белән ак төшкән уң күзен каплап, еларга керешге.

— Исән булса, Азатым да кайтырые,— диде, борынын тарткалап.

Өй эчендә авыр тынлык урнашты. Барысы да, күршеләренең кайгысын уртаклашып, әдәп саклап тын гына утырдылар.

— Язмыштыр инде, Бибехәят,— диде Җәмиләттәй, көрсенеп, тынлыкны бозып.

Бибехәяттәй бераз гына балавыз сыкты да язгы кояш кебек ачылып та китте — ул алай озак кайгырып утыра торган кешеләрдән түгел иде.

— Карале, әллә баласы да бар? — диде ул, исе китеп.

— Бар, дүртәү булдык, Бибехәят, — диде Җәмиләттәй, ясалма бер куаныч белән куанып.

— Бигрәк матур сабый икән, күз тимәсен! — диде Бибехәяттәй, бала янынарак килеп.— Бала белән юлда кыен булгандыр, Хәмдия? Ничек кайттың соң? Син безне онытсаң да, без сине онытмадык. Җәмиләдән белешеп кенә тордым. Хат та язмадың. Нәрсә булды? Әйдә, тормале шулай каш астыңнан карап. Син белмәгән Хәмдия түгел, мин белмәгән Бибехәят түгел.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның, Бибехәяттәй,— диде Хәмдия, теләр-теләмәс кенә.— Менә... улым белән кайттым. Икәү без хәзер.

— Бибехәят, әйдәле ашарга утыр әле,— диде шул чакны Җәми- ... ынга чакырып.

## XVII

Ул кичне Бибехәяттәй күршеләрендә шактый озак утырды. Сөйләшә торгач, ул үзе өчен күп кенә яңалык ишетте. Аннан да бигрәк, яңалыкларны ул үз күзләре белән күрде. Аның йөрәге әрнеде, аның йөрәге сызланды.

— Башта ук керсәгез нәрсә булгандыр! — диде ул, хуҗаларны шелтәләп.— Күрәләтә бала үтереп яталармыни?! Без ничек тә түзәрбез. Без инде карт агачлар... кештер-кештер, мыштыр-мыштыр йөрештерәбез. Сабый ничек түзсен? Сыерым әле сөт бирә. Теләп кенә торыгыз... сабый бәхетеннән... тамчысы да җәл түгел.

— Рәхмәт инде, Бибехәят,— диде Җәмиләттәй, куанычыннан нишләргә белмичә.— Сезнең үзегезнең дә балаларыгыз җитәрлек... Рәхмәт инде.

— Ул балалар аякка баскан инде,— диде Бибехәяттәй, бер дә исе китмичә.— Аларга хәзер сөт эчәргә ярамый. Ашасыннар әнә черек бәрәңге! Көн дә кереп алыгыз. Кермәсәгез, үзем кертермен. Тамчысы да җәл түгел.

— Рәхмәт, Бибехәяттәй, — диде Хәмдия дә, тыелып кына.

Бибехәят апа өйдәгеләрне шулай куандырды да, шаулап, уен-көлке сөйләнеп кайтып китте һәм күп тә үтмәде, ярты литр пыяла банка белән сөт күтәреп, алъяпкыч итәгенә беркадәр бәрәңге салып, яңадан кереп җитте.

Ниһаять, баланың тамагы туйды. Тынычлап ул шундук йокыга китте. Олылар да ул көнне үзләрендә беркадәр тынычлану, иркенәю кебек нәрсә тойдылар.

— Андый тишек авыз! Бөтен авылга сөйләп йөрер әле,— диде Әлтәф кенә, күрше әбисенең шулай җиңел генә кереп-чыгып йөрүен бик үк ошатмыйча.

— Сөйләмәс,— диде Җәмиләттәй, нык итеп.— Бибехәят андый түгел. Карты да, балалары да сөйләмәс. Алтын кешеләр алар!

«Әйе, алтын кешеләр», дип уйлады Хәмдия, әнисе белән килешеп. Әбит кайчандыр ул аларның килене булырга ниятләнеп йөрде... Юк, Хәмдия турында ул берни сөйләмәс! Күрше буларак та алар гомер-гомергә дус-тату яшәделәр: бер-берсенең гайбәтен сатмадылар, бер-берсе белән беркайчан телгә-тешкә килмәделәр. Ә инде көннәрдән беркөнне Азат белән Хәмдиянең үзара мөнәсәбәте ике якка да мәгълүм булгач, элекке дуслык-татулыкка тагын да җылырак тойгылар өстәлде. Һәр ике як аларның дуслыгын хуп күрде, һәр ике як яшьләргә бәхет-куаныч теләде һәм акренләп-акренләп кенә, артык шауламыйча гына киләчәк туйга әзерләнә дә башлады. Ләкин туй була алмый калды. Туй урынына мәхшәр башланды. Бөтен илдә мәхшәр башланды.

«Нинди кыска булды синең гомерең, бәгырем!» дип уйлады Хәмдия, төн карасы аша үткәннәргә күз салып.

Әйе, кыска булды, бик-бик кыска булды. Аны сугышның беренче көннәрендә үк алдылар. Ул китеп күп тә үтмәде, аның турында язу килде. Хәмдия ул язуны үзе укып чыкты. «Муллануров Азат батырларча һәлак булды», диелгән иде анда.

Шулай, Муллануров Азат сугышта үлде, батырларча үлде. Ул инде күптән җир куенында ята.

Шулай ук аларның мәхәббәте дә бик-бик кыска булды, үкенечле булды.

Кырык беренченең бөркү июнь төне Хәмдиянең хәтеренә мәңге сеңеп калды. Бүә буенда, Очлы тау итәгендә... тирә-якта тоташ кара урман иде... һавада бал исе, печән исе аңкый иде. Аяк астында елкылдап, пышылдап акрен генә Бүә ага иде... Сандугачлар сайрый иде, чикерткәләр сайрый иде. Яр буенда караеп [illegible] Ул

вакытта алар болында төн кунып эшлиләр иде. Берәүләр печән чаба, икенче берәүләр печән җыя иде. Эш тә түгел иде ул — бәйрәм иде, сабан туе иде...

Олыраклар йоклап беткәч, алар төне буе яр читендә утырдылар. Аста Буә ага иде... түбә өстендә тишкәләнеп беткән кара күк табагы капланып тора иде. Аһ, нинди гүзәл, нинди татлы иде ул төннәр!

«Мин гаепле, Азат, синең алда, бик гаепле», диде ул, еpактагы изге хатирәләргә эндәшеп.

Бик гаепле... Ул чакта ул ахмак булды. «Минеке бул!» диде аңа ул чагында Азат. Сузма, өйләнешик, бергә-бергә тормыш корыйк, диде. Ә ул сузды. Үзе дә аңламастан, бер дә юктан сузды. Бөркү татлы июнь төнендә ул аңа каршы килде. Азат әйтте: үлсәм дә үкенмәс идем, жаным! — диде. Нәкъ әкияттәгечә булды: ул үлде, мәңге үкенеч белән, мәңге үпкә белән үлде. Саф көенчә үлде, керләнмәгән сабый бала кебек үлде. «Мин гаепле синең алда, Азат!»

Хәмдия ул чакларда бераз гына кырыс булды, кыргый булды. Алар халкының күпчелеге кырыс. Татар кызы гомер-гомергә кырыс булган, горур булган. Татар кызы гомер-гомергә тыйнак булган, турылыклы булган. Ул да тыйнак булды, турылыклы булды. Ләкин... кем белгән соң аның менә болай булып бетәсен!

Азатның үле хәбәре килеп биш-алты ай вакыт узмады, яраланып Мидхәт кайтып төште. Хәмдиягә ул үзенең якын дусты турында сөйләде, аның кайчан, ничек үлүе, кайчан, ничек күмелүе турында сөйләде. Хәмдия аны елый-елый тыңлады. Бу сөйләшү аның күңел ярасын яңадан кузгатып җибәрде. Ләкин шул ук вакытта бу сөйләшү андагы «бәлки исәндер әле» дигән яшерен өметләрен бөтенләй диярлек юкка чыгарды. Аннары, Азатның сугыш иптәшен сау-сәламәт килеш күрү, аның белән әледән-әле очрашып тору күп нәрсәне онытырга мәҗбүр итте.

Мидхәтнең кайбер нәрсәләрен — аумакайлыгын, вәгъдәсезлеген — ул моңарчы бик үк яратып та җиткерми иде, шуңа күрә алар арасында кайчагында әйткәләшүләр дә булып алгалый иде. Ләкин шулай да алар дошман түгелләр иде. Хәзер уртак кайгы аларны тагын да ныграк якынайтып җибәрде. Һәм көннәрдән беркөнне Мидхәт аңа үзенең мәхәббәтен белдерде. Үлгән артыннан үлеп булмый, диде, минеке булсаң, мин сине уч төбендә генә йөртермен, диде.

Ул риза булды. Башы-күзе әйләндеме, күрәчәге булдымы... ул риза булды. Кем белә, бәлки, сугыш шаукымы да тәэсир иткәндер — Мидхәт кебекләр авылда бармак белән санарлык та юк иде бит! Анын урынына, кызлар оялары-оялары белән торып калдылар... яшь-яшь чибәр кызлар, күз яшьләрен түгеп, ялгыз калдылар...

Әйе, ул риза булды. Бары тик Мидхәтнең анасы гына риза булмады. Бердәнбер улына ул күрше Ушия-таудан үзенә ошаган «булдыклы» кыз ярәште. Хәер, Мидхәт үзе дә Ушия-тауга барып йөргән. Беркөнне Хәмдия белән очрашса, икенче көнне Рәбига белән очрашкан. Хәмдиягә анасы соңыннан үзе ишеттерде: усал дигән, телчән дигән...

Аһ, нинди оят, нинди хурлык булды шул чагында! Кем уйлаган аны шул кадәр үк икейөзле булыр дип, кем уйлаган аны шул кадәр үк оятсыз булыр дип?!

Менә шул. Ә бер атнадан аларны читкә озаттылар...

## XVIII

— Мин бернәрсә уйладым әле, кызым,—син нәрсә әйтерсең тагын,— диде Җәмиләттәй икенче көнне иртән йокыдан торгач.— Сырманы сатарга туры килер. Башка чара калмады.

— Кемгә? Мәликә корткагамы? — диде Хәмдия.

— Хәзер базарга китәм. Яңавылга.

— Тагын үлеп кайтыргамы? Юк, әнкәй, җибәрмим. Синсез нишләрбез без монда?!

— Мәликә корткага бер дә аягым тартмый,— диде Җәмиләттәй.— Карун... ач күз... Мыскыл итеп тагын бер пот бәрәңге биреп җибәрер. Үлмәм әле, кайгырма. Базар үзенекен әйтер. Озакламый кузгалак чыгар, какы, балтырган чыгар. Баланың кайгысы китте. Шулай итеп, ничек тә яңа ашлыкка барып җыгылырбыз әле. Кайтканда Уразы аша кайтырмын. Кичтән Уразыда кунармын, иртәгә иртүк үзебезгә кайтып төшәрмен. Мине алай югалтып ятмассыз.

— Белмим шул, әнкәй,— диде Хәмдия, икеләнгәндәй итеп.

Сырма турында инде ул үзе дә уйлаган иде, тик әлегә әнисенең хәтерен калдырасы гына килмәгән иде.

— Уразыга керәсе булгач... барырсың инде, әнкәй, — диде ул бераздан, килешергә мәҗбүр булып.

Җәмиләттәй әзерләнде дә «аллага тапшырып» китеп тә барды.

Әлтәфне мәктәпкә озаткач, баласын туйдыргач, Хәмдия урыннарын җыештырды, чоланга чыгарып әйберләрнең тузаннарын каккалады. Барлы-юклы эшләрен бетерде дә улын кулына алды.

Менә алар тагын икәү генә калдылар. Әннәдән башка кеме бар аның? Беркеме юк. Тегендә дә икәү генә, монда да икәү генә. Юлда да икәү, өйдә дә икәү. Нинди кансыз була кайчагында карт кешеләр, улым! Ничек әйтә алды икән картый шундый коточкыч сүзләрне? Юри генә әйтте микән, кызганып кына? Тегендә дә әйткәләгәннәр иде аңа андый сүзне. Ә бит баштарак әннә кеше үзе дә шуны теләгән иде! Әйе, әйе, ул үзе дә аның үлүен теләгән иде. Анықын гына түгел, үзенең дә үлемен теләгән иде. Үзенең авырга калганлыгын белгәч тә ул үз-үзенә кул салмакчы булган иде. Чын-чынлап. Берни уйламыйча, үкенмичә... кызганмыйча. Кояш инде сүнгән иде, дөнья тәмам беткән иде. Рәхмәт яусын мукшы хатынына. Агач арасында ул очрады. Ул сизенде... ул арттан килде. Ул ирек бирмәде. Рәхмәт яусын аңа!

«Менә шулай саклап калдым... саклап килдем мин сине, улым,— диде ул күңеленнән, улы белән сөйләшеп.— Инде шул кадәр карап үстергәч, инде сине кеше иткәч... Картый ахмак!..»

Ләкин хәзер инде аңа беркем андый сүзне әйтмәячәк. Хәзер аның ике картыйсы бар. Бер әннәсе, бер абыйсы, ике картыйсы бар. Нинди бәхетле ул хәзер! Аның өчен картыйлар ике яклап тырышалар. Әнә берсе үлмә хәлендә ерак юлга сәфәр китте, икенчесе янда гына... икеөч өй аша гына... кирәк икән, хәзер кереп житәчәк ул.

Көне буена Хәмдия шулай үз-үзе белән сөйләште, улы белән сөйләште. Кинәт кенә идән уртасында, я булмаса тәрәзә каршысында туктап калды да онытылып уйларга тотынды. Аның уйлары өйдә, авылда гына тукталып калмады. Уйлары, йөгерек җил кебек, Урал артындагы сазлы урманнарга барып кайтты, Бүә буйларында йөрде, күршеләрендә тукталгандай итте дә каядыр читкә — иркен басуларга, кырларга чыгып китте. Ул хәзер элеккегә караганда тирәнрәк итеп, төплерәк итеп уйлады. Көтмәгәндә Бибехәяттәйнең килеп керүе, көтмәгәндә аңа шулай ярдәм кулы сузуы аның берничә көн эчендә ныгып житкән кайбер карашларын, фикерләрен юкка чыгарды. Ул дөньяга киңрәк, ачыграк күз белән карый башлагандай булды. Анда үз-үзенә карата, кешеләргә, дөньяга карата ышаныч барлыкка килә башлагандай булды. Ул үзенең болай качып-посып, яшеренеп яшәвенең мәгънәсезлеген төшенгәндәй булды. Шулай булмыйча! Илдә каты сугыш бара, кайда да эш кешесе кирәк. Тегендә эшләсә ни, монда колхозда эшләсә ни — барыбер түгелмени? Ул бит юри кайтмады монда. Ул кайтырга мәҗбүр булды. Ул баласы өчен кайтты! Аңларга тиешләр ләбаса шуны!

Кичкә таба, вәгъдә итүенчә, балага сөт күтәреп Бибехәят апа килеп керде. Бу юлы ул Хәмдия янында озаграк, иркенләбрәк утырды. Азатны искә төшереп, тагын бер-ике мәртәбә күз төпләрен юешләтеп алды. Яратып, үз итеп баланы сөйде, бала карау буенча кайбер киңәшләр бирде. Баланың икенче картыйсы янында, үзенең була алмаган кайнанасы янында бүген Хәмдия үзен иркенрәк хис итте. Алай гына да түгел, ул үзендә гаҗәеп бер күтәренкелек тойды.

Күршесе чыгып киткәч ул, кызларча җиңел-җиңел атлап, Салкын чишмәгә суга китеп барды. Караңгы төшү белән ул һәркөнне шулай чишмәдән су алып кайта иде. Ләкин бүген ул ныклап торып караңгылатканны да көтеп тормады. Бүген ул, ниһаять, тиешле карарга килде.

## XIX

Урамда ана беркем очрамады. Авыл инде йоклый иде. Бик сирәк йортларда гына җемелдәп кызгылт утлар күренә иде дә, бик сирәк ишегалларында гына эт өргәне, я булмаса песиләр елаганы ишетелә иде. Кичләрен шаулап-гөрләп тора торган клуб ягында да бүген тынлык һәм караңгылык хөкем сөрә иде.

Шулай да югары урамдагы биек йортның зур тәрәзәләрендә әле балкып ут яна иде. Бу элекке мәчет иде, анда хәзер колхоз идарәсе урнашкан иде. Караңгы урамнан, караңгы чокыр буеннан шундый якты җиргә килеп чыккач, Хәмдия кинәт каушап калгандай булды. Ары барыргамы, юкмы икәнлеген белмичә ул койма буенда тукталгандай итте.

Димәк, кайтып китмәгәннәр. Нишләп утыралар икән — җыелыш микән, әллә болай гына шаулашалар микән... нәрәт алып, нәрәт биреп... иртәгә эшлисе эшләр турында сөйләшеп?.. Кемнәр булыр анда — бригадирлар, ферма мөдирләре, хисапчылар? Ләкин аңа бит председатель генә кирәк, баш кеше генә, иң олы кеше генә... Ничек итеп аның үзен генә туры китерергә?

Урам ягындагы ишектән чыгучы-керүче күренмәде. Шулай ук якынтирәдә дә бернинди җан әсәре сизелми иде. Хәмдия беркадәр тынычлангандай булды, кузгалып китте дә бер-ике атлауда биек баскыч янына килеп җитте. Баскычтан менде. Ләкин ишек янында ул яңадан туктап калды.

Ә бит кайчандыр бу ишекләрне ул орып-бәреп кенә йөри торган иде. Кайчандыр аның бу йортта ярты төнгәчә җыелышларда утырганы бар иде. Ул чакларда аңа сөйләргә, «тәнкыйть итәргә» үзләре кушалар иде. Ул үзе дә алай бик үк ялындырып тормый торган иде — кемнең кем булуына карамастан, йөзләренә бәреп әйтә торган иде.

«Керим әле», диде ул үз-үзенә, күпмедер вакыт шулай икеләнеп торганнан соң. Ишекне тартып җибәрде дә ишек төбеннән үк башланган тар, биек баскыч буенча югары менеп китте. Өстә чолан сыман зур гына бүлмә бар иде. Монда караңгы, салкын һәм аулак иде. Берничә адым атлагач ул яңадан икенче бер ишек алдына килеп туктады.

Монда ул шактый озак басып торды. Куркудан, шүрләү-шикләнүдән аның еш-еш йөрәге типте, колагы шаулады. «Әллә беркем дә юк инде?», дип уйлады ул, ишек артына колак салгандай итеп. Шыгырдамаска тырышып ул ишекне иплән кенә үзенә таба тартты. Капка кебек зур авыр ишек әкрен генә ачыла башлады, һәм шул чакны Хәмдиянең йөзенә кисәк кенә яктылык бөркелде.

Ул көткәнчә, монда бернинди җыелыш та юк иде, шаулашып тәмәке тартып утырган кешеләр дә юк иде. Бүлмә эче буп-буш иде. Бары тик түрге яктагы озын өстәл янында гына иелеп, нидер язып хисапчы утыра иде дә, аның каршысында, бу якта бер ир кеше басып тора иде. Ул, ахрысы, хисапчының эше беткәнен көтә иде.

Хәмдия җиңел сулап куйды, ишекне япты да тиз-тиз атлап кире төшеп китте. «Ярый әле күрмәде, ярый әле күрмәде!» дип уйлады ул сөенеп, ниндидер бәла-казадан котылган кебек.

Әйе, күрмәде... күрмәделәр... Сизмәделәр дә, ишетмәделәр дә. Аның элекке дус кызы, сабакташы... яшьтәше Сабира. Теге елны аны да урман кисәргә язганнар иде. Ул чакта әле ул хисапчы түгел иде. Факия кебек ул да гап-гади колхозчы иде. Әтисе Яңавылга Низамовка бер сарык, Мраморнаяга бер сарык илтеп биргән. Шуннан калды. Ике сарык бәясенә тора аның башы. Хәмдиянең әнисе дә сарыкларын корбан итәргә булган иде дә, ул үзе риза булмады. Ул инде сарыктан да зуррагын корбан иткән иде.

Сабираны күргәч, анда үзеннән-үзе кемгәдер ачу кабара башлагандай булды. Үзенең болай качып-посып йөрүе, нәрсәдер теләнеп йөрүе бик тә хурлыклы булып, түбәнлек һәм әшәкелек булып тоелды. Шул ук вакытта аның күңелендә бәхетле сабакташыннан көнләшү хисе уянды. «Нинди киенгән!» дип уйлады ул, Сабираны күз алдына китереп. Өстендә яхшы пинжәк, иңбашында ефәк шәл, колакларында алка! Бите күмәчтәй. Баш булып утыра. Ялганчы Сабира, биремче Сабира начальник булып утыра! Ялкау Факия — бригадир, ударник Хәмдия — теләнче... Менә ул нинди замана! Туктагыз әле, күрәселәрегез алда әле. Сугыш кына бетсен, чын хуҗалар гына кайтсын — типкәләп төшерербез әле оялаган урыннарыгыздан!

Үз алдына шулай ярсып бара торгач ул үзенең бу очка ни өчен килгәнлеген исенә төшерде. «Юк, күренмичә, сөйләшмичә кайтырга ярамый» дип уйлады ул, кискен бер карарга килеп.

## XX

Председатель Вәлиәхмәт абзый йортында ут сүнмәгән иде, ләкин капка эчтән бикле иде. Хәмдия, аны-моны уйлап тормыйча, бар көченә шакырга тотынды. Күп тә үтмәде, шыгырдап өй ишеге ачылганы ишетелде.

— Кем бар анда, кем? — дип кычкырды чәрелдек тавышлы хатынкыз.— Көндез вакыт беткәндер — киләләр дә җитәләр! Әле кайтып аягын салырга да өлгермәде.

— Ач әле, ач, Мөнирәттәй! — диде Хәмдия, таләп итеп.

Мөнирәттәй, күрәсең, таләпчән тавышка алданып, баскычтан җиргә төште, капка янына килде дә аркылы агачны этеп җибәрде. Керүченең кем булуын ул төпченеп тә тормады — үзенең хуҗа икәнлеген, соңлап йөргән теләсә кемне санга сугарга исәбе юк икәнлеген сиздереп, көтмичә генә керде дә китте.

Мөнирәттәйне дә, Вәлиәхмәт абзыйны да Хәмдия бик яхшы белә иде. Янбашы гарип Вәлиәхмәт абзый гомере буена көтү көтте. Баштарак ул авыл көтүен көтте, колхоз чыккач исә аны фермага куйдылар. Хатыны да һәрвакыт ире белән булды. Сугыш башланып ферма мөдирен армиягә алгач, Вәлиәхмәт абзыйны аның урынына мөдир итеп билгеләделәр. Менә шуннан үрли башлады инде ул. Әнисенең әйтүенә караганда, колхоз председателе итеп аны былтыр җәй утыртып куйганнар. Ямалов дигәне уракка төшү белән колхозчыларга йөз илле граммнан арыш таратып, «дәүләт милкен әрәм-шәрәм иткән» икән дә, аны шундук Яңавылдан килеп алып та киткәннәр, утыртып та куйганнар.

Председатель Вәлиәхмәт абзый турында ул менә шундыйрак нәрсәләр белә иде. Аннары ул тагын шуны да белә иде: элек алар бик ягымлы, хәтта кирәгеннән артык ягымлы һәм ялагай кешеләр иде. Шуңа күрә, Мөнирәттәйнең шундый усал, чәрелдек тавышы, үзен шундый эре тотуы Хәмдияне шактый гаҗәпкә калдырды. «Ай-яй... Эт оясында көч-

ле диләр, үз өендә нинди икән бу!» дип уйлады ул, председатель хатыны артыннан ашыгып.

Өйгә килеп кергәч тә Хәмдия иң әүвәл түшәмдә эленеп торган утызлы лампага игътибар итте. Бу клуб лампасы иде — Хәмдия аны бик яхшы белә иде. Председатель өендә утызлы лампадан башка тагын берничә клуб әйберсе бар иде. Түр почмакка бастырып куелган пыялалы шкафта элек китапханә китаплары саклана иде. Арты бөгеп эшләнгән җиһаз урындыклар да элек клуб милке булып исәпләнелә иде.

«Әллә клубны монда күчергәннәрме?» дип уйлады Хәмдия беркатлы гаҗәпләнү белән. Чыннан да, Вәлиәхмәт абзыйның өе бүтән яклары белән дә ниндидер җәмәгать йортын хәтерләтә иде. Ишектән кергәч тә, каршыда, ике тәрәзә арасында маршал кителе кигән Сталинның мәһабәт портреты эленеп тора иде. Портреттан астарак язгы чәчүне вакытында башкарып чыгу турында кечкенә лозунг кадакланган иде. Стенаның уң ягында исә — шулай ук тәрәзә араларында — немецларны юк итәргә, заемга язылырга өндәгән, басуда кышлаган ашлыкны ашамаска кушкан, нәсел үгезләрен күрсәткән лозунглар ябыштырып куелган иде. Шул ук вакытта түшәм астыннан, стена буйлатып өй әйләнә чиккән кашага эленгән иде, тәрәзә араларында исә борынгы сөлгеләр салынып тора иде.

Сөякләрең эрерлек җылы өйгә итле аш исе, суган исе чыккан иде. Вәлиәхмәт абзый, гарип иңбашы белән сул яккарак янтайган көе, сары мыекларын салындырып, тирләп-пешеп, өстәл янында аш ашап утыра иде. Җылы өйгә тагын да ныграк җылылык, рәхәтлек тойгысы өстәп, идәндә мич алдында ак самовар гөрләп утыра иде. Хәмдия капка шакыган вакытта Мөнирәттәйнең дә ашап утырган чагы булган иде, ахрысы — өстәлдә Вәлиәхмәт абзыйныкыннан башка тагын буларын бөркеп кечкенә тәлинкә тора иде. Шунда ук ялтырап путаллы агач кашык ята иде. Ләкин кеше ияртеп кергәч, хуҗа хатын яңадан өстәл янына барып утырырга кыймады — ишектән керү белән сулга, мич арасына узды да, ниндидер бик кирәк эше бар сыман, кыштыр-мыштыр шунда маташа башлады.

— Исәнмесез,— диде Хәмдия, түргә узгандай итеп.

— Исәнмесез,— диде хуҗа, керүчегә таба чак-чак кына башын борып.

Ләкин аның игътибары шуннан ары узмады. Бик бирелеп ул һаман ашавында булды. Шулай ук мич артындагы Мөнирәттәй дә эндәшмәде. Ичмасам, сүз битлеге өчен булса да, «түргә уз» да димәделәр, «ашарга утыр» да димәделәр. Өйдәге шундый җылылыктан, исерткеч, туклыклы аш исеннән һәм хуҗаларның шул дәрәҗәдәге салкынлыгыннан Хәмдиягә әллә ничек булып китте. Аның кинәт башы әйләнде, күз аллары томаланды һәм түшәмдәге утызлы лампа берьюлы өч-дүрт булып күренә башлады. Ул кире ишек төбенә чигенде, егылып китмәс өчен ишек яңагына сөялде дә, өстәл өстендәге зур агач табактан, Вәлиәхмәт абзый кулындагы ялтыравыклы агач кашыктан күзләрен алмыйча, төкерекләрен йотып, беравык хәл җыеп торды. Болай тынып тору бик озакка сузылгандай булгач, тамагын кырды да, ялынычлы бер өн чыгарып:

— Вәлиәхмәт абзый?..— диде.

## XXI

— Ыһым... Сүләп кара,— диде хуҗа, башын калкытмыйча гына.

— Мин сиңа йомыш белән килгәнием, Вәлиәхмәт абзый,— диде Хәмдия.

— Йомыш белән кантурга киләләр,— диде хуҗа.

— Әйтмә! — диде мич артыннан Мөнирәттәй, тузынып.— Тапканнар! Кешегә иркенләп ашарга да вакыт юк. Болай да көн-төн чаба, инде өенә басып керәләр.

— Ачуланма инде, Мөнирәттәй,— диде Хәмдия, күңеле кырылып.— Көндез туры китерәлмәдем. Йомышымны әйтәм дә китәм. Сезгә килми кемгә килим.

— Ыһым... Сүләп кара,— диде тагын да Вәлиәхмәт абзый.

— Эш сорап килгәнием мин, Вәлиәхмәт абзый,— диде Хәмдия.

Хуҗа кеше авызына китергән кашыгын кире алды, башын калкытты да кызарган, тирләгән йөзен керүчегә таба борды.

— Нindәен эш: кул эшеме, йорт эшеме? — диде ул, аптырау катыш бер дорфалык белән.

— Юк, калхуз эше,— диде Хәмдия.

— Калхуз эше?! Эш бирмәйләрмени?! — диде Вәлиәхмәт абзый, көлеп, кычкырып.— Мин тагын эшләргә кеше җитмәй дип йөрим, эш тә җитмәй икән әле болай булгач.

Шырпы белән тешен казыштырып, күзен шардай итеп, орчык кадәр гәүдәсе белән Мөнирәттәй дә мич артыннан килеп чыкты. Килеп чыкты да, идән уртасына баскан килеш, аю күргән кебек Хәмдиягә карап тора башлады.

— Кем дип әйтим соң — Вәрәш оч Җәмилә кызы түгелме соң әле син? — диде ул, хәтеренә төшерергә тырышып.

— Шул инде, шул, Мөнирәттәй! — диде Хәмдия, сөенгәндәй итеп.

— Зариф Хәмдиясеме? — диде Вәлиәхмәт абзый.

— Нишләп Зарифныкы булсын! — диде Мөнирәттәй, иренә кычкырып.— Зарифныкы — Хәмидә. Яңавылда чуен юлда эшләй. Нигъмәт Хәмдиясе. Ысбирлауга урман кисәргә җибәргәннәрие түгелме соң әле сине, апаем?

— Менә шуннан кайттым инде мин,— диде Хәмдия, җиңел сулап.

— Ә, алай икән,— диде Мөнирәттәй, үзгәргән, сүлпәнләнгән бер тавыш белән һәм тәкәллефсез генә керүченең өс-башына күз йөртеп чыкты.

— Өченче көнне генә кайтып төштем. Бер дә кайта торган кеше түгелием... иремне сугышка алдылар. Яшь бала белән бик кыенга туры килде, Мөнирәттәй... Вәлиәхмәт абзый...— диде Хәмдия, ашыгып, буталып.

— Яшь балаң да бармыни? — диде орчык буе хатын, кызыксынган булып.— Бала белән кыендыр шул.

— Кайтып төштем — өйдә шыр ялангач. Ашарга юк. Эшкә чыгыйм дигәнием, Вәлиәхмәт абзый... Сукагамы анда, чәчүгәме... Нинди эшкә дә риза.

— Ы шул, ы,— диде Мөнирәттәй, килешкән сыман итенеп.— Эш кешесенә эшсез ятуы кыен инде ул. Балаң бик яшьмени шулай?

— Яшь шул, Мөнирәттәй,— диде Хәмдия.

Вәлиәхмәт абзый, хатыннарның сөйләшкәнен эндәшмичә генә тыңлап утырды-утырды да, чүпрәк белән майлы авызын сөртеп куйды, аягына басты, бил каешын рәтләде — сугыштан кайткан кешеләр кебек ул да гимнастерка киеп, биленә каеш буып йөри иде.

— Ыһым... Ничек соң, язу белән кайттыңмы? — диде ул Хәмдиягә.

— Юк шул, Вәлиәхмәт абзый,— диде Хәмдия.

— Ә, алай икән,— диде Мөнирәттәй, беркадәр тынлыктан соң.

— Ыһым,— дип куйды Вәлиәхмәт абзый, тамагын кырып.— Алайса, сүләшеп тә торасы юк, сеңелкәем. Дүкәмит кирәк. Хәзер ваеннай бримә, закун каты, ыһым... Язу алып кил — шуннан сүләшербез.

— Вәлиәхмәт абзый! — диде Хәмдия, эшнең болайга китүенә коты алынып.— Хәзер генә каян язу алып килим?! Шушы калхуз кешесе ич мин!

— Белмәймен, бернәрсә белмәймен,— диде хуҗа кеше коры гына.— Сүзгә генә ышана торган заман түгел — каян беләем мин сине? Әллә күрше авыл син, әллә изәртил, әллә ышпиун!

— Вәлиәхмәт абзый! Мөнирәттәй! — диде Хәмдия, шаккатып, урыныннан кубып.— Ни сөйлисең, Вәлиәхмәт абзый?! Нинди ышпиун ди ул?! Шушы Янтыкта туып үскән... шушы калхуз кешесе... Сез дә якламагач, кем якласын мине?!

Мөнирәттәй, бәладән баш-аяк дигәндәй, ялт кына яңадан мич артына кереп югалды. Вәлиәхмәт абзый да, артык сөйләшеп торасы килмәгәнлеген сиздереп, пыялалы шкаф янына килде дә, аннан нидер актара башлаган булды.

— Безне алты айга гына дип җибәрделәр,— диде Хәмдия, үзенең иң ышандыргыч тоелган дәлиленә тотынып.— Алты ай урынына мин ел ярым эшләдем... Безне көчләп тоттылар. Ел ярым бит ул, Вәлиәхмәт абзый! Җәй көне торф чыгардык, кыш көне урман кистек. Мин теләсә нинди эшкә риза: сукага, чәчүгә... утауга... уракка... Чәчем белән җир себерергә дә риза, Вәлиәхмәт абзый! Балам ач, үзем ач. Ничек карыйм мин аны? Ничек карыйм?! Сөт юк... ачтан үлә, Мөнирәттәй! Әйт, ичмасам, Вәлиәхмәт абзыйга — син бит хатын кеше!

— Нәрсәсен әйтәсең аның? — диде Мөнирәттәй, мич артыннан чәрелдәп.— Синең балаң өчен кеше минават түгел. Баланы песи дә таба—тапмаска кирәгие!

— Мөнирәттәй! — диде Хәмдия, йөрәк түреннән чыккан бер әрнү белән һәм тыела алмыйча кинәт сулкылдап еларга тотынды.— Ничек оялмыйсың?!. Ничек телең бара?!

— Бер дә ояласы юк! — дип кычкырды председатель хатыны, тагын да яманрак ител.— Кеше өчен кәтер китәсе юк монда. Кемгә дә баш кадерле.

— Ыһым...— диде шул чакны хуҗа, яңадан Хәмдиягә борылып.— Монда җылап эш чыкмас, сеңелем. Үзең беләсең, ваеннай бримә... Син, булмаса, иртәгә төшкә таба кантурга кил, эш беткәчрәк... Шунда сүләшербез, элекке дүкәмитләрне карарбыз. Исемең чыга икән — баш өсте! Калхузда эш җитәрлек — күрәгең генә нык булсын. Ыһым, менә шулай. Сүләшербез... иртәгә кил.

Хуҗаларның баштагы кыланышлары никадәр көтелмәгәнчә булса, председательнең бу йомшаруы да шул ук дәрәҗәдә көтелмәгәнчә булды. Хәмдия моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ләкин шунда Вәлиәхмәт абзый йомшак кына итеп тагын кабатлады: дисвителнә син калхуз члены булсаң, кантурда ныклап сүләшербез, диде, шунсыз булмый, сеңелем, диде...

Хәмдия башын югары күтәрде һәм яшь аралаш елмаеп, тәэсирләнеп:

— Рәхмәт, Вәлиәхмәт абзый! — диде.— Гомергә дә онытасым юк бу яхшылыгыңны!

## XXII

Икенче көн бик матур башланды. Иртүк елмаеп кояш чыкты. Кояш чыгу белән, өй эченә якты тулды, тышта тәрәзә түбәсендә сыерчыклар чыр-чу килә башлады. Күршеләр ягында, ике-өч өй аша, сузып-сузып этәч кычкырды. «Бибехәяттәйләрнеке, ахрысы», дип уйлады Хәмдия. Нинди шәп кешеләр алар! Аларның әнә әтәчләренең тавышы да нинди моңлы, нинди яңгыравыклы. Сыерчыклар тавышы да моңлы, матур. Сайрыйлар да, сызгырып та җибәрәләр, кайчагында күгәрченгәй гөрләргә дә тотыналар.

«Минем дә сыерчыгым бар,— дип уйлады ул, янында яткан улына карап.— Сыерчыгым-тургаем, сандугачым-былбылым... күгәрченем-аккошым!..»

Күңеленнән ул шулай тыштагы сыерчыкларга сокланды, улына сокланды, шул ук вакытта үзе бүген башлаячак яңа тормыш турында

хыял йөртте. Хәер, әлегә ул бер нәрсәне дә ачык кына күз алдына китерә алмады. Хәзергә ул үзенең моннан соң ябылып ятмаячагын гына белде, бүтәннәр кебек иртән иртүк торып фермага төшәчәген, кешеләр белән аралашачагын, ат өчен, камыт өчен, тегесе-монысы өчен җиңелчә генә кычкырышып алачагын, һәм, гомумән, элеккечә шау-шулы тормышка кереп китәчәген генә белде. Аннары ул үзенең улын күз алдына китерде. Ул аны үзе сукадан кайтканда атка атланган итеп, я булмаса сука сөргәндә үзе яныннан теркелдәп бара итеп күрде. Хәзергә аның хыяллары шуннан ары узмады. Шулай да аның күңелен бер өзлексез шатлык һәм куаныч тойгысы тутырып торды. Колхозның элекке исемлекләрендә үзенең барлыгын һәм баш кешеләрнең үзен Янтык Нигъмәт кызы Хәмдия дип таныячакларына ул, билгеле, бернинди шик тотмады.

Йокысыннан тору белән ул тышка чыгып китте, күршеләр күрүдән әз генә дә шикләнмичә, курыкмыйча, озак кына утынлыкта булашты; аннары, су кирәкмәсә дә, Салкын чишмәгә китте. Чишмә янында ул Гафияне очратты, аның белән озак кына сөйләшеп-гөрләшеп торды, үзенең кайчан кайтканлыгын, ничек кайтканлыгын әйтте, хәтта үзенең баласын да телгә алды. Гафия исә китеп тыңлап торган булды, ләкин аның үз-үзен тотышы буенча, кайбер сүзләре буенча Хәмдия аның күптән инде барысын да белгәнлеген аңлап алды. Белмәс сиңа күршеләр! Шул кадәр кеше арасында ничек яшеренеп ятмак кирәк! Ярый инде, рәхмәт, беркем барып чакмаган. Чаксалар, кем белә, күптән инде аны дезертир итеп, «ышпиун» итеп... Ә хәзер ул үзе барып күренде, ул үзе баш иде. Иелгән башны кылыч чапмый...

Судан Хәмдия бик шат күңел белән кайтты. Ләкин аны көпә-көндез тышта күреп, Әлтәфнең ике күзе дүрт булды.

— Хәмдия апа! — диде ул, үзенчә бик кырыс кыланып.— Нәрсә, оныттыңмыни?! Картый кайтсын әле, күр дә тор менә — барыбер әйтәм!

— Әйтсәң әллә! — дигән булды Хәмдия, көлеп.

Суын өйгә кертеп куйгач ул, тузанын кагарга дип, кием-салымнарны, ястык, мендәр ише нәрсәләрне тышка алып чыкты. Малай берни аңламады һәм «баш күтәргән» апасына ничек тәэсир итәргә дә белмичә, кашларын җыерып, баскычта басып тик торды.

Нәкъ шул чакта, аркасына капчык күтәреп, капкадан Җәмиләттәй кайтып керде.

— Нәрсә булды, кызым? — диде ул, киртәгә эленгән чүпрәк-чапракка шикле караш ташлап.

— Берни булмады, әнкәй, җилләтәм,— диде Хәмдия, тыелгысыз бер күтәренкелек белән.— Ничек кайттың? Юлың уңган, ахрысы? Көне бигрәк матур, әнкәй.

— Юлым уңды,— диде Җәмиләттәй, өйгә таба юнәлеп.

Әлтәф аның аркасындагы капчыкны үз җилкәсенә күчерде, һәм алар шаулашып, куанышып өйгә керделәр. Хәмдия әнисенә чишенергә булышты, аннары ялт-йолт кына казан астына ягып җибәрде. Арып, шулай да канәгать бер кыяфәттә Җәмиләттәй сәкегә утырды, юл хәлләрен, базар хәлләрен сөйләде.

— Ярый инде, бәхетегез бар икән, балалар,— диде.— Ярты пот онны, ипләп тотканда, күпкә житкерергә була... Янавылда да шул ук сүзне сөйлиләр: быел көзгә сугыш бетәр, диләр. Иншалла, фәрештәләрнең амин дигәненә туры килсен инде.

— Син гел шулай дисең дә соң, бер дә туры килми шул әле,— диде Әлтәф, картыйсының динлелеген тәнкыйть итеп.

— Җә, тик кенә утыр син,— диде картыйсы ачусыз гына.— Синә, кызым, ни булды? Нишләп йөрисең анда?

— Бер әйткәнне тыңламый, картый! — диде Әлтәф, әләкләшеп.

— Мин югында нишләп ятасыз сез монда? — диде Җәмиләттәй, пошынып.

Хәмдия, нәрсә әйтсәгез дә, нишләтсәгез дә хәзер инде соң дигән сыман, җиңүче кыяфәте белән беравык елмайгандай итеп утырды да, барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде. Әнисен ул үзе кебек үк сөенер дип уйлады. Ләкин әнисенә игътибар беләнрәк караган иде, аның төсе качкан йөзен күреп, тып-тын калды.

— Булдыргансың икән, кызым! — диде әнисе, башын селкеп.

— Һи, әнкәй, бигрәк куркак инде син! — диде Хәмдия, көлгән булып.

— Батырлар, кызым, сугышка китеп беттеләр,— диде Җәмиләттәй, авыр сулап.— Монда шул минемише куркаклар гына калды да инде.

## XXIII

— Карале, картый, кем килә ул безгә? — диде Әлтәф ашап утырганда, урам як тәрәзәгә күрсәтеп.— Мидхәт абый инде әллә?

Җәмиләттәй дә, Хәмдия дә икесе берьюлы дерт итеп киттеләр.

— Һай алла! Кызым, җыен! Төш базга! Әлтәф, тыныңны чыгарасы булма! — диде Җәмиләттәй, кабаланып.

Гомердә булмаган бер житезлек белән ул урыныннан торды, мич каршындагы баз капкачын ачып җибәрде дә, күзенә күренгән бала чүпрәкләрен, кызының кием-салымнарын — барысын да шунда ыргытты.

— Ишетәсеңме, төш тизрәк! — диде ул, кузгалмыйча утырган кызына кычкырып.

Мидхәтнең килүе Хәмдиягә бөтенләй икенче яктан тәэсир итте. Ләкин ул әз генә дә курыкмады. Шыртламады да ичмасам! Бу минутта аның күңелендә дулкын-дулкын булып бөтенләй икенче төрле хисләр, икенче төрле тойгылар калкып чыкты. Бу минутта аның күңелендә, барыннан да элек, үч алу теләге калкып чыкты.

Ул тәрәзәгә үрелеп карады. Әйе, чыннан да бу ул иде... Озын куныччлы кара хром итек кигән, зәңгәр галифе чалбар кигән, иңбашына шәп каешлы шәп сумка таккан, фуражкалы, кобуралы Мидхәт иде. Тормышыннан туйган чакларында, бар нәрсәгә җен ачулары килгән чакларында еш кына Хәмдия аны исенә төшерә торган иде. Андый чакларда ул кайчан да бер аның белән очрашу турында һәм очрашкач аннан бик ныгытып, усал итеп үч алу турында хыяллана торган иде. Үзенчә ул аңа инде мең-мең төрле җәза уйлап куйган иде.

Әйе, бу ул иде... аннан көлгән... аны мыскыл иткән, аны йөзе белән җиргә салган бәндә иде. Ул аның дошманы иде, һәм аның белән дөньяда да, тәмугта да, оҗмахта да — беркайда да, беркайчан да килешү дә, аңлашу да булырга мөмкин түгел иде. Һәм менә шул бәндә хәзер аны кулга алырга килә!

— Кызым, Хәмдия! Ишетмисеңмени?! — диде әнисе, ялварып, еларга житешеп.— Безгә керә бит! Капкадан керә!

— Керсен — уйламыйм да! — диде Хәмдия. Өйдәме балта — башын сугып ярам! Кереп кенә карасын, аягын гына атласын!..

— Әстагафирулла тәүбә! — диде әнисе, коты алынып.— Балаң турында уйла, безнең турыда... Харап итмә, кызым!

Җилтерәтеп ул Хәмдияне җиңеннән тотып алды, сандык өстендәге баланы чүпрәкләре белән җыеп төрде дә, кулына тоттырды һәм этеп-төртеп кызын баз капкачы янына китерде. Баласын кулында тою белән кинәт Хәмдиянең зиһене яктырып киткәндәй булды. «Төшми ярамый,— дип уйлады ул гаҗәеп бер тынычлык белән.— Чыннан да, әнкәй... Бала... Әлтәф...»

Җайлап кына ул баскычның беренче басмасына басты — өйнең идән асты биек иде һәм базга төшү өчен кечерәк кенә баскыч куелган иде.

Шуннан соң еламасын өчен улына «ашарга» бирде, каушамыйча, кабаланмыйча аны әйбәтләбрәк түрдә дә, икенче басмага басты.

Ул баз авызында күздән югалганда, чоланда аяк тавышлары ишетелде. Җәмиләттәй шап иттереп капкачны япты да ашыгып өстәл янына килде, кулына кашык алды. Өстәлдә ашлы өч тәлинкә торуына ул бөтенләй игътибар итмәде.

Ишек кисәк кенә ачылып китте һәм аждаһа булып, газраил булып, ач яңаклы, тар маңгайлы һәм эчкә баткан сусыл-зәңгәр күзле милиционер Мидхәт килеп керде. Килеп керде дә, агач идәнгә дагалы итекләре белән шак-шок басып, туп-туры түргә узды һәм, озын аякларын аерып, идән уртасында туктап калды.

— Исәнмесез,— диде ул, бераз тынып торганнан соң.

— Исәнме, Мидхәт улым,— диде Җәмиләттәй, урыныннан кузгалып.

Милиционер сәкегә Җәмиләттәй урынына килеп утырды, өй эчен күздән кичерде дә өстәлгә борылды, табак-савытларны читкәрәк сыпырды һәм иңбашындагы сумкасын салып актарына башлады. Җәмиләттәй белән Әлтәф, телсез калып, аның беренче сүзен көттеләр. Мидхәт ничектер чамадан тыш әкрен кыланды. Ниһаять, ул сумкасыннан кирәкле язуны тапты да, үзе каршысында каккан баганадай басып торган авылдашына күтәрелеп карады.

— Менә нәрсә, гражданка Ахмитуа,— диде ул сүзгә башлап.

— Нишләп мин граштанка булыйм, Мидхәт улым? — диде Җәмиләттәй, хәтере калып.

— Тукта, тыңлап тор! — диде Мидхәт каты гына.— Синең монда кызың качып ята икән. Так как сугыш вакыты нимескә каршы, нәрсә була ул, беләсеңме?.. Кая кызың?

— Кызым? — диде Җәмиләттәй, теле көрмәлеп.— Туктале син, Мидхәт улым... ни бит эле...

— Кая качты? — диде Мидхәт.— Качалмас, барыбер табарбыз!

— Бу ни эш бу? — диде Җәмиләттәй, исен-акылын җыя башлап.— Кем әйтте аны качып ята дип? Үз өендә кеше качып ятамыни?! Менә син агай! Ниндәен сүз бу? Сорау юк, нитү юк — кеше өенә басып керәсең.

— Ярар, күп сөйләнмә! — диде милиционер тупас кына.— Мин үз эшем белән йөрмим. Закун кушканча йөрим. Кая кызың?

— Минекеләр дә закун өчен йөриләр! — диде Җәмиләттәй, теле чишелгәннән чишелә барып.— Икесе башын салды, берсе әнә аяксыз ята. Ятим дигәч тә, нигә мыскыл итәсең алай?

— Телең озын, Җәмиләттәй,— диде Мидхәт, кинәт йомшаргандай итеп.— Сине беркем мыскыл итми. Кызың кая? Хәмдия кая?

— Кая булсын — әле генә Уразыга китте. Төшкә кайта. Качып ятырга монда!

— Ярар — аңлашылды! — диде Мидхәт.

Шулай диде дә, башка бер сүз әйтмичә, тышка чоланга чыгып китте. Дөбер-шатыр килеп ул төрле почмакларны, аулак урыннарны карады, аннары чормага менеп китте. Аннан тузанга буялып төште дә абзар ягына юнәлде. Ләкин анда да ул эзләгән кешесен тапмады һәм үзенең уңышсызлыкка очравына әз генә дә кәефе кырылмыйча, шулай да рәсми дәрәҗәсен сакларга тырышып, кире өйгә керде, өстәл янына утырды, озак итеп акт язды һәм:

— Кил, шунда кулыңны куй,— диде хуҗа хатынга.

— Әнә Әлтәф куйсын — мин белмим,— диде Җәмиләттәй.

Әлтәф, әйткәнне дә көтмәстән, житез генә өстәл янына килеп басты һәм тиешле урынга үз фамилиясен язып куйды. Милиционер акт язуын бөкләп сумкасына салды, сумкасын бикләде дә, саубуллашып ишеккә юнәлде.

— Кайткач әйт: кешегә күренмәсен. Бигрәк тә миңа күренмәсен! Ярамый,— диде ул чыгып киткәндә Җәмиләттәйгә, тавышын әкренәйтеп.

Ул урамга чыгып өйдән беркадәр ераклашкач та, Җәмиләттәй баз капкачын ачты.

— Чыгыгыз, китте! — диде ул, кызына эндәшеп.

Ләкин аннан нишләптер җавап кайтаручы булмады, шулай ук чыгып килүче кеше дә күренмәде. Җәмиләттәй тагын эндәште. Монысында да бернинди җавап ишетелмәгәч, базга ул үзе төште һәм шул чакны караңгы идән астында көн яктысы күреп, аптырап китте.

— Баз ишеге ачык лабаса! — диде ул, үз алдына сөйләнеп.

Чыннан да, идән астындагы кечкенә ишек яртылаш ачык тора иде. Хәмдиядән җилләр искән иде.

## XXIV

Аның баздан ничек чыкканлыгын беркем дә сизмәде дә, күрмәде дә. Якты җиргә аяк басу белән ул өй буйлап абзар ягына китеп барды, бакча аша үтте дә, яр астына төште. Монда ул беравык тыңлап торгандай итте. Шул ук вакытта ул кайсы якка китү турында да уйлап алды. Ул чокыр буйлап түбән төшәргә булды. Болай иткәндә, елга буена барып чыгарга була иде, ә елга аръягында урманнар да, чокыр-чакырлар да җитәрлек иде.

Абына-сөртенә ул яр астыннан китеп барды. Арттан куа килмәсәләр яисә алга төшмәсәләр, аны монда берничек тә күрә алмаячаклар иде. Чокыр эче тайгак, юеш иде. Аның аяклары әледән-әле таеп китте. Бер-ике мәртәбә ул ялгыш суга басып алды, бер мәртәбә абынып чакчак кына егылмыйча калды. Бала куркып еларга тотынды, ләкин ана кеше шундук аның авызын яулык белән томалады да, пычранган кулын итәгенә сөртештерде дә, ашыгып һаман алга атлавында булды.

Исән-имин елга ярына килеп җиткәч ул янә дә тирә-якка колак салды. Аны чынлап та беркем дә куа килми иде, ахрысы. Ләкин шулай да әле ул үзенең котылуына тулысынча ышанып җитә алмады һәм, туктап-нитеп тормыйча, туп-туры елгага ташланды — өч-дүрт метр киңлегендәге боздай салкын су аша чыкты да, тагын яр буйлатып китеп барды. Аның күлмәк итәкләреннән шыбырдап су акты, маңгаеннан шыбырдап тир акты.

Хәзер ул үргә таба китте һәм яр читендәге талларны, баткак урыннарны узгач, икенче бер чишмә турысына килеп чыкты. Бу чишмә чокыры үргә, калкулыкларга таба сузыла иде. Ул шунда борылды һәм, адымнарын әз генә дә үзгәртмичә, кырлар-басулар ягына үрмәләвендә булды. Бераздан ул куе гына таллыкка барып керде. Аның адымнары кыенлашты. Ул яр өстенә менде, яр читенә утырды да куаклар арасыннан артка, авыл ягына әйләнеп карады. Юк, аны беркем дә куа килми иде. Ул, ахрысы, чын-чынлап котылган иде!

Ләкин ул монда барыбер озак утыра алмады. Аны һаман нидер әйдәп, куалап торды. Ул яңадан кузгалып китте. Тал куакларына шыкланып ул хәзер яр өслэтеп кенә барды. Чокыр төбендәге куаклар бераздан өскә дә менделәр, әледән-әле аның каршысына чыгып утырдылар. Таллар зирек белән, шомырт, миләш белән алышынды. Әрәмә никадәр киңәймәсен, Хәмдия һаман читтән генә барырга тырышты һәм шулай итеп бер заман тигез җиргә — такыр басуга килеп чыкты. Монда ул үзен күпмедер дәрәҗәдә иректә итеп хис итте. Уң яктан, авыл ягыннан аны әрәмә каплый иде, сул якта, алда һәм артта туган кырлар җәелеп ята иде. Көн кояшлы иде, күктә тургайлар сайрый иде, язгы хуш исләр аңкытып яткан басу өстендә рәшә тирбәлә иде. Алда, үр буйлап күтәрелә торган басу читендә караеп икенче бер әрәмәлек күренә иде; әрәмә артында исә — төпсез-зәңгәр күк астында — иксез-чиксез бушлык һәм иркенлек барлыгы сизелә иде.

Хәмдия чокыр буендагы әрәмәдән беркадәр читләште дә, сулгарак борылды һәм ерактагы әрәмәгә карап китте. Аны хәзер авыл ягыннан күрүләре дә мөмкин иде. Ләкин шушы минутта ул бу турыда онытып җибәрде һәм, битләрендә кояш җылысын тойган хәлдә, як-ягында туган якның киңлекләрен тойган хәлдә, һаман алга барды да барды. Аңа ничектер бар куркыныч өйдә һәм тегендә — чокыр-чакыр эчендә, әрәмә эчендә торып калды шикелле тоелды. Ул хәзер артына да борылып карамады, куа килүләре мөмкинлеге турында да уйламады. Ул бары калкулык өстендәге күксел әрәмәгә барып җитәргә генә тырышты.

Әрәмә буена барып җиткәч исә ул тагын утырды, улының тәпиен тотты, аның өстендәге киемнәрен рәтләде, аякларындагы оекларының корымы, түгелме икәнлеген тикшереп карады. Шуннан соң ул аны үзенең алдына утыртты. Әннәсе белән уйнарга Ирек бик тә ярата иде, аннары болай әрәмә буйларында утыру да аңа инде таныш иде. Берни булмаган кебек ул шундук шаярырга тотынды: көлде, нәни генә куллары белән әнисенең борынына үрелде, үзе һаман нидер сөйләнергә азапланды. Борын тарту аның иң яраткан һөнәре иде. Борыннан башка ул тагын колакны, чәчне тарта белә иде. У-у, аның һөнәрләре бик күп иде! Күңеле бик күтәренке чакларда ул качышлы уйнарга да ярата иде: битенә яулык каплый да бераз тынып торган була, аннары яулык читен күтәреп карый. Үзе шундый шат, үзе елмая, җитмәсә, «һайт-ти!» дигән булып, сине котыртып маташкан була... Аннары ул тагын өстәл астына керергә, арттан урындыкны этеп йөрергә ярата. Бик үскән инде ул, тәти инде ул!

— Нишләргә соң хәзер, улым? — диде Хәмдия, улының күзләренә карап.—Син дә киңәш итмисең, ичмасам. Безгә бит кайтырга ярамый, улым. Безне тотып алачаклар, аңлыйсыңмы? Без көчкә котылдык. Ярый әле әннә исенә килеп өлгерде. Син коткардың мине, улым. Тагын син коткардың! Син булмасаң, улым, әннә дивана туп-туры бүре авызына барып кергәние. Беләсеңме, ул кем? Ул дөньяда иң кабахәт кеше, улым!.. Юк, ул синең... атаң, улым. Ни хәл итәсең! — ул сиңа ата тиеш кеше... Миңа әллә нәрсә булды әле, улым. Никтер мин аңа ачуланмый башладым кебек. Ник ачуланырга? Нигә гомер буе куенында, күңелендә таш йөртергә? Ни әйтсәң дә, ул бит сиңа ата кеше, ә син минем улым. Без дөньяда бары икәү генә. Безгә хәзер беркем кирәкми. Кара әнә тирә-ягыңа: әнә безнең авыл, әнә безнең җирләр, әрәмәләр, чокыр-чакырлар. Әнә унда Көшләби чокыры, әнә сулда, бик-бик еракта Очлы тау. Очлы тау астында Бүә буйлары зәңгәрләнеп күренә. Авыл читендә, әнә, калкулыкта безнең зират. Дүрт почмаклы урман булып утыра. Анда синең бабаларың йоклый, әбиләрең йоклый. Анда безнең барлык нәселебез ята. Әйдә, улым, ачуланмыйк аңа. Син инде тудың, син инде күзләреңне ачтың, улым. Йөре шушы җирдән, туп-туп басып йөре, курыкмыйча, яшеренмичә йөре — бу безнең җир, улым! Синең бабаң, абыең... абыйларың шушы җир өчен кан койдылар улым!

Шулай сөйләнеп ул аны алдыннан төшерде. Иске үлән сабакларына абынып, басылган иске яфракларны, үләннәрне таптап бала әнисеннән читкә үрмәләде. Ул әле ике аяклап йөри белми иде. Ул әлегә дүрт аяклап кына китте. Беләк буе җир китте дә туктап артына борылды, елмаеп әнисенә карады.

— Бар, бар, улым, нык басып бар! — диде әнисе аны дәртләндереп.

## XXV

Әрәмәне чыккач, Хәмдия иске арба юлына төште. Юл аны каядыр читкә, еракка алып китте. Хәер, юлның кая барып чыкканлыгын ул бик яхшы белә иде. Бу тар гына арба юлы Яңавылга илтә торган олы юлга тоташа иде. Ә Яңавылга илтә торган олы юл тагын да олырак, та-

гын да тапталганрак юлларга барып ялгана иде. Ул аларны белә иде, ул инде шактый күп юлларны йөргән иде. Алар кайда да бар иде, тик менә юл читендәге кырлар-басулар гына, әрәмәләр, урманнар гына бүтәнчәрәк иде, чит иде, җансыз һәм күңелсез иде. Юк, беркайда да җирнең өсте мондагыдай гүзәл, якын түгел иде!

Кая барганлыгын ул бик үк аңлап та җитмәде. Ул бары бер урында туктап тора алмаган өчен генә барды. Ләкин туган авылыннан, туган кырларыннан ераклаша барган саен аның аяклары үзеннән-үзе әкренрәк атлый башлагандай булды. Шул ук вакытта ул үзен куа килүчеләрдән бөтенләй курыкмый башлады. Әллә инде аңа янадан көч-куәт кайтты, гайрәтлек, горурлык кайтты, әллә инде аңа бүтән берәр нәрсә булды. Юк, һич тә аның нинди дер билгесез җирләргә, зәңгәрсу томан артындагы ят илләргә китәсе килмәде. Туган ягы, авыр йөк булып, адым саен аның аягына урала барды.

Алда — арба юлы олы юлга тоташа торган турыда ябулы ындыр табагы күренде. Ындыр табагы янында былтыргы салам өеме бар иде. «Шунда утырып хәл җыйыйм әле», дип уйлады Хәмдия. Ә ул бик арыды. Бит ул иртән рәтләп ашый да алмады. Ярый әле улына сөт эчергән иде.

Салам өемен ул төрле яктан карап чыкты, аннары ындыр табагын караштырды. «Җилгәрмәгән кибәкләре калса, әнкәйгә әйтермен», дип уйлады ул. Ләкин кибәкне монда да актарып, яңа баштан җилгәреп бетергәннәр иде. Эскерт калдыгы да як-яктан йолкынган-таланган иде һәм шуңа күрә ул каплап куелган чүлмәк кебек булып калган иде.

Хәмдия салам өеме итәгендә җайлырак бер урын карады да оя ясап шунда кереп утырды. Аңа монда бик рәхәт тоелды. Ул аякларын иркенләп сузып җибәрде һәм бары шунда гына үзенең бер кат йон оекбаш белән икәнлеген күреп алды. Гаҗәп, ул аны чокырда килгәндә дә күрмәде, әрәмә буенда утырганда да күрмәде.

Бала йоклаган иде. Ул аны уятып тормады — чүпрәкләрен баш астына җайлабрак куйды да, үзе янына саламга яткырды. Шуннан соң ул, тәмам онытылмакчы булып, үзе дә күзләрен йомды. Ләкин күзләрне йому белән генә йокы килмәде. «Әгәр шушында яшәсәм... шушылай?» дип уйлады ул. Элек качкыннар яшәгән бит...менә шулай салам, печән кибәннәрендә, урман эчләрендә... Хатын-кыз да качкын була алмыймыни? Күзгә чаклы түзсәң, анда инде сугыш бетәчәк. Анда инде аны беркем кыерсыта алмаячак.

Бу уй аңа бик тә мавыктыргыч булып тоелды. Ул салам арасында күренгәләгән башакларны тотып-тотып карады. Ләкин ул бер генә тук башак та тапмады — барысы да сугылган, барысы да җиңеләеп калган иде. «Юк, әле иртә», дип уйлады ул, баштагы уйларыннан суынып. Урманда, басуда хәзер ашардай бернәрсә юк. Иң кытлык чак, иң өзек чак. Ә өйдә аны сагалап торулары мөмкин. Булмый, берничек тә булмый. Булмый икән шул. Карале, чынлап та, берничек тә булмый икән лабаса!

Ул шулай артык пошынмыйча гына, кайгырмыйча гына уйланып утырганда, еракта, олы юлда җигүле ат күренде. Атлы кеше Яңавылга таба бара иде. Ул бик кызу килә иде, күрәсең, аты яхшы иде. Хәзерге вакытта колхоз атлары алай кызу йөри алмас. Кем булыр бу? Билгеле, яхшы атка утырып йөрергә хакы булган берәр олы начальниктыр, я булмаса, колхоз председателедер. Хәзер атларга бары алар гына утыра. Күтүче Вәлиәхмәт менә нинди кеше икән! Димәк, Шүрәле турысында Бүә аша күпер салганнар... Әллә Уразыга гына барамы соң бу кеше?

Ул аягына басты, салам артына ышыкланды да атлы кешенең якынлашканын көтә башлады. Аның аты, чыннан да, яхшы иде. Атның киң, таза күкрәкләре, янбашлары ерактан ук елтырап, йомрыланып күренә

иде, йөгәнендәге, эшлеясендәге җизләре исә кояш нурларында елкылдап-елкылдап китә иде.

...Ә начальник халкы ач түгел. Утырган саен алар авыз тутырып ипи ашыйлар, ит-май ашыйлар. Аларның балалары да тук, таза...

...Әнкәсе аның, чыннан да, хаклы. Ул күпне күргән кеше. Әгәр аның сүзен тоткан булса, алар менә шушы хәлгә төшмәгән дә булырлар иде, әнкәсе, әлбәттә, хаклы.

Нидер эшләргә кирәк. Болай булмый. Болай була алмый. Ләкин аның улы яшәргә тиеш... Ул инде туган, аның инде күзләре күрә, колагы ишетә. Башка чара юк. Юллар бикле... Ул яшәргә тиеш...

## XXVI

Атлы кеше якынайганнан якынайды. Озакламый ул үз юлына аркылы сузылып яткан киң чокырны чыгар да үрне менәр, ындыр табагы янына килеп җитәр. Килеп җитәр дә, як-ягына карангалап, эре генә шушы төштән узып китәр. Юк, ул тиз генә узып китмәс. Китә алмас... Моннан китми, каян китсен ул — юл бит бер генә!

Кызу чабып килгән ат чокырның теге як кырыена килеп җитте һәм, тагын да ныграк кызулап, аска төшә башлады. Атлы кешенең күздән югалуы булды, Хәмдия ашыгып баласы янына килде, ике куллап аны күтәреп алды да юлга таба атлады.

Бала һаман йоклый иде. Күтәреп киткәч тә ул уянмады. Шулай ук җиргә, юл буендагы басылган кибәк өеменә китереп салгач та ул керфеген дә калкытмады — татлы төшләр күреп йоклавында булды. Ул, ахрысы, чыннан да матур төшләр күрә иде: әнисе яңа урынга салгач, кинәт үз алдына елмаеп куйды.

Соңгы кат Хәмдия аның саф һавада алсуланган нәфис йөзенә карады. Ул аны үпмәкче дә булды, ләкин уятудан, я булмаса артык тоткарланудан куркып, мондый уйдан шундук баш тартырга мәҗбүр булды.

Бала йоклап калды. Үз алдына татлы төшләр күреп, сабый бала юл буенда йоклап калды.

Ана кеше, алдын-артын карамыйча, салам өеменә таба йөгерде. Салам янында ул абынды, җиргә капланды, аннары аягына басты һәм тагын йөгерә башлады.

Якында гына, бик якында гына аны урман көтеп тора иде. Бик озак тоелган күпмедер вакыттан соң ул шунда барып җитте. Шомырт, чикләвек куаклары ботакларын аерып җибәрделәр. Карт чыршы, пошынып, сагышланып, әкрен генә шаулап алды. Ул да аңа үз яныннан юл бирде һәм, ботакларын сузып, арттан аны каплап калды.

Күктә тургайлар сайрады. Күктә олы кояш карап торды. Җир өстендә, юл буенда, берни белми, сабый йоклап калды...

Кибәк арасында тычканнар кыштырдады, саламнарда бөҗәкләр йөрделәр, юлда, тузанда, чыпчыклар сугышты. Әнисенең яулыгына төренеп, җылыда, йомшакта ятим бала йоклап калды...

Ана кеше, тыны бетеп, хәле бетеп, һаман ераккарак качты. Ләкин мәкерле усак аңа аяк чалды. Ул гөрселдәп җиргә ауды. Кайгырудан, сызланудан җирнең өсте тетрәп китте. Карамалар, ак чыршылар, юкә, шомырт куаклары, аһылдашып, кайгырышып, чал башларын чайкадылар.

Ул күзләрен ачты. Яткан килеш юл ягына борылды да, уттай янган күз карашын чыбык-чабык арасыннан бер ноктага юнәлдерде.

Атлы кеше туктаган иде. Кибәк өемен ул бераз гына узып киткән иде һәм, артына каерылгандай итеп, юл читенә карап тора иде.

Менә кеше арбасыннан төште, аксаклап ике-өч адым атлады да туктап калды һәм, күрәсең, берни аңламыйча, исе китеп кибәк өеменә карап торуында булды.

Башына ул тегенең кебек үк хәрби фуражка кигән иде. Аның да аягында хром итек, иңбашында күн сумка иде. Ләкин аның фуражкасы да, өс киемнәре дә яшькелт төстә иде. Аннары ул буйга да тәбәнәгрәк иде, гәүдәгә юанрак, авыррак иде һәм төскә-биткә шактый олы күренә иде. Ул, чыннан да, нindидер зур начальник булырга тиеш иде. Кем булыр бу? Әллә соң т е г е н е ң башлыгымы? Әллә алар икәүләп килгәннәрме? Бик мөмкин. Икәүләп килгәннәрдер дә, тегесе авылда торып калгандыр, монысы менә аны эзләп Уразыга бара торгандыр!

Хәмдиянең кинәт эче өшеп китте. Шул ук вакытта аның бөтен тәне дер-дер калтыранырга тотынды. Иште ишәк чумарын! Берсеннән котылды, икенчесенә килеп капты! Аны тоту... аны эзләп табу берни түгел. Эте дә булса, бетте баш!

Бәхеткә каршы, арбада ул берниндн эт-фәлән күрмәде. Беразга бу аны тынычландыргандай булды, ләкин шулай да ул тулысынча тынычлана алмады. Куркү, кот алыну торган саен аны ныграк били барды, торган саен аның көчен, ихтыярын сындыра барды. Аның тизрәк моннан китәсе килде, юл буеннан, ят кешедән, үзе эшләгән хәтәр эштән каядыр качасы, котыласы килде. Ләкин китү түгел, хәтта ул кыймылдый да алмады һәм, жиргә береккәндәй, телсез-өнсез урынында ята бирде.

Кибәк өеменә кеше шактый озак карап торды. Ул, ахрысы, анда яткан ят кешене танымакчы булып азапланды. Әллә соң ул аны үлгән дип белдеме?

Менә ул иелде. Кулына баланы алды. Чит кеше, бөтенләй ят-чит кеше аны кулына алды. Үзенеке кебек итеп ул аны тупас, салкын кулларына алды... Көнләшүдән, әрнү, кызганудан ана кешенең йөрәге пычак белән телгән сыман сызылып китте.

Шул чакны кинәт аның колагына бала тавышы ишетелде. Баштарак ул моңа ышанмыйча ятты, ләкин елау тагын кабатланды. Ул аңа кычкырды... үзен ташлап киткән... жанын саклап әрәмәдә качып яткан куркак, кансыз анасына кычкырды. Ул аңа кычкырды, ул аны эзләде, ул аны таләп итте. Ачынып, үрсәләнеп, хәтере калып, ул әнисеннән ярдәм таләп итте...

Елау тавышы тагын... тагын кабатланды. Бөтен тирә-якны, бөтен жирне-күкне тетрәндереп бала үз анасын таптырды.

Хәмдиянең чыдамлыгы юкка чыкты. Нindидер илаһи көч аны жирдән алып күккә чөйде, янә жиргә атып бәрде, һәм ул, тыны бетеп, күзебашы томаланып, юлга ташланды.

— Минеке! Минеке! — дип кычкырды ул йөгерә-йөгерә.

## XXVII

Аның кычкыруын кеше ишетмәде. Ул хәтта аның үзен дә күрмәде һәм, юлдан тапкан төенчеген ничектер бик уңайсыз күтәреп, арбасына таба титаклады.

— Минеке! Минеке! — дип кычкырды Хәмдия тагын да, соңгы көчен жыеп.

Ат кузгалып киткәнче ул арба янына килеп житә алды. Килеп житте дә, юлбарыстай, ач бүредәй балага ыргылды. Аны тартып алды, йолкып алды, күкрәгенә кысты һәм кире борылды да шундук качып та китмәкче булды.

Ләкин качып китү алай бик үк жиңел булмады — әллә ачлыктан, әллә бик нык йончылудан ул үзендә бик нык хәлсезлек тойды. Аның башы әйләнде, аяклары сөрлекте һәм тынын буып бугазына күз яшь-

ләре тулды. Артына чигенгәндә ул, аягы әремгә уралып, кинәт чайкалып китте. Ят кеше алдында үзенең шушы кечкенә ипсезлеге анда ачу һәм горурлык шикелле нәрсә уятып җибәрде. Шул чакны ул беренче мәртәбә кешенең йөзенә карады. Төбәп, ашардай булып, нәфрәтләнеп карады.

— Бирмим! Минеке... үз балам! — дип кычкырды ул, буталып, тилереп.— Алып кит! Теләсәң нишләт! Курыкмыйм, ишеттеңме, курыкмыйм! Икебезне бергә алып кит, бергә үтер! Бирмим... бирмим!..

Чәче-башы тузгыган, киемнәре ертkаланган, чыгырыннан чыккан Хәмдиягә ят кеше аптырап, исе китеп карап торды. Ул бернәрсә дә әйтә дә алмады, бернинди хәрәкәт тә ясамады. Аптырау гына түгел, бераз гына ул хәтта каушап та калды, ахрысы — чөнки юлда яткан бала да, өрәк сыман «күктән төшкән» Хәмдия дә аның өчен һич тә көтелмәгән нәрсә иде.

— Синеке булгач... ник калдырдың? — диде ул, ниһаять, телгә килеп.

— Минеке! Үз балам... үземнеке! — диде Хәмдия, бер үк сүзне кабатлап.

— Миңа синең балаң кирәкми, сеңелем. Үзеңә булсын,— диде кеше әкрен генә, җитди итеп.

Аның шундый тынычлыгы, җитдилеге һәм дусларча әйтелгән «сеңелем» сүзе Хәмдияне берьюлы айнытып җибәргәндәй булды. Ул тагын да аңа сынабрак, җентекләбрәк карады... Зур битле. Чигә чәчләренә ак төшкән. Йомшак нур бөркеп торган кысык күзләре акыллы, сагышлы. Әрнеп, кызганып карый. Ә уң колагы китек! Чигәсе дә җөйле — пулямы, снаряд китегеме сыдырттырып узганлыгы әллә каян күренеп тора. Кара, кулы да гарип түгелме соң?! Әйе, беләзек турысы җөйле, бераз гына кәкре. Әлбәттә, сугышта булган, чын сугышта... Вәлиәхмәт шикелле тумыштан да гарип түгел, тегенең шикелле юри дә гариплләнмәгән.

«Юк, милиция начальнигы булмаска тиеш,— дип уйлады ул, ят кешегә карата үзендә ышаныч барлыкка килүен тоеп.— Милиция начальнигы аксак-туксак булмас».

Ул кисәк кенә тынып калды. Үз атасы кебек олы һәм акыллы кеше алдында никтер аңа чак-чак кына уңайсыз булып китте. Үксүеннән әле һаман туктый алмыйча, тик шулай да инде чынлап тынычлана барып, тиз-тиз генә ул чәчләрен төзәткәләде, улын төргән яулык очы белән битендәге яшьләрен сөрткәләде һәм шул ук вакытта, тирбәткәндәй итеп, кулындагы баласын селкеткәләп алды.

— Абый, син кем? — диде ул йомшап, беренче сүзе итеп.

— Кем булсам да, юлда бала җыеп йөрүче түгел,— диде кеше, баштагыга караганда кырысрак бер тавыш белән. Күрәсең, ул үз-үзен кулга алып өлгергән иде.— Ник ташладың? Кирәкмимени? Эт тә баласын ташламый, песи дә... бүре дә! Син үзең кем?

Соңгы сүзен ул шундый усал итеп әйтте һәм шул чагында Хәмдиягә шундый усал итеп карады — Хәмдия ирексездән калтыранып китте.

## XXVIII

Ә бераздан ул аңа үзенең язмышын сөйләп бирде.

— Менә нәрсә, сеңелем,— диде кеше, Хәмдия сөйләп бетергәч,— әйдәле, утыр әле син арбага. Бара-бара уйлашырбыз. Киңәшмәгә соңга калам, тизрәк кузгалыйк әле без.

— Син кем соң, абый? — диде Хәмдия тагын да, куркып кына.

— Минме? — диде кеше, теләмичә генә.— Минме... күрәсең ич, бер аяклы, ике куллы...

Шулай сөйләнгәләп ул тарантастагы саламны таратыбрак, җайлабрак куйды, шунда яткан юл плащын рәтләде. Аннары, әле һаман урыныннан кымшанмыйча торган Хәмдиягә борылды да нык кына итеп:

— Әйдә, утыр,— диде.

Хәмдия улын кысыбрак тотты, арбага таба кузгалып куйды. Ул һич тә кузгалмый булдыра алмады. Ул атларга мәҗбүр булды. Ләкин бу мәҗбүрият аны хәзер аз гына да куркытмады-өркетмәде, киресенчә, ул үзендә, үз күңеленең бик тирән җирендә киләчәккә өмет чаткылары туа башлаганлыгын тойды.

— Туктале, болай итик без...— диде кеше.— Син, булмаса, плащны өстеңә киеп утыр. Җайлы да булыр, очраган кешеләр дә танымас.

Ике куллап ул зур, авыр плащны Хәмдиянең иңбашына каплады, башлыгын күтәреп куйды. Хәзер инде аны, чыннан да, танырлык түгел иде.

Тарантаска алар парлашып, бер-берсенә сыенып утырдылар. Баядан бирле бер урында таптанып торган таза ат, дилбегәне кагу белән, җиңел генә кузгалып китте.

— Абый, син мине кая алып барасың? — диде Хәмдия, күңелендәге соңгы төенен чишмәкче булып.

— Тормышка! — диде кеше серле итеп.— Дөнья киң, көн якты... ат яхшы... Ничек тә җаен табарбыз әле!

Шуннан соң ул иелгәндәй итте дә әнисе алдында яңадан йокыга киткән балага карап алды, елмаеп җибәрде.

Уйчанланып, бераз вакыт тын гына баргач ул, үз алдына сөйләнгән сыман, әйтеп куйды:

— Сугыш бетәр... сугыш белән бергә ачлыгы да, газаплар да, җәбер-золымы да бетәр,— диде.— Инде күп калмады. Дөнья барыбер безнеке! Ышанасыңмы син шуңа?

— Ышанам, абый !— диде Хәмдия, баласын күкрәгенә кысып.— Рәхмәт инде сиңа, абый, рәхмәтләр яусын!

## МОРДВА МӘКАЛЬЛӘРЕ

### (Мукшы һәм Эрзә телләреннән)

**Язларны чәчәк бизәсә, көз күрке — бәлеш була.**
**Язның байлыгы — кояш, көзнең байлыгы — уңыш.**
**Яз хезмәтен көз бәяли, яз җырын көз тәмамлый.**
**Язын ничек эшләвеңне көзләр җиткәч беләсең.**
**Яхшы хуҗаның начар көне юк.**
**Яңа итек катырак шыгырдый.**
**Карт кычыткан катырак чага.**
**Ватансыз кеше — оясы юк кош.**
**Кәкре агачы булмаган урман юк.**
**Энә кайда — җеп шунда.**
**Капканы ике багана, йортны ике баш тота.**
**Бала кулына кергән шырпы ана йөрәген чәнчә.**
**Балалары юк кеше — ботагы кипкән агач.**
**Кулыңа үзең утыртсаң, җилкәңә үзе менәр.**
**Авыр гомер озын була.**
**Үлемнән курыксаң — тизрәк үләрсең.**
**Басудагы чүп үлән карактан күбрәк урлый.**
**Көр ат ун аяклы була.**
**Кирәкле таш авыр булмый.**
**Йөзәргә өйрәнми торып, суга сикереп төшмә.**



## *Фәһим Хәсәнев*

●

*Күптән түгел генә күңел тетрәткеч хәбәр ишеттек: Кукмара егете, яшь шагыйрь Фәһим Хәсәнев хезмәт фронтында фаҗигале рәвештә һәлак булган.*

*Фәһим 1937 елда Кукмарада туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, «Кызыл тукучы» фабрикасында слесарь булып эшли. 1956 елда флотка алына; башта Балтика, аннары Баренц диңгезендә хезмәт итә. Андагы әдәби берләшмә эшендә актив катнаша. Диңгезгә һәм поэзиягә гашыйк егет күп укый, туктаусыз эзләнә.*

*Фәһим Хәсәнев шигырьләре, художество эшләнеше ягыннан әле тәмам камилләшеп җитмәгән булсалар да, туган илгә, тормышка, флотка тирән мәхәббәт хисләре белән язылганнар. Аларда яшь шагыйрь үзе татыган моряк хезмәтенең героикасын һәм романтикасын тоясың.*

*Тик кызганыч, Фәһим Хәсәнев тулы күкрәк белән сулап җырларга өлгермәде...*

Гали Хуҗиев.

### Дозордан кайтышлый

Үтелгән һәр метрга сөенеп,
Без диңгездән кайтып килгән чакта,
Ак дулкыннар йөрде тирә-якта,
Ак кашларын усал җимереп.

Штормнарда булган кеше белә:
Җиңү килми безгә үз-үзеннән.
Хәлдән тайды куллар, өзелүдән
Тотып торды кебек җиң генә.

Йокы аяклардан екса да,
Чыдамлыкны һич тә киметмәдек.
Чит илләргә туктап ял итмәдек,
Кайтасы юл озын булса да.

Җилдә уйнап, алып күз явын,
Мачтабызда флаг җилфердәде,
Кульяулыгын безгә хәтерләтеп
Туган ярда калган кызларның.

### Прибой

Дулкын,
Чәчәкләрен кочып йөгергәндә
Егылып киткән бер кыз шикелле,

Күкрәгендә шуып ярга чыккач,
Ак күбекләр чәчрәп сибелде.

Ә бер тамчы,
Яше булып агып
Яңагына салкын бер ташның,
Ерак-еракларга балкып торды
Бөтен нуры белән кояшның.

## Сине сагынганда

*(Аның хатыннан)*

Кайчан гына кояшлы җәй иде,
Гөлләрем бар иде бакчамда;
Чәчәк тотып тора идең син гел,
Кичен тәрәзәмне ачканда.

Чәчләремнән назлап сыйпый идең,
Үрмәле гөл кебек сузылып.
Син киткәчтен бары сагыш калды,
Күңелемә тирән сыенып.

Каеным да шундый сагына күк
Син сөялеп торган чакларын.
«Кайта», «кайтмый», «кайта» дигән
сыман
Бер өзлексез коя яфрагын.

## Һәр тал монда...

Кайтып тракторга утыруымны
Ошатмады өйдә берсе дә:
«Ярты маең булса машинада,
Ярты маең, диләр, өстеңдә.

Аз дигәндә урта белемең бар,
Флотта да өлкән булгансың...
Ничек инде кабат шул эшеңә
Баш төртергә мөмкин шуннан соң?

Киләчәге юк бу ягыбызның,
Берәр якка эшкә кит! — диләр. —
Ни урманы юктыр якынында,
Елга килер дип тә көтмиләр».

Монда изге ватан күгенә мин
Беренче кат күзем ачканмын.
Шуннан бирле аның суын эчтем
Һәм күзәттем таңнар атканын.

Монда мине тукландырган туфрак...
Мин соң барын ташлап китимме?
Һәр тал монда, кипкән кулын сузып,
Миннән яфрак сорый шикелле!

## *Җәүдәт Исмәгыйлов*



*Мин Башкортстанның җырларда җырлана торган Ашказар, Дим сулары башланган тирәләрдәге авылларның берсендә — Балыклыбашта 1936 нчы елда тудым. Үз авылымда башлангыч белем алдым. Урта мәктәптә укыгач, Оренбург педагогия институтын 1959 нчы елда тәмамладым. Аннан туган якларыма кайттым, 3 ел укытучы булып эшләдем. Яшьтән үк театр сәнгате белән кызыксынганга күрә, 1962 нче елда Әлмәт драма театрына килдем. Төп максатым: югары театр белеме алу.*

*1952 нче елдан бирле ВЛКСМ члены. Поэзия белән кызыксынуым мәктәп эскәмиясеннән үк башланды. Безнең мәктәптә шигырь язучылар күп иде. Сәхнәдә Г. Тукай, М. Җәлил, Һ. Такташ һәм Ш. Маннур шигырьләрен яратып укый идек.*

*Поэзия турында язсаң, күп язарга була инде ул. Бер карауда гади генә булган нәрсәләр дә укучы өчен яңа булырлык итеп, тапталмаган образлы сүзләр белән язылса, әйтергә теләгән фикереңң күпләрнең хисләрен дулкынландырса, шигырь күңелгә сеңә, андый шигырьләрне яратып укыйлар. Бүгенге кешенең эчке дөньясын ачкан шигырьләрне халык үз итеп кабул итә.*

*Яшьләр арасында «Хәзер язар нәрсә азайды» дип шөбһәләнүчеләр дә бар. Хезмәт кешесенең мең төрле хыялы, үзенә генә хас матур яклары бик күп, менә шулар турында язарга кирәк дип уйлыйм мин.*

### Ләйсән яңгыр килә сибәләп

Янар кояш көлеп кенә карый
Күңеле тулган ерак бозларга.
Боз китүен әллә кызганамы, —
Зәй буйларын күзләп кыз бара.

Юл тетрәтеп килгән самосвалда
Шофер егет туктап көтсә дә,
Ник утырмый ул кыз машинага?
Бар, күрәсең, бардыр бер сәбәп.

Һәр машина канат куйган кебек,
Илтеп куйса Бигәш кырына,
Ул арада сүзләр табыламени
Язылачак яңа җырына?

Әнә алда
Урсал тавы урман-бүрегеннән
Кышкы карны кагып төшергән.
Әйтерсең лә,
Сүндергән дә Зәйнең факелларын,
Мактау сүзе көтә кешедән.

Әнә унда яңа шәһәр үскән,
Ап-ак йортлар Чупай ташыннан;
Бигәш кызлары күк канат җәеп,
Тезелешкән таулар каршына.

Зәй буенда яткан тау сыртларын
Йомшак кына назлап, иркәләп,
Чал бөдрәле аксыл томан төште —
Ләйсән яңгыр килә сибәләп.

Яз килүен, ярга гына сыенып,
Көтә-көтә Зәй дә үртәлгән.

Кай арада Әлмәт — Урсал чиген
ГЭС буасы кадәр күтәргән.

Кара алтын тулган ак мичкәләр
Утраулардан гүя купканнар,
Ак аюлармени боз өстенә
Балык аулар өчен чыкканнар.

Үзәннәргә яңа агым биреп,
Унынчы яз килеп житәсен
Белә торып,
юлны машинада
Буш кул белән ничек үтәсең?

Әй, син шофер,
ян көзгеңә карап,
Тарасаң да тузгак түбәңне,
Кыз утырмас синең кабинаңа —
Җыр язасы аның күп әле.

Һәм самосвал упкәләгән сыман,
Зәңгәр төтен бөркеп кузгала.
Күңеленә яңа жырын теркәп,
Әлмәтенә кайта кыз бала.

## Кеше үзе дөнья куйгач та

Баш очына агач утыртуны
Жирдәгеләр йола иткәннәр.
Агач үскән.
Кабер язуларын
Еллар, жилләр юып үткәннәр.

Ә агачлар кайсы ятып үскән,
Кайсы үскән күккә омтылып.
Кызык кына, әнә, һәркайсында
Бер кыланыш, үзенә бер холык.

Күкрәп үскән имән иңнәренә
Ак беләген салган бер каен.
Имән сөеп, чәчләреннән
сыйпый,
Ике гашыйк болар, мөгаен.

Карагайлар мыштым егет сыман
Йомылып тора баскан урында.
Сер тоталмас усак яфраклары
Ни пышылдый алар турында?

Жирдә үзен кем дә үз итмәгән
Кәкре каен тора бер читтә.
Шикләнепме шуннан йөзен борган
Шау чәчәккә чумган яшь юкә.
Биек нарат үзе тиң күрмәгән
Бу кечкенә урман кисәген:
Бөркет канатыдай ботаклары,
Карурманга очу исәбе.

Күрәсең бер тормыш алымы бу:
Кеше үзе дөнья куйгач та,
Яшәеше аның чагылыш тапкан
Каберендә үскән агачта.



# Фәнис Яруллин

*Поэзия белән ныклап кызыксыну, больницада, тән газабы белән генә түгел, рухи газап белән дә җәфаланган вакытларда башланды. Башта мин очраган бер шигырь китабын йотылып-йотылып укыдым. Китапларны сайлап түгел, нинди туры килсә шуны укыдым. Соңгарак, әйбәт шигырьләр укыган чакларда, үземнең дә язасы килә башлады. Әллә ни ис китәрлек шигырьләр яза алмасам да, шигырьләр миңа рухны төшермәскә, боекмаска, кыскасы — яшәргә ярдәм иттеләр. Поэзиянең сихри көче барлыгына тәмам төшенгәч, бөтен тырышлыкны шуңа багышлап, чынлабрак яза башладым. Хәзер шигырьләр белән бергә кыска хикәяләр дә язам.*

*Биографиямә килсәк, түбәндәгечә:*

*1938 елда, Ютаза районы Кызылъяр авылында туганмын. Кызылъяр җидееллык мәктәбендә укып, 8 классны Баулыда тәмамладым. 1954—1957 еллар Берләшкән Татнефть конторасында (Бөгелмәдә) монтер булып эшләп үзды. Аннан Совет Армиясе сафына алындым. Шунда турникта күнегүләр вакытында бәхетсезлеккә очрап, кул-аякларым хәрәкәтсез калды. Тормышта бернигә дә яраксыз кеше булып калмас өчен, язмыш белән көрәшергә — укырга кирәк иде миңа. Казан больницасында яткан вакытта урта мәктәпне тәмамладым. Монда 18 нче кичке-яшьләр мәктәбе укытучыларының тырышлыгын, миңа бик булышуларын ихтирам белән искә алып үтмичә булмый. Хәзер Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында, икенче курста укыйм.*

## Батып бара кояш ашыгып

Бар кешеләр әле эшләп йөри —
Кешеләрнең эше күп кырда.
Әй, син, кояш! Яктырт озаграк
Тау башына менеп утыр да.

Күрәсеңме? Әнә болыннарның
Печәннәре чери пакуста.
Сылу кызлар керләр элеп куйган,
Кем киптерер?
Синең өчен калыр кем постта?

Юк, тыңламый, кояш башын бора,
Тәгәри ул һаман түбәнгә,
Әнә аның соңгы нуры төште
Очланмаган биек кибәнгә.

Тау астына тәгәрәтмәс өчен
Куеп булса әгәр иңбашны,
Үз иңсәмдә гел яктыртыр идем
Кешеләргә якты кояшны.

## Теләк

Әгәр дә мин ак күгәрчен булсам,
Очар идем зәңгәр һавада,
Канатларым белән бәхет җилпеп
Һәр авылга, һәрбер калага.

Кояш булсам, гел балкытыр идем
Елмаюлар өләшеп йөзләргә.
Я булмаса шатлык яше булып
Бер ялтырар идем күзләрдә.

Кайнар чүлдә чишмә булыр идем,
Юлчыларның басып сусавын.
Юынсыннар иде салкын суда,
Тыңлый-тыңлый моңлы су шавын.

Мин ризамын берәр төзелешкә
Таш булсам да — әгәр кирәксә.
Тик теләмим бары бер нәрсәне —
Таш булуны һичбер йөрәккә.

● ● ●

Дөньяда мин бер битараф кеше түгел,
Матурлыкны күрер өчен күзләрем бар.
Шуңа күрә шатлана һәм сөенә күңел
Тормышымда үзем салган эзләрем бар.
Дусларымны кочар өчен кулларым бар,
Ялкынланып сөяр өчен хисләрем бар.
Сөйгәнемне назлар өчен моңнарым бар,
Сөенеп искә ала торган кичләрем бар.
Кешеләргә йөрәгемне бирә алам,
Диңгез кебек ярсып торган йөрәгем бар.
Авырлыкка туры карап яшим һаман,
Чөнки минем кешеләргә кирәгем бар.
Каерса да язмыш минем канатымны,
Ала алмас кешеләрне яратуны.

● ● ●

Тау астында бер таш ята инде күптән,
Янгыр килеп аның битен юып киткән,
Уятырга теләп ярсып җил уйнаган,
Ләкин бу таш йокысыннан уянмаган.
Урманнар да дәртле көйләр көйләгәннәр,
Ә карт таллар эшне мактап сөйләгәннәр.
Ташка шулай һич тынгылык бирмәгәннәр,
Барсы аны уятырга теләгәннәр.
Таш йоклаган уянмыйча шулай һаман,
Мүк сакаллар басып киткән аны тәмам.
Тора-бара ул онтылган, чыккан юкка,
Калган бары таш урынында кара нокта.
Яшәгәндә кеше булсын ут һәм яшен,
Шул таш кебек хәрәкәтсез яшәмәсен.



## *Әхәт Гайнуллин*

●

*Буа районы Аксу авылында 1929 елда тудым. Арыш басуларында тук башаклар тавышын тыңлап, тормыш матурлыгына сокланып үсәр чакта Ватан сугышы башланып киткәнлектән, тормышның әчесен дә, төчесен дә бик яшьләй татырга туры килде. Без, сабыйлар, фронт өчен, җиңү өчен үз өлешебезне кертеп, унөч яшьтән сабанга йөрдек һәм печән чаптык. Ә сугыштан соң, сугыш җәрәхәтләре — элекке матурлыгын югалткан шәһәрләр, йөрәгендә дәрте, беләгендә көче булган һәрбер кешене үзләренә чакырдылар. Минем дә шул төркемдә буласым килде.*

*1954 елда, армиядән соң, чирәм җирләрдә һәм Себер төзелешләрендә эшләдем.*

*Яңа цехлар, корпуслар, йортлар төзүнең төзүче кешегә үзенең бер шигъри матурлыгы бар. Әле кичә генә син салган яңа йортның ишекләрен бүген инде шатланган кешеләр — квартира хуҗалары ачалар... Күңелдә җыр туа! Ул җырларның көчәйгәннән-көчәя барып, тышка, киң мәйданга чыгасы килә башлый. Мин тик шуны уйлыйм: ул җыр — төзүченең шатлыгын да уртаклашсын, кайгысын да таратсын, йөрәгенә җылы бирә алсын, канатландырсын, кыскасы, төзүченең үзе кебек була алсын иде.*

*Хәзер дә төзүче булып эшлим һәм республика урта мәктәбендә (читтән торып) укыйм.*

### Йөрәкләр сөйләшкәндә

Күрергә сине ашкынып,
Талпынып типкәч йөрәк,
Аз сүзле диеп, урынсыз
Үпкәләү нигә кирәк?

Тынлыкка чумган бу кичтә
Җаннарың эри бергә,
Ишетәм хәтта чирәмнең
Тамыр җәйгәнен җирдә.

Талпынып сиңа ашкынган
Күңнәрем сирәкмени...
Йөрәкләр үзе сөйләшкәч,
Сүзләрнең кирәге ни?

### Флаг

Сез бит монда беренче кат әле,
Гаҗәпләнгән кеше кебек бер:
Күрәсез дә флаг җилфердәвен,
Бәйрәм микән бүген, дисездер...

Гаҗәпләнү, белмим, кирәк микән,
Ә шулай да менә кранга
Төзүчегә аны ни өчендер
Кирәк булган элеп куярга.

Машиналар чаба,
Кирпеч килә
Асфальт җәйгән озын юллардан;
Үсә бара шулай яңа йортлар
Исемнәрен көткән урамнар.

### Кар кызы

Ап-ак кардан киенеп таш салабыз...
Ташчы кызга карыйм, эндәшмим,—
Нинди чибәр!
Керфек очларына
Карлар куна. Кунсын, күнләшмим.

Охшаган ул сылу Кар кызына,
Татар кызы, минем якташым,
Татьянасы төсле ул Пушкинның,
Ул Алсуы төсле Такташның.

Күләч йөзе, ачык елмаюы...
Карашлары якты ут мәллә?
Ник гаҗәпкә калдым егет булып,
Кызларны соң күргән юк мәллә?

Азмы күзләр!
Әмма күргәнем юк
Беркайчан да мондый күзләрне! —
Уйларымны минем белгән кебек
Алсуланып китте йөзләре.

Романтикның исе китәмени, —
Салкын җилгә, кышкы буранга.
Эшләр беткәч, җәяү, икәү генә
Без атлыйбыз бергә урамнан.

Йөрәгемдә бетмәс җылы хисләр,
Әйтер сүзләр аңа, бар да бар.
Гашыйк булып күктән җир кызына
Талгын гына ява ап-ак кар.

## Учак

Кышкы суык үзәкләргә үтә:
Без эшлибез ачык һавада,
Кирәклеген үзенең белгән кебек
Учак яна төзелеш барганда.

Вакыт-вакыт килеп төзүчеләр
Җылыталар туңган кулларын...
Этаж арты этаж күтәрелә
Болытларны этеп югары.

Мин учакка карап уйга калам:
Йөрәк утың өстәп эшеңә,
Җырың белән учак булсаң икән,
Җылы бирер өчен кешегә.

## Хәлләрең белсәм икән

Хәлләрең белсәм икән лә,
Төшләремә керәсең:
Юллар озын, туңгансыңдыр,
Гел тауларга менәсең.

Гау түбәсе киртләч-киртләч, —
Болыт микән, кар микән...
Сагынып язган хатларымның
Җылылыгы бар микән?

Салкыннарда йөри-йөри
Керфегең бәсләнгәндер.
Абау, җаным, бәс түгелдер,
Күзләрең яшьләнгәндер...

Әйт дускаем, нилектән бу —
Шатлыктанмы яшь чыга?
Керсез күңелем, тугры бул син,
Әйдә юрыйк яхшыга.

Газиз Мөхәммәтшин

# Авылда бер...

Хикәя

Үзенә «егет» дип дәшүләрен быел гына ишетә башлаган чандыр буйлы монтер малай белән бергәләп, Әхияр бик озак өй түбәсендә йөрде. Алар түбә тактасын тишеп колга утырттылар. Аңа бакыр чыбык беркеттеләр. Чыбыкның икенче очын мунча артында кукыраеп утырган өянке ботагындагы керәч кәтүккә бәйләделәр. Монтер малай, өянке ботагыннан төшкәч, мин бәләкәй дип кыстатып тормады: иң элек, яратып биргәннең суын эч, диде дә, бер шешә портвейн «чеметеп» куйды. Аннан, тишек тамак тик тормый, дигәләп, тугыз пәрәмәч ашады һәм ярты самовар чәй эчте. Урындык артына ята төшеп чын күңеленнән «уфф!» диде. Коры тастымалны сыкмалы итеп тирләрен сөрткәч, атын җикте дә күрше авылдагы сөйгән кызы янына китте.

Әхияр, аның артыннан капканы ябып кергәч, трюмо белән диван-караватурт уртасында торучы радиоалгычка ашыкты. Башы күккә тиярдәй булып аның сырлы төймәләрен боргалады. «Монысы ДВ, монысы КВ III икән, джаз дисәң — менә джаз!» дип сөйләнә-сөйләнә, тальян телләре шикелле тезелеп торган ак телләргә басып-басып карады. «Белорусь 62». Иң соңгы модель! Кара, өстендәге лагы ялык-йолык итеп ничек ялтырап тора — кызын хәвеф-хәтәрсез генә кияүгә биреп җибәргән әбинең нурлы йөзе диярсең... Эченә карасаң — ис китә: төрле-төрле ничаклы лампочка тутырганнар. Кәнишне тутырырлар. Шушы тартмага ярты сыер хакы керде дә китте бит. Күренмәде дә. Шүткеме әллә сыер хәтле ярты сыер!.. Эһ тә итмәде — шифер түбәле абзар салырга җыйган акчаның кабыргасын сукты да сындырды бу ялтыравык тартма. Ләкин, җан биргәнгә җүнен бирә диләр, акчасы тагын табылыр. Җаныннан аерылырга уйлаганы юк — акчаны көрәп ала Әхияр. Алтын куллы дип тикмәгә генә әйтәләрме әллә аны. Шул алтын куллары сау булсын да балтасы үтмәсләнмәсен... Аның каравы бу нәрсәкәй белән бөтен дөньяны рәхәтләнеп тыңлыйсың. Кытай кирәкме — рәхим итегез! Тотканы борып җибәрәсең, шунда ук сиңа: Хуан-чжан-ци-хи-хуа-ха-ха-ха!.. Әһә, әзербәйҗан җырлары яратасыңмыни? Рәхим итә күр! Дулкынны сизелер-сизелмәс кенә күчерәсең, һәм: җуҗуләрем чеп, чеп, чеп!.. Әгәр инде берәр мәзәк кеше булсаң һәм эчең катып көләргә яратсаң, андый дулкын да бар: Ватиканның Иисус Христос турындагы «Чвятой отеч...» дип башланган экиятләрен тыңлап идәндә тәгәри-тәгәри көлеп тик ят... Эх!..

Әхияр шулай хыялланып торган арада, өй эченә караңгылык үрмәләп өлгерде. Ләкин электр станциясе ут бирергә ашыкмады, матча турысыннан асылынып торган каз күкәе хәтле лампочка һаман кабынмады. Электрдан башка әлеге телсез «Белорусь»ны ничек телгә китерәсең.



Әхияр лампочкага карый-карый, мыгырдана-мыгырдана ишекле-түрле йөри башлады. Сәгатькә күзе төшкәч, тагын да чыгырыннан чыкты. Тәрәзә пәрдәсен күтәреп электр станциясенең калай торбасына йодрык янады.

— Ну Салхан — арпа талкан! Тагын Пушкинга ябыштың микән!?. Син бүрәнә сәкеңдә Онегин, Татьяна диеп акылыңнан язасың, мин монда радио тыңлый алмый тилмерәм. Бүген генә тилерми, саташмый торсаң ни була!..

Йодрык янау түгел, әллә нишләрсең! Кайчакларда бик кызык хәлләр китереп чыгарган, кайчакларда олы җәнҗаллар куптарган, имгә ярамаган сәер гадәте бар шул Салханның. Ул, юньсез ирләр аракыга сабышкан шикелле, хәреф танычач ук укуга ябышкан һәм, яше дүрт дистәгә күтәрелеп килүенә дә карамастан, бу гадәтен ташламаган иде. Аның бар белгәне, дөньяда яшәвенең бөтен яме — китап. Ул, пар казанының мичендә икешәр метрлы юан-юан әрдәнәләр тутыра да, бар нәрсәсен тикшереп, ике бит кенә укып алыйм әле дип, китабын ачып, җәй булса ишек тупсасына утыра, кыш булса почмактагы бүрәнә сәкесенә сузылып ята. Ятуын гына ятсын, бер ятса инде — бетте! Дөнья белән тиенлек тә алыш-биреше калмый. Эштә икәнен дә, яшәвен һәм ашавын да, хатыны, балалары барлыгын да, хәтта үз исеме Салхан булуын да оныта.

Салхан бүрәнә сәкесенә җәелгән толып өстенә чалкан яткан килеш кенә Чапаевның өермәдәй дивизияләре белән бергәләп Колчак бандаларын пран-заран китерә, космонавтлар белән космик корабльләрдә җир әйләнеп рекорд арты рекорд куя, орден арты орден ала, «Томанлы Альбион» сәяхәтчесе Джемс Кукка ияреп Австралия ярларын ачып йөри. Көлә, елмая, кашларын җыера, ыңгыраша, тешләрен шыгырдата, елый.

Ә сәгать келт-келт йөри, вакыт үтә, әрдәнәләр дулый-дулый янып бетә, казандагы пар басымы түбән сикерә. Тегермән ташлары үлдемкалдым әйләнергә тотына, мөшкәдән кершәндәй ак он агуын өмет итеп килгән агайның капчыгына көрпә коела башлый; түгәрәк пычкылар бүрәнә арасына кысылып шып туктала; көзге алдында электр машинасы белән сакал кырып клубка ашыгып утыручы егетләр, тырпаеп калган ярты сакалларын зәһәр селкетә-селкетә, эттән алып эткә салып «ни гомер халык канын эчсә дә, һаман яшен сукмаган каһәр суккан китап кортын» сүгәләр, елардай булып көзгедәге мәзәк кыяфәтләренә карыйлар; йөзләрчә лампочкалар, кинәт сискәнеп, мелт-мелт күз кысалар да хуҗаларыннан оялып бәләкәй күмер кисәге кебек кызаралар; кечке мәктәптә тирләп-пешеп диктант язучы егетләр, кызлар, агайлар, апайлар шул кызгылт күмер кисәгенә мәхәббәтле күзләре белән иркәләп карыйлар, куанып елмаялар, чыш-пыш киләләр, кыбырсыйлар. Кыскасы, әле генә балкып, гөр килеп торган авылны төнге караңгылык, тынлык баса...

Баш очында күк күкрәгән тавышлар чыгарып телефон шалтырагач кына, Салхан, бер минут тынычлык юк; үләм инде эшли-эшли, дип сукрана-сукрана толып өстеннән калкына. Мондый «кызыклар» ходайның һәр бирмеш аенда, дигәндәй, кабатланып торса да, Салханның кулына китап эләкмәгән сәгатьләрдә өендә дә, эшендә дә менә дигән кеше булуын уйлап, авыл халкы аңа әллә ни үпкәләми.

Әхияр шуларны уйлый-уйлый пәрдәне төшереп азапланганда, тавышсыз гына ишек ачылды. Шунда ук ялт итеп матча астындагы теге каз күкәе кабынды.

Әхияр, күзләре яктыга иялэшкәч, хатынына карап эре тешләрен күрсәтеп елмайды.

— Синме, Марзия! Бүген соңгарак калдың, дип әйтимме?!.

— Калынды шул. Карлыган төпләрен казыдык. Алмагач ботакларын кистек. Җиләк төбенә суперфосфат керттек... Уф!.. Көн буе аяк өстендә, җеп өзәрлек хәлем калмады.

— Ярый, мин болай гына әйттем... Карале, син, бусагадан атлавың булды, өйнең яктырып китүе булды. Әллә син утны кесәңә генә салып йөртәсең инде.

Марзия дәшмәде. Иягенә төшереп бәйләгән ак яулыгын чишеп, аягындагы галошын салып куйды да, оекчан гына калып, мич арасына кул юарга кереп китте. Анда умывальникны шалтырата-шалтырата юынгач, Әхияр янына чыгып:

— Әнкәй өйдә юкмы әллә? — дип сорады.

— Юк шул. Бибибану кортка, эссесе дә, кайнар суы да бик мул дип, мунчага әйттергән иде. Комганы белән мәтрүшкәле пиннеген тотып шунда йөгерде.

— Соң мин бакчага киткәндә, Бәдерҗан түтиләргә мунчага барам, дип калган иде бит.

— Барды, барды. Кайтып кына кергән иде.

— Ай ярата да мунчаны. Гомер буе ләүкәдә генә утырыр иде... Ә балалар кайда, һаман кермәделәрме?

— Аларның шул инде — урам... Марзия, кара инде монда. Күрерме, күрерме, дип кайчаннан бирле торам. Тәки теләгәнем булды бит. Алып кайттым. Антеннасын да элеп куйдык. Хәзер җибәрәм. Яктыны гына көтеп тора идем.

— Ә-ә, алдыңмыни? — дип Марзия урыныннан торды. Радиоалгыч янына килеп аның шкалаларын карады, капкачын ачып япты. Әллә ни исе китмәде. Кире урынына барып утырды.

— Әйбәт булган инде. Ярый... Утны кесәңдә йөртәсеңме әллә, дисең. Кесәмдә түгел, менә монда, йөрәгемдә йөртәм мин аны...

Әхияр хатынының тел төбен сүзен әйтеп өлгергәнче сизеп ала. Чөнки ничә елдан бирле шул иске сүз, бер үк нәрсә өчен ызгыш-бозылыш, нервы-йөрәк туздыру. Марзия, борып җибәргән сәгать шикелле, ялыгуны-нитүне белми, һич онытмый үзенекен тукый: эшкә кер, кеше алдында оят, ди. Ә ник эшкә куа ул аны? Әхияр мич башында түшәмгә төкереп, таракан санап ятамы әллә? Өсте ялангач, тамагы ачмы Марзиянын? Шуңа оялып йөриме? Әхияр әз табамы акчаны! Авылда, чагыштырып карасаң, алардан бай, алар кебек мул тормышта яшәүче дә юк. Бер куллары майда булса, берсе балда. Мөшкәләре тулы. Әхияр эчеп, азып-тузып йөрүчеме — түгел. Җилбәзәк хатын-кыз артыннан юртырга яратамы? Юк. Кесәсе төбенә төшеп яткан акчаларын, кайбер тотрыксыз җаннар кебек, кайткан юлында җилгә очырып бетерәме? Юк бит, юк, алай түгел. Җан тиргә төшеп эшли, таба. Бөтен тапканы бер үк капкага кайта, бөтенесе аңа, балаларына. Кыскасы, агачтан сандугач кына ясамый Әхияр. Ә хатыны менә шуларны аңламый, күкәй эчендәге сары кебек кенә яшәргә теләми. Йөзгә бер тулмаган нәрсә. Аның урынында бер төйнәгән йодрыгын патша килсә дә ачмый торган йорт җанлы хатын булса, кадерен белер иде ул мондый ирнең. Салкынга өшетми, кайнарга пешерми кул өстендә генә йөртер иде. Тәрбияләп, өстеннән кош та очыртмыйча өф-өф итеп өреп кенә, рәхмәт әйтә-әйтә аркасыннан сөеп кенә яшәтер иде. Ә бу тугыз төймәдән юк! Юк, тилебәрән котырыгын әллә ниләр кыландырсаң да юк!..

Әхиярнең бүген көн буе көлеп, куанычтан балкып торган йөзе күмергә әйләнде. Ул кулларын артка куеп, авыр, салмак адымнар белән ишек яныннан әйләнеп килде.

— Һаман шул балык башымы?

— Әйе! Нишлим! Кәнсә янына тагын «Кысла»ны чыгарып элделәр. Тагын син.

— Мыскыл иткәннәрме?

— Иткәннәр. Инсәңә балта салып бүтән авылга китеп барасың. Астына җыр язганнар:

Алма пешкән, өзелеп төшкән,
Күгәрчен башын тишкән.
Акча артыннан чаба-чаба
Чәчләренә чал төшкән,—

дигәннәр.

— Минем ни зыяным тия инде аларга,— диде Әхияр ачулы сукранып.— Нигә мине күрәлмиләр, нигә ару суны куерталар. Күзләренә кылчык булып кердем инде, валлаһи.

— Күпме ялварам!.. Күңел җылап торгач, күзгә байлык күренәме?..

— Җитәр! — диде Әхияр һәм тагын ишек яныннан урап килде.— Колхоз минем ише бер инвалид кулына калган икән, ә?!. Шушындый техника заманында! Совхозда әнә эшчеләргә эш җитми. Дөньяларын машина басып алган... Ә монда һаман йөрәк итен талап ни кыланып яткан булалар... Кылтаеп... Бездә аерым законмы әллә!..

Марзия аңа тагын каршы әйтергә теләгән иде — өлгермәде: ишек шакыдылар.

— Кем йөри, керегез! — дип кычкырды Әхияр.

Бригадир Миргарифан килеп кергәч, салкын гына исәнләште дә, хатынның һөҗүме көчәя — подкрепление килде, дип уйлап куйды. Миргарифан урындыгын ишек төбенә алып утырды. Йокысызлыктан шешенгән күз кабакларын сыпырды. Марзияның, ник анда гына, түрдән үтегез, диюенә каршы, мин хәзер чыгам, йомышым бар иде, диде.

— Чәй эчеп китәрсез, хәзер самовар гөжләтәм,— дип, Марзия кече якка чыгып китте һәм чытырдатып чыра телэргә тотынды. Ирләр үзләре генә калдылар. Миргарифан ничек сүз башларга белми аптырап утырды. Авыр сулады, кулларын угалады. Әхияр, бригадирның йомышын алдан белгәнгә күрә, киресенчә, тыныч иде. Йөзенә: я, тыңлап

карыйк, сайрап җибәр, дигәндәй, сизелер-сизелмәс мыскыллы кыяфәт чыгарып, әзер җавап белән тегенең сүз әйтүен көтә иде. Радиоалгычны күргәч, Миргарифан, йомышын йомышларга җай чыгуына шатланып, иркен сулады.

— Яңамы?

— Яңа! — диде Әхияр, әзрәк ачылып.— Көндез генә кайтарып утырттым әле. Тавышы ничектер — сөйләтеп карарга да өлгермәдем.

— Минем үземә дә кирәк иде. Акчасы да әзер, юк исә. Сельпога барырга вакыт таба алмыйм. Кырык төштә кырык төрле эш. Кырыгына да житешергә кирәк.

— Бригадир булгач шулай инде, нишлисең!

— Бу яз, соң килгәнлектән, бигрәк авыр булды. Һәммә эш берьюлы тыгылды. Бүген-иртәгә чәчүне ерып чыгабыз дип торабыз инде. Әзрәк иркен сулар идек. Үзем менә чәчү беткән көнне егылып ике тәүлек рәттән йоклар идем.

Бригадир, үз сүзләренә ышандырырга теләгәндәй, авызын учы белән каплап иснәп алды. Ләкин бераз уйлангач башын чайкады.

— Юк, хыял бу. Йокы эләгер димә. Кичә клубтан орлык бәрәңгене алып бетердек кенә — бүген инде чебеш кайтарып тутырдык. Өч мең штук. Кая куясың, урын юк. Хет үкереп ела...

Әхияр дәшмәде. Миргарифанга һәм кече яктан чыгып өстәл башына утырган хатынына каш астыннан гына шелтәле карап, мин эшкә чыксам, үкереп тә, шыпырт та еламас идегез — гел көлеп кенә йөрер идегез, ә, дип уйлады.

Бригадир бер аягын икенчесенең тез өстенә куйды, бармакларын шытырдатып кулларын уды, өмет белән Әхияргә карады.

— Яшьләр клуб даулый, давай, ди. Менә бу айда, менә теге числода дигәләп көн үткәреп йөрергә туры килә. Нормальный нәрсә түгел инде — нишләмәк кирәк!.. Ә бит чеби өенең проектын ел башында ук кайтарттык, бүрәнә кистек, Ык читенә су чыкканчы кирпеч заводыннан кирпечен ташыдык. Балта осталары юклыгы аяктан ега. Теге бригадалар арттырмый: үзләре төзи. Өч өйрәнчек егет бурап ята да соң — борыннарына борыч кермәгән. Булдыра алмыйлар. Эшләре бик акрын үрли. Аларны өйрәтеп эшләтергә дөнья күргән тәҗрибәле оста табалмый интегәбез... Менә...

Шул урында Әхияр аның сүзен бүлде:

— Энем, туктасаң да ярар. Тел төбеңне әллә кайчан сизеп торам. Дөресрәге, тәрәзәдән шәүләң күренгәч тә, нинди йомыш белән йөрүеңне аңладым. Беренче үгетегез түгел бит — егерме ел үгетлисез. Элек мәҗбүри эш, суд белән куркытып карадыгыз. Бик үк өркә торган кешегә туры килмәгәч, туктадыгыз.

Бу юлы Әхиярнең үз сүзен Марзия бүлдерде:

— Сине әйтәм, кара әле. Тик торганда кешегә ник шулай бәйләнергә! Сиңа ул чын күңеленнән аптырап сөйли. Чынлап киңәш сорый... Кит инде, язмаганны... Нервный дигәч тә, шул хәтлегә җитмәм...

Бу сүзләр Әхиярне ярсытып кына җибәрде.

— Минем әле «шул хәтлегә» җиткәнем юк, — дип кычкырды ул, тавышын күтәрә төшеп.— Телем әйткәнне колагым ишетә. Ул чынлап сораса, мин дә чынлап әйтәм. Мин Ватан сугышы инвалиды. Керчь ярымутравына десант төшкәндә яраланып гарипләнгән, гомергә аксак булып калган кеше. Минем кан тамырларына литр ярым ят кеше каны җибәрелгән, белдегезме?!. Караңгы төндә автоматны баш өстенә күтәреп катердан боздай салкын диңгез эченә сикергәндә Әхиярне яраталар иде. Хәзер оныттылар. Стенгазиткә карикатурный итеп мыскыллап төшерәләр. Фашистка үлем! дип кычкыра-кычкыра, тыр-тыр ата-ата күкрәк киереп снәрәтләргә каршы барган чакта гына кирәк булганбыз икән. Значица, кәк элекке фронтовик, гварди младшы сержант сез ми-



не әзрәк хөрмәт итәргә тиеш. Ләкин мин хөрмәт сорамыйм, үзем теләгәнчә яшәргә ирек бирегез. Шул гына. Эшегезгә вакыты җиткәч чыгармын. Чеби өен дә салырмын, ни кушсагыз — шуны. Ә бүгенгә үз планнарым бар...

Миргарифан Әхиярнең мондый дулауларын күп тапкырлар ишетте. Ишеткән саен Әхияргә карап аның йөрәге әрни. Ояла, хурлана яшь бригадир. Үзен ниндидер саилче, хәер сорарга кергән кеше кебек уңайсыз хис итә. Ләкин тиз генә бер-бер нәрсә төзергә кирәк булып та осталар таба алмыйча зар елап йөргән чакларында, аптырап, тагын шушы тирәсе чыпчык очып кермәслек биек койма белән кеше күзеннән ышыкланган калай түбәле йортның ишеген кагарга мәҗбүр була.

Марзия, әле Әхияргә, әле Миргарифанга карап, рәнҗеп-рәнҗеп:

— Сугышта катнашканнарны берәү дә онытмый. Әле ничек зурлап Гитлерны җиңүнең егерме еллыгын үткәрдек. Пенсияләр артуын ал. Инвалидлар шәһәр транспортында түләүсез йөри башлады, медаль белән бүләкләнде. Шул искә алмау, санга сукмау буламыни?!. — диде.

— Шәһәрдә бит ул! — диде Әхияр.— Авыл җирендә мин, буш йөрим, дип, салам ташучы малайларның чытыр арбасына чыгып утырмам бит!.. Өч медалем сугыштан кайтканнан бирле чемоданда ята. Монысын да шулар янына салырмын... Болардан миңа ни файда?!.

Әхияр Миргарифанга арты белән борылып радиоалгычын кабызды. Минут чамасы аның кызганын көтте һәм лампочкада яшел ут күренеп, радиоалгыч талгын гына гүләргә керешкәч, тоткасын бора-бора дулкын тота башлады.

— Карале, Әхияр абый, өйрәткәләп торырга гына ие. Үзең эшләмәссең. Бүтән борчымас идем,— диде бригадир өметсез тавыш белән.

— Юк, энем, әйтсәм — берәгәйле әйтәм мин. Аягым сызлап тора, больницага барасым бар. Иртәгә ат җәлләмәссең бит?

— Атны бирермен, алмый калганың юк. Тик барыбер правлениегә әйтәм, тагын чакырсыннар... Соңыннан үпкәләшеп йөрмик, Әхияр абый.

Әхияргә болай итеп ачыктан-ачык әйтү ошамады. Ул кырт артына борылды, өзеп-өзеп:

— Синең, энекәем, минем белән алай янап сөйләшергә... башың яшь әле... Мин — Ватан өчен... синең ише малайлар бәхетле үссен, рәхәт күрсен өчен газиз канымны койган кеше...— диде.

— Э-эх, янап әйтүмени бу,— диде Миргарифан, урыныннан торып,— чебиләрне кызганып әйтүем. Бүген дүрт градус кына булды... Иртәгә дә шулай торса... Туңалар, өч мең штук бит... Э-эх!..

Миргарифан кулын селкеп чыгып китә башлады. Тик шул чакта колак төбендә генә сөйләгәндәй ап-ачык итеп «Белорусь 62» сөйләп җибәрде. Миргарифан туктап аңа колак салды.

— Тыңлагыз, Казан сөйли. Соңгы хәбәрләр тапшырабыз,— диде диктор.— Без бүген студиябезгә, Казанда булуыннан файдаланып, Бөек Ватан сугышы ветераны, Дан орденнары кавалеры, гвардия кече лейтенанты Зәки иптәш Сабировны чакырдык. Иптәш Сабиров Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк немец-фашист яуларына каршы сугышка алына. Сталинград сугышларында катнаша, Кырымга төшерелгән десант частьларының алдынгы сафында була. Сугыша-сугыша Германиягә барып житә. Өч тапкыр яралана. Госпитальләрдә дәваланып чыкканнан соң тагын фронтка ашыга. Батыр якташыбыз сугыш бетәргә бер ай калганда дүртенче мәртәбә каты яралана: сыңар кул һәм сыңар аягын югалта. Шулай булуына карамастан, тынгысыз йөрәкле коммунист хезмәт фронтында да сынатмый. Менә унбиш ел инде Актауның «Ландыш» кинотеатрында киномеханик булып эшли.

Әхияр үзенең яңа радиоалгычыннан беренче мәртәбә яңгыраган бу беренче тапшыруны селкенергә базмыйча зур игътибар белән тыңлады. Аның нәкъ алар — элекке сугышчылар хакында булуы Әхиярнең күңеленә бигрәк тә хуш килде. Безнең ишеләрне ничек мактаганнарын ишетәсезме, дигәндәй, Марзия белән Миргарифанга караштырып куйды. «Сыңар кул һәм сыңар аягын югалта... Киномеханик булып эшли» дигән сүзләр яңгырагач, түзмәде, гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде:

— Бәй, нинди таныш фамилия дип баш ватам — мин белгән Сабиров ич бу, депутат Сабиров. Такта алырга булышты!..

— Әйе шул! Үзебезнең Зәки абый! — дип, бригадир аның сүзен раслады.

— Киномеханик икәнен кем белгән аның,— дип кызды Әхияр, радионы бүтән тынламыйча.— Язын кино караганда лента өзелде дә, залда ут кабынды. Шунда, гафу итегез, кәнишне, җыен маңка малай дәррәү сызгырырга, «сапожник!» дип акырырга керешә. Төрмәгә ябарга не суккин сыннарны. Унбиш тәүлеккә түгел — күбрәккә... Гварди кече лейтенантка, Дан орденнары кавалерына, үзләре өчен утка-суга төшеп гарипләнгән фронтовикка сызгырганнар бит, ә?!. Ай шул чакта белгән булсам! Иманга китерер ием мин ул имансызларны. Ботларыннан болгап-болгап тупсага сугарга да күп сорамас идем. Мине барыбер бер нәрсә дә эшләтмиләр. Минем кызу канлы дуамал кеше икәнемне бөтен милиция белә. Ярты каным — кеше каны бит минем...

— Кешеләрнең төрлесе бар шул әле,— диде Марзия.

— Әйе-е. Андый әдәмнәрне бетерергә күп вакыт кирәк,— диде Миргарифан аңа өстәп һәм радиоалгычка якынрак килде.

Радиодан Зәки Сабировның карлыккан тавышы яңгырый иде инде. Ул иң элек Бөек Ватан сугышы, шул канлы сугышта совет кешеләренең искиткеч каһарманлыклары, фашизмны җиңү шатлыгы турында сөйләде. Аннан соң тыныч төзелеш чорына күчте һәм бүгенге көннәргә килеп җитте. Элекке солдатларның хәзерге хәлләренә, уй-хисләренә кагылды.

— Без, сугыш ветераннары, төзелеш фронтының да иң алдынгы линиясендә булырга тиешбез,— диде Зәки.— Ләкин, кызганычка каршы,

өй гарипсез булмый, дигән шикелле, элекке фронтовиклар арасында да үзенең шәхси эшен бөтен илнең гомуми эшеннән якынрак күрүчеләр очрый әле. Дөрес, андыйлар күп түгел — меңгә бер, авыл саен бер генә. Әмма бар. Аларның бер ишеләре сугышта йөрүләре, яраланулары турында чат саен кычкырып йөриләр. Менә инде егерме ел буе, мин Ватан сугышы инвалиды, мине бөтен халык хөрмәт итәргә тиеш, чөнки мин туган ил өчен, балалар бәхетле үссен, рәхәт күрсен өчен газиз канымны койган кеше, диләр. Күкрәк кагалар. Ә үзләре шул ук вакытта җәмгыятькә файдалы эштән баш тарталар, күп алырга, аз бирергә һәм үз кесәләрен калынайтырга тырышалар. Кирәк чакта фронтларда арсландай көрәшкән, ә бүген коммунизм төзү дигән изге һәм тыныч фронтта ат шикелле эшләүче миллионнарча ветераннар армиясенә кара тап төшереп яши торган мондый кешеләр безнең Актау районында да бар. Мин аларның исемнәрен атап тормыйм. Бу чыгышны тыңлаган булсалар, бәлки уйланырлар һәм...

Марзия Зәкинең бу сүзләрен гаҗәпләнүдән зур ачылган күзләре белән әле Әхияргә, әле радиоалгычка карап истән таеп тыңлады. Миргарифан белән Әхияр үзе дә аннан ким гаҗәпләнмәгәннәр иде. Әхияр җәннәт өмет итеп торган чакта җәһәннәмгә төртеп төшергән кеше шикелле аңгыраеп калды. Ул, тегеләргә күтәрелеп карарга көч тапмыйча, башын аска иеп, бөргаланып утырды да, әкрен генә кулын сузып, радиоалгычны сүндерде. Ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Ярар... җитәр! — диде һәм әкрен генә торып, әкрен генә чыгып китте.

Бераздан, таш сын шикелле хәрәкәтсез утырган Марзияның ялгызын калдырып, тавыш-тынсыз гына Миргарифан кузгалды. «Ну эләктерде Зәки абый. Кәрт ачучы чегән хатыны да бу хәтле туры китермәс. Нәкъ Әхияр абый хакында сөйләгәндәй булды. Үзе дә кая керергә тишек тапмады, бурлаттай кызарды — ә кызарган кешедә өмет бар диләр... Күптән кирәк иде, күптән»,— дип, канәгатьләнеп уйлый-уйлый капкага юнәлде. Әхияр аны күрмәде. Ул ишек алды уртасында, ә боларны нигә ташыдым соң әле мин дигәндәй, аптырап һәм шаккатып, мунча белән келәт арасына таудай өелгән нарат бүрәнәләргә карап аягүрә катып калган иде.

Август, 1965 ел.

## МОРДВА МӘКАЛЬЛӘРЕ

Оста кулда балта да — пәке.
Яхшы ишкәкче барында көймә дулкыннан курыкмый.
Иртән торган — авыз сөртә, соңга калган күз тырмый.
Ялкау ат камчыдан курыкмый.
Күмәк малны күп күз саклый.
Бердәм булган көтүгә бүре бәреп керә алмый.
Кеше авызындагы тешнең сызлаганы сизелми.
Сөтле сыер базарга барып житмичә кала.
Судтан курыкма, начар судьядан курык.
Таяк телсез, ләкин өйрәтә.
Күмер корымга буялмый.
Сазга илтеп салсаң да алтын барыбер ялтырар.
Сүз сөйләргә яратсаң, кешене дә тыңлый бел.
Кул эшләгәнне тел белән төзәтеп була, тел эшләгәнне — кул төзәтми.
Җырны бергә җырлау яхшы, ә сүзне үзең генә әйт.
Ни тартсаң, шуны илисең.
Тел белән дингез кичә, эштә — тамчыдан да курка.
Кайчы кырка, сүз кисә.

*Леонид Топчий*

## Берәүгә дә әйтмим

Үзем өчен таш-пулатлар кормыйм.
Торам гади — исләр китмәле.
Берәүгә дә әйтмим,
Сөйләп тормыйм
Бәхетем минем кайда икәнне.

Сорашыгыз моны
Сез алардан:
Киптерелгән сазлык-сайлардан,
Агачларыауган тайгалардан,
Шартлатылган
Биек таулардан...

Шаулап иген үсә ул сазлыкта,
Шәһәр тора тайга түрендә,
Нинди матур, тауда елан сыман
Бормаланып юллар күренә!

Шәһәр әйбәт, игеннәр дә бик шәп,
Мул җыярбыз уңыш-икмәкне...
Берәүгә дә әйтмим,
Тормыйм сөйләп
Минем бәхет нидә икәнне.

## Әнигә

Мәрхәмәтле, изге, карт анам,
Бераз ела инде еласаң...
Ансат түгел иде кайтканда
Юлым минем туган якларга.

Инде яшьнәп торган чагым түгел,
Төсем хәтта түгел танырлык,
Элеккедәй ләкин, сулмый күңел,
Чәчәк ата, гел таң калырлык.

Сорашма син кайда булганны,
Ниләр күреп, ниләр кылганны.
Нинди генә гомер кичмәдем —
Сиңа, әнкәй, рәхмәт хисләрем.

Үкенмә син, оныт кайгыларны,
Ялгыз үтте димә шәп чаклар.
Соң уллары бит рус аналарның
Алмаш белми торган солдатлар.

● ● ●

Ирештек ди без бар теләкләргә,
Тормыш итү җиңел инде ди,
Җан башына күпме кирәкканчә
Сөт һәм ит тә туры килде ди.

Димәк, безгә бакчаларга кереп,
Алма төпләрендә ятарга,
Көн үткәреп пенсионерлар кебек,
Гамьсез яшәп, ләчтит сатарга.

Юк! Җир ул — җир, охшаш түгел күккә,
Тыныч яшәү аңа кул түгел,
Ашау өчен генә яши икән
Әле бит чын кеше ул түгел.

Елга булып акканда да сөтләр
Гамьсезлек юк, төшен син шуңа.
Әй, кадерле кешем, сине көтә
Ул чакта да бик күп борчулар.

## Кешеләрнең алтын хыялы?

Көннәр үтеп елга әйләнәләр,
Әйләнәләр еллар гасырга.
Картаялар халыклар һәм илләр,
Картаймыйсың тик син асылда.

Гел яшь, буыннардан буыннарга
Күчәсең син гизеп дөньяны,
Азатлык һәм хаклык турындагы
Кешеләрнең алтын хыялы.

Тартасың син үзеңә мавыктырып,
Көчсезләргә хәтта рух биреп,
Кешене кара язмышыннан йолып,
Әйттермәскә кабат кол диеп.

Көрәшләргә өндәп, ачып таңны,
Күрсәтәсең яңа дөньяны,
Азатлык һәм хаклык турындагы
Кешеләрнең алтын хыялы.

• • •

Кыланудан мин бер кызык тапмыйм,
Кол итәрлек җырлар язмадым.
Шигырьләрдә прозаны яклыйм, —
Гади сүзләр минем язганым.

Талантымны бирәм тик тормышка,
Шатлык, сагыш бүлешәм мин аңар.
Кирәк түгел мактау һәм алкышлар,
Була бирсен түбән гонорар.

Тел тыймадым микән кирәгендә,
Адаштыммы юллар кичкәндә?
Тик гомеремнең күп еллары белән
Түләдем мин борчу, шикләргә.

Һаман сөйдем ләкин якты таңны,
Хыялландым аяз көн көтеп,
Нинди әйбәт әгәр шагыйрь җаны
Саф һәм ачык булса көн кебек.

• • •

Печән исе,
Чәчәк исе аңкый!..
Төн.
Диңгездә көмеш тамчылар
Чәчрәп балкый.
Элек шулай иде,
Ә хәзер бер сихри төш сыман,
Гаҗәп әкият сыман барсы да.
Бер тына, бер ташып күтәрелә
Безнең хисләр кинәт ярсый да.
Юк, борчымый мине инде сөю,
Ниндидер бер башка тойгылар,
Сөюдән дә өстен,
Нәфис хисләр
Йөрәгемдә минем уйныйлар.

*Нури АРСЛАНОВ* тәрҗемәләре.

Фатих Хөсни

# БЕРТУГАН ТАҺИРОВЛАР



*ДРАМА 4 ПӘРДӘДӘ, 6 КҮРЕНЕШТӘ*

КАТНАШАЛАР:

Закир Таһиров — колхоз председателе. 55—56 яшьләрдә.

Камәрия — аның хатыны, 46—47 тирәләрендә.

Зариф Таһиров — доцент, Казанда авыл хуҗалыгы белән бәйләнешле югары уку йортларының берсендә укыта, Закирның энесе, 53—54 яшьләр тирәсе.

Заһит Таһиров — кече энеләре, 33 яшьләрдә.

Мәхмүт Корбанов — колхозда бригадир, бер үк вакытта партоешма секретаре да, 33—34 яшьләр тирәсе.

Гөләндәм — Мәхмүтнең хатыны, 30—31 яшьләрдә.

Әкълимә — авылда «Шома Әкълимә» дип тә җибәргәлиләр. Икеме, өчме ирдән аерылып кайткан, хәзер дүртенчесен кулга төшерергә чамалап йөри, 30 яшьләрдә.

Тансык — Закир Таһировларның, озак көттереп туган, бердәнбер бик кадерле малае, 12 яшендә.

Касыйм — колхозда тракторчы, Гөләндәмнең төп йортта калган энесе.

Почтальон, шофер һ. б.

Вакыйга 1950 елларның икенче яртысында бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Колхоз председателе Закир Таһировның заманнан калышмаска тырышып җиһазландырылган бай гына өе. Бер читтә язу өстәле, телефон. Каршы як стенада Закир һәм Заһит Таһировларның, җилкәгә кулны салып, агай-энеләрчә бергә төшкән портреты — зурайтылган, пөхтә рамда, пыяла астында. Заһиты, чәчне-башны кая куярга белмәгәндәй, аеруча түшне киереп төшкән — яшь чак, дәртле чак, килешеп тора тагы үзенә... Пәрдә ачылганда, Закирның хатыны Камәриянең зал ягындагы аш өстәленә табын әзерләп йөргәне күренә.

Камәрия *(үзалдына сөйләнеп)*. Колхоз күрмәгәнме инде Зариф абый, йөртә дә йөртә бугай кешене тинтерәтеп. Мактанырга дисәң, безнекенә куш инде... *(Пауза.)* Бертуган энесе, эш белән йөрешли, әйләнгечне туры итеп, кагылган, ә безнеке — коры куаныч — имештер, ин

элек колхозны күрсәтә. Туган-тумача хәлләрен сорашып, рәхәтләнеп бер чәй эчеп утырасы...

Тансык йөгереп керә. Кызарган, тирләгән. Кунак абыйсы, бигрәк тә аның «Победа»сы өчен очынганлыгы әллә кайдан күренеп тора.

Т а н с ы к. Әни, Турабый белән әти фермага кереп калдылар, озаклamый кайтып җитәрбез, диделәр. *(Бераздан уйлап тапкандай.)* Әни, кибеткә барып кайтыргамы? Турабыйга кирәк булыр микән?

К а м ә р и я *(ачуланып)*. Синең эшең түгел, йөрмә зурлар эшенә кысылып. Өйрәндең син кибеткә барган саен сдача акчасын кыстырып калырга.

Т а н с ы к. Кирәк ие бик синең сдача акчаң. Әти барыбер җибәрә мине, менә күрерсең. *(Борынын сала төшеп, чыга башлый.)* Мин Турабыйның шоферы янына, машина юарга киттем. Ул инештә машина юа.

К а м ә р и я *(беркадәр йомшый төшеп)*. Син, малай актыгы, һич югы Зариф абыеңның исемен дөрес әйтергә өйрәнер идең. Бәләкәй чагында яраган «Турабый» хәзер килешми, дүртенче классны бетердең бит син быел.

Т а н с ы к. Ә мин менә юри өйрәнмим, юри шулай бозып әйтәм. Кибеткә җибәрмәдең әле үзең. *(Чыгып киткәч, кире әйләнеп керә, ялагайланып, әнисе тирәсендә сырпалана.)* Шофер абый мине «Победа»сына утыртып урам әйләндерде, әни. Киткәнче әле тагын әйләнербез, диде. Менә машинаны гына юып бетерәбез дә... Әни дим, шул абыйга аз гына алып төшим инде. Күрдем ич теге як сәкесендә. Кызылын гына булса да бир инде.

К а м ә р и я *(тәмам җене чыгып)*. Бирермен мин сиңа кызылын, булмас йортка бөкре туган нәстә. *(Кыздырмакчы булып, малайга ташлана, ләкин теге китеп өлгерә.)* Аның ишеләр, тырышып-тырмашып, мәктәп бакчасында чүп утый, ә бу җүнсез юк кына башыннан шешә тирәсендә ялманып йөри. Шофер абыйга, имеш. Өйрәтте соң теге карт тилесе. Янәсе, бердәнбере. *(Пауза.)* Кайтсалар кайтмадылар, болай озак чуаласыларын белгән булсам... берәр җылы ризык әзерләргә дә өлгерәсем икән. Көндезге савымга хәтле. *(Урам тәрәзәгә күзе төшеп.)* Әкълимә җаным, әллә синең китеп тә барышың инде?

Урам ягыннан тавыш. Пожар юктыр әле ул хәтле чабарга. Кызыл тактага синең белән мине барыбер язмыйлар.

К а м ә р и я. Мин барып җитмәсәм, зинһар өчен дип әйтәм, Әкълимә, шунда беррәттән Хәерниса белән бүлешеп минекеләрне дә сава күрегез, малай. Безнең өйдә бүген уйламаганда килеп чыккан зур кунак: Казаннан Закир абыеңның бертуган энесе кайтты.

Урамнан тавыш. Сабан туе дип кайткан мәллә? Әче бал мичкәләрен юып куйганнан соң...

К а м ә р и я. Үз эшләре белән... үтеп барышы.

Урамнан тавыш. Шулай да Казан хәтле Казаннан коры кул белән кайтмагандыр әле. Казан күчтәнәчләреннән миңа авыз иттерерлек булсаң, хет бүген бөтенләй барма. Миннән рөхсәт. *(Шаркылдап көлә-көлә үтә.)*

К а м ә р и я. Эш белән йөрүче кеше төягәндер сиңа күчтәнәч... *(Пауза.)* Менә ичмасам, чак кына тынычлангандай булдым. Шулай да бик озак йөртте бу кунакны. Укымышлы энем еш йөрми, күренгәндә мактанып калыйм, ди торгандыр инде. *(Эшен, әзерлек чараларын дәвам иттерә.)*

Ачык тәрәзә алдында, ишек алды ягыннан Гөләндәм күренә.

Г ө л ә н д ә м. Сау гынамы, Камәрия апа? Минем Мәхмүт күренмәдеме шушы тирәдә? Закир абыйда йомышым бар дигән иде.

К а м ә р и я. И, аларны бер генә урында тотып буламы соң? Безнеке бүген кунагы белән. Кайтып, бер утырып чәй эчү юк, колхозымны күрсәтәм, дип алып китте.

Г ө л ә н д ә м. Сездә кунак бар икән шул, бая Тансык сөенеч алды инде. Ничек алай ялгыз гына кайтасы иткән соң?

К а м ә р и я. Эше буенча үтешли сугылуы. «Кызыл Байрак» совхозында нәрсәдер яңа төр бодай диме... Эше шундый бит аның. *(Пауза.)* Өйгә уз, Гөләндәм. Бергә булсалар, менә үзләре дә кайтып җитәрләр: күрүен күрсә, Мәхмүтне калдырмый инде безнеке.

Г ө л ә н д ә м *(рамдагы зурайтылган портретларны күреп)*. Кайчан эшләттегез ул карточканы, Камәрия апа? *(Кермәс җиреннән кереп.)* Күргәнем юк иде, шундый килешле чыккан. Барысына да өлгерә Закир абый.

К а м ә р и я. Эшләтер Закир абыең. Яз көне, терлекчеләр киңәшмәсенә барганда, үзем алып барып биреп кайткан идем. Зурайтып җибәрделәр. Безнеке дә яшь чагында кешегә охшаган булган бит... Хәзерге «Ике әйтмәм Закир» дип белмәссең.

Г ө л ә н д ә м. Аның янындагысы кем соң? Заһит абыймы дип әйтим?

К а м ә р и я *(игътибар итмәгәнгә салышып)*. Нишләп сиңа абый булсын икән Заһит?.. Икегез бер чама түгелме соң сез?

Г ө л ә н д ә м. Кем белеп бетергән инде әллә кайчандагыларны... *(Пауза.)* Безнең дә бар иде зурайттырып аласы карточка, Мәхмүткә әйтим әле. *(Камәрия уз эше белән үтеп-сүтеп йөргән арада, карточкага игътибар беләнрәк текәлеп, узалдына.)* Булыр икән бу хәтле үз төсе белән чыккан карточка! Бер чама гына түгел, бер мәктәптә, бер класста укыдык без аның белән. Ә кешегә әйтеп булмый торганы күпме!.. *(Кинәт исенә килгәндәй, чыгарга кабаланып.)* Нишләп болай эшле кеше янында катып калдым әле мин? Син дә куып чыгара белмисең, ичмасам, Камәрия апа. *(Ишеккә бара. Ләкин чыгып өлгерә алмый, туганнарча шау-гөр килеп кайтучы Закир белән Зариф аның юлын бүләләр.)*

З а к и р *(Гөләндәмнең юлына аркылы төшеп)*. Постой, бик алай танытмыйча узып китәргә маташма. Менә бу кешене Зариф абыең диләр. Белмәсәң — белеп кит, профессор...

З а р и ф. Я... син тагы бигрәк, абый, ишек янында ук кешенең анкетасын тутыртмакчы... *(Гөләндәмгә текәлеп.)* Тануын танып ук бетермим, әмма безнең авыл токымы булса кирәк. Ә безнең авылда начар токым булмас. *(Күрешергә дип кулын суза.)*

З а к и р *(кунагы сүзеннән үсенеп)*. Шәп әйттең, Зариф туган. Дөрес әйттең, минем колхозда начар токым булмас! *(Гөләндәмгә.)* Ник авызыңа су кабып торасың, син дә чатылдатып җавабыңны бир: киләчәк яшь буынны кайгыртучы, ясле балаларына дип, көн саен Закир абыеннан сөт, май таптыручы, Кызыл байраклы колхоз яслесенең Кызыл байраклы мөдире диген. *(Зарифка.)* Әле алай гынамы, энекәш: колхоз партоешмасы секретаре Мәхмүт Корбановның хәләл җефете дә менә шушы кеше була инде. Туйларында баш кода булып үзем утырдым. *(Гөләндәмгә.)* Ике әйтеп тормам, хәзер үк, исән булса — исән килеш, чирләп егылган икән — егылган җиреннән өстерәп, теге белдекле башыңны алып кил. Аннан башка тамагымнан аш үтмәгәнне беләсең.

З а р и ф. Анысы кем була тагы? Сине алай тамактан калдыра торганы?

З а к и р *(Гөләндәмгә ишарәләп)*. Әйтеп торам ич: менә моның интеллигенты. Кирәгеннән артык күпне белергә маташуын исәпкә алмаганда, ярыйсы кеше болай. Кыскасы, күрше, көттермәгез, кунакның вакыты чамалы потому-што.

Г ө л ә н д ә м *(тартына төшеп)*. Бездән башка да үтәр әле бер генә юлы, Закир абый.

З а к и р *(кырт өзеп)*. Мине «Ике әйтмәм Закир» диләр, чибәрем. Аны белә торгансың. Шуның өстенә тагын менә бу кала кешесенең дә,

үземнең дә зерә дә тамак чатнады, момент китереп җиткер интеллигентыңны. *(Гөләндәм чыга.)*

З а р и ф. Күрәм, син, элеккечә үк, бик югартын торып сөйләшәсең кешеләр белән.

З а к и р *(мактану тоны беләнрәк)*. Эше шулай башны югары тотарга мәҗбүр итә, энекәш. Югыйсә, монда бик алай ваклап турый башласаң, хәтәр. Тураган калҗаң белән бергә үзеңне дә йотып җибәрүләре бар.

З а р и ф. Алай булгач бигрәк тә алны-артны уйлап сөйләшергә кирәктер, миңа калса.

З а к и р. Артымда шушы колхоз өчен чыккан бөкре, алдымда шулай үк шыр ялангач кыр түгел. Ике дә уйламыйм, ичмасам. *(Камәриягә.)* Сиңайтәм, кая, кунакка кул юарга чыгар әле.

К а м ә р и я муенына кызыл башлы озын сөлге элеп, ялтырап торган кечкенә җиз таз белән җиз комган күтәреп чыга.

Нәрсә син, әнкәсе? Мыскыл итүеңме бу? Казан кешесе, профессор кеше мондый иске тормыш калдыгыннан юынамы соң?

К а м ә р и я. Ә мин аны, зур укыган туганыбыз итеп, салкын чишмә суы белән, үзем салып торып юындырасым килә. Болай да рәтләп җиңги хезмәте күрсәтеп булмады энекәшләргә.

З а р и ф. Болай булгач каршы сүзгә урын калмады, иптәш председатель. Син, башыңны югары тоткан килеш, басып тора бир, ә мин, үзең әйтмешли, профессор башымны рядовой колхозчы алдына иеп, чишмә суы белән тиз генә кулны йөгертеп алыйм әле. *(Юына.)* Абзаркура арасында йөргәннән инде... Юкса, кул юган арты сезнең әле табынга дип кыстый башлавыгыз да бар.

З а к и р *(аның сүзен уенга алып)*. Ягъни без, шәһәр кешесе, профессор кеше, кыстатмыйча гына утырабыз, димәкче буласың инде син?

З а р и ф. Кызганычка каршы, алай димәкче булмыйм. Чәйләп торырга вакытым юк, расписание сыйдырмый, димәкче булам.

З а к и р *(төшенеп җитмәгәндәй)*. То-есть чәйләп тормаска мөмкин. Әгәр нәфесең теләмәсә... Но, ике-өч елга бер туган авылга сугылып, абыең белән чак кына мәйләп алмасаң, аяз көнне яшен сугуы бар. *(Хатынына.)* Ишеттеңме, хатын, нәрсә ди бу укымышлы баш? Сезнең ише кара корсаклар белән утырып, чәйләп торырга вакытым юк, ди.

К а м ә р и я. Ишетергә дә, тыңларга да теләмим. Сиңа да юк сүз белән вакыт уздырмаска кушам.

З а р и ф. Шулай, Камәрия җиңги. Бу турыда дискуссия ачмыйбыз. Зинһар, гафу итә күрегез, вакыты шундый, совхоздан бүген үк килеп җитәргә дип хәбәр иттеләр, эш көтә.

З а к и р *(әле һаман өнгә килеп җитә алмагандай)*. Ишетәсеңдер, хатын, көпә-көндез ни сөйли кеше?

З а р и ф *(Закирның сүзләренә колак та салмастан, Камәриягә)*. Әле бу урап чыгуым да... Фәүзия килендәшегез ай-ваема куймады, вак-төяк күчтәнәчләр әзерләгән булган икән дә... *(Ачык тәрәзәгә килеп, шоферына.)* Хөсәен, анда безнең ящиклы төргәк бар иде арткы кабинада, керт әле шуны.

К а м ә р и я *(үпкәли төшеп)*. Бер дә харап, алар сүзе генә сүз. Аларга, узып барышлый, күчтәнәч ташырга да ярасын, ә бездә бер утырып чәй эчәргә дә ярамасын. Кирәкми, алмыйм күчтәнәчегезне...

З а к и р. Син, әнкәсе, күчтәнәчкә отказ сукма. Кертсен, калдырсын. Фәүзия килен син түгел, минем нәрсә яратканны чамалый. Шәт, теге йолдызлылар да бардыр.

Ш о ф е р Хөсәен сүзсез генә төргәк кертеп чыга.

Камәрия *(ирена)*. Комагайланма әле зинһар өчен, күрмәгәндәй булып... һич югы, юл аягы дигән булып та кыстый белмисең... Безнең ризык та хәрәм түгелдер.

Зариф. Күрәм, Камәрия җиңги чынлап торып үпкәләргә өлгерде. Я инде алайса, аштан олы түгел дигәндәй... *(Табынга якынлаша, ләкин утырмый.)* Туган-тумача белән араның бозылмаганы яхшы.

Закир *(аптырап, нәрсәдән тотынырга белмичә)*. Сиңа әйтүе ансат, энкәсе... Имештер, «юл аягы». Юлның башы булмады, аягын ничек тапмак кирәк. Кайсын тотасың, энекәш?

Зариф. Берсен дә тотмыйм, печенема ярамый. Әнә, Камәрия җиңги куе итеп бер чынаяк чәй ясап бирсен дә...

Закир *(кыза төшеп)*. Шуның белән өстән бурычны төшермәкче буласың, әйеме? *(Тәкәллефсез рәвештә.)* Утыр әле син, энекәш... «Басып ашама, ипиеңнең валчыгын коясың» — без бәләкәй чакта әни шулай дип тирги торган ие бит безне.

Зариф. Хәтер яхшы икән әле синең, абый. Склероздан зарланыр урының юк. Шулай да без вакыт белән исәпләшергә өйрәнгәнбез, безнең академически эштә шунсыз мөмкин түгел. *(Ашыкканлыгын белдереп, сәгатенә карый.)*

Камәрия *(ирена шелтә белдергәндәй)*. Күп сөйләшмичә генә эшеңне кара инде. Бу хәтле оешмаган җан булырсың икән.

Закир *(хатыны сүзеннән хурлангандай, кызу тотынып)*. Алайса, чорт с ним. Утырмасаң утырмассың, хатын алдында минем афтаритетны төшермәстәй итеп, менә шушы йомшагын гына урынына илтеп куй әле. *(Рюмка тоттыра.)* Шуны тиешле урынына чөйкәлтеп җибәрсәң, «яшәсен минем профессор брат!» дип урра кычкырырга әзер торам.

Зариф. Урра кычкырырга иртәрәк әле, профессор булганчы докторскийны яклыйсы бар. Совхозга да шул диссертация йомышлары буенча чабуым.

Закир. Менә шуннан соң аяк бигрәк тә тибеш йөгерә инде. Я, кулны талдырма.

Зариф. Печень белән берәр хәл була-нитә калса, безнең кафедра алдында син җавап бирерсең, брат. *(Тәкәллеф белән рюмканы баш очынарак күтәрә төшеп.)* Фәннең практикага якынрак килә төшүе өчен! *(Эчә.)* Ләкин «урра!» кычкырмыйбыз, агай-эне. *(Акыл бирергә тырышып.)* Һәм, гомумән, өлкән туганым буларак киңәш биреп әйтүем, син бу нәрсә белән бик чуалма, иптәш председатель.

Камәрия. Ныграк кыздыр, Зариф, мин әйткәнгә генә колак салмый.

Закир. Печень авыртмый бит минем, энекәш. Шулай ук теге... Нәрсә дисең әле? Диссертация дә яклыйсым юк. *(Якланып китеп рюмкаларга яңадан коя.)*

Зариф. Миңа булды, бусын да җиңги-абыстай үпкәләмәсен дип кенә тоттым. Рәхмәт.

Закир. Ә монысын менә мин үпкәләмәсен дип тот.

Зариф. Артык бер тамчы да бармый. Норма, агай-эне, норма.

Эчке жилет кесәләрендә казына торгач, канәфер чыгарып, авызында әүшәли башлый.

Закир *(Зарифның бу хәрәкәтләрен игътибар белән күзәтеп торганнан соң, сәерсенеп)*. Анысы нинди әкәмәт тагын? Әнә ул авызыңда мәтәштерә торганың?

Зариф. Ә ул — гвоздика дигәннәре... Канәфер ди бугай татар. Авыздан юк-бар исне алу өчен. Күз буяу икенче төрле әйткәндә.

Закир. Күз буяу түгел, авыз буяу була инде ул, алайса. Миндә дә төрле чак туры килә, энекәш, запасы булса, калдыр әле миңа да биш-алты гына штук.

Камәрия *(кисәтеп)*. Закир! Кыланмасын икән кеше, бала-чага кебек!

Закир. Күп шауламa, карчык, энекәш үзебезнеке. Әнә теге интеллигентның, Мәүлә малае Мәхмүтне әйтүем, борыны бик сизгер: юк-бар нсне момент сизеп ала. Парторг итеп куйган булдым, шуннан бирле бөтенләй бозылды. Берәрне тотмыйбызмы соң?.. мондый «сихер» дә булгач?

Зариф *(кистереп)*. Әйткән сиңа: норма есть норма!

Закир. Минем норманың корсагы киң, гаеп итеш булмасын алайса. *(Эчеп җибәрә.)* Шуннан шул: парторг итеп куйгач, бөтенләй тамактан калды егетем. Рюмка тотарга дисәң, элек уңга, аннары сулга карый.

Зариф. Парторгны да син генә куясыңмыни? Сездә шул, агай-эне, бөтенләй икенче тәртип икән. Бездә, мәсәлән, парторг дигән кешене коммунистлар сайлап куялар.

Закир. Бусы да шул интеллигент! Сүзгә бәйләнергә тотынды. Бозып бетердек кешеләрне шулай нечкәрткән булып... *(Житди.)* Узганны сагына дип әйтмә, Зариф туган, әмма сугыш елларында без алай кәнфитләнеп тормый идек. Җыен бала-чага, карт-коры, кыз-хатын белән дигәндәй, колхозны сөйрәп чыктым бит. Фронтына да бирдек, үзебез дә ач булмадык. *(Пауза.)* Хәер, яшь чак, гайрәтле чак, үзем дә, туганкай, сүзгә бәйләнеп маташырга юл куймый идем.

Зариф. Үземә күрә бер культ идем димәкче буласың, әйе бит?

Закир. Тагын сүзгә бәйләнергә тотынды. *(Кыстап.)* Син иң элек минә тот әле, аннары мине төзәтә башларсың. *(Җитдиләшә төшеп.)* Дөресен әйткәндә, агай-эне, сине якын итеп кенә чишелүем, гаепкә алма: ул «культ, культ!» дип шаулаулары Мәскәү, Казан өчен бәлки кирәктер, мин үзем, сүздән әйтсәк, безнең авыл җирендә аның фактический нигезен тапмыйм. Без — электә дә шул без идек, хәзергесе көндә дә шөшлегә әйләнмәдек.

Зариф. Әлбәттә, син моны минем алда гына әйтә торгансыңдыр. Югыйсә, мин сине башына ни килде — шуны сөйләп йөри торган кешедер дип уйламыйм. Беләсеңме, борынгы бер француз патшасы ни дигән? «Әгәр мин, башымдагы уйларны бүрегем белә башлады, дип шикләнсәм, бүрегемне шундук тотып утка ягам» дигән. Бүрек әрәм була дип тормый кеше, кара син аны... *(Стенадагы зурайтылган портретны күреп.)* Тукта әле, тукта, болар кемнәр монда? Безнең алда болай авыз ерып утыручылар? Әлеге дә баягы: колхоз «культы» үзе. Ә берсе... Дөрес күрәмме? Теге малай түгелме соң бу? Чәче шулай кепкасына сыймаслык калын идемени соң аның? Онытып та бетергәнмен, дөнья мәшәкатьләреннән баш әйләнгән соң...

Камәрия. Өйдән чыгып киткәненә унбиш ел. Ул киткәч дөньяга килгән Тансыкка да унике тулды инде.

Зариф *(уйланып)*. Уза гомер... *(Закирга.)* Үзара гына әйткәндә, син, абый, тагы бераз җиңел караш күрсәтмисең микән бу мәсьәләдә?

Закир. Нәрсәдә икән анысы, безнең баш җитмәгәне?

Зариф *(стенадагы карточкага күрсәтеп)*. Менә бу ярты стенаны биләп торган фотоны әйтергә була, һич югы. Заһит мәсьәләсе хәзергә әле ачыкланып җитмәгән, ә син, аның белән кочакланышып, стенага кунаклап өлгергәнсең.

Закир. Әнә Камәрия эше анысы. Ул оста безнең андый юк-бар эшләргә. Ә минем, күрәсең, күз җитмәгән. Аннары, егет, син теләсәң ничек уйла, *(тавышын кыса төшеп)* мин ул пумала башны элек-электән ярата идем. Әнинең дә иң яраткан баласы иде ич ул.

Зариф. Икенче мәртәбә әнине искә төшерәсең бүген, хәтереңечен рәхмәт. *(Утә җитди.)* Ә мин яратмаганнан әйтәмме? Бала булма син,

туган итеп әйткәнне бел: кешенең яхшысы, кара эчлесе бар, вакытыннан элек чаң сугып, мәхәлләне бутама.

Болар шулай аяк өсли бәхәсләшеп әвәрә килгәндә, Тансык култык астына ярты бутылка кызыл аракы кыстырып, кече яктан ишек алдына шылмакчы, ләкин, әнисе «нәни разбойник»ны күреп өлгерде.

Камәрия. Тукта әле, малай актыгы! Нәрсә синең анда... култык астында?

Тансык *(ни әйтергә дә белмичә, аптырап)*. Бу ни... шофер абыйга. Катать иткән өчен.

Зариф *(коры гына)*. Ә шоферга юл йөргәндә аракы эчерергә ярамаганны белмисеңмени син, бәләкәй Закир?

Камәрия. Ныграк кыздырчы шуны, абыйсы, югыйсә, соңгы вакытта киртәдән чыга башлады. Әнә этисе узындыра.

Закир. Как же! Ничә еллардан бирле кәтеп алган бердәнбер малай ич ул минем. *(Шаярган булып, малайны иркәләп.)* Әйт, улым, яшермә. Монда барысы да үз кешеләр: бәлкем, мәйтәм, тәмен беләсең килеп алгансыңдыр? «Шофер абыйга» дип маташтыра гына торгансыңдыр?

Тансык *(кирелә́неп, бер үк вакытта якланып)*. Алган! Кирәк ие бик. Синнән элегрәк белгән инде аның тәмен.

Зариф. Здорово! Сүзгә аптырап тормый сезнең бу герой. Күреп торам, җиңги эше түгел, синең продукт бу, абый. Бәлки әле бергә утырып эчкәли дә торгансыздыр?

Закир *(сүзне гел уенга борырга тырышып)*. Моңарчы туры килмәде. Булмаганны булды дип хәрәмләшер хәлем юк. Ә бүген менә, профессор булырга укучы кадерле абыйсы кайту шәрәфенә... и шуның янына тагын җавапны да оста бирде... И шуларның барысы өчен дә кил әле, тишек борын, хөрмәтле дәү абыең алдында икәү бер чәкәшеп күтәрик әле... Курыкма, әнисе, кызылны гына.

Зариф *(нәрсә дип әйтергә дә белмичә кулларын җәеп)*. Нәрсә дип әйтмәк кирәк бу җилъяк кешегә. Менә шулай бозып бетерәбез инде без яшь буынның ашказанын. *(Канәфер каба, сәгатенә карый.)* Однако, тоткарладыгыз сез мине бу спектаклегез белән. *(Тәрәзәдән боерык тоны белән.)* Заводить итә башла, Хөсәен... хәзер китәбез.

Камәрия *(малайны өстәл яныннан йолкып алып, ишектән чыгарып җибәрә)*. Оялмыйсың да, ичмасам... Булмас йортка бөкре туган нәрсә.

Закир *(хатыны каршына килеп, ачуланган да, үчекләгән дә кебек кыланып)*. Каты кагыласың, Казан кешесе алдында оят... Зарифка замечание ясаса да килешә: кунак кеше, профессор, аракы эчми, эчсә, кабып җибәрергә кесәсендә генә, тәк сказать, канәфере. Ә син нәрсә беләсең, иске тормыш калдыгы... Бүгенгесе көндә яшь буын белән шулай тупас кылану ярыймы соң, фактический алып әйткәндә...

Тәрәзә каршында почтальон Хәйдәр шәүләсе.

Хәйдәр *(тәрәзә каршына килеп)*. Барыгыз да өйдә чак туры килде, кабул итеп алыгыз, сезгә телеграмма.

Барысы да кәтеп, сагаеп калалар. Закир тәрәзә аша гына кул куеп ала да укый, тагын бер укый. Кинәт бөтенләй җитдиләнеп кала, мондагыларның әле берсенә, аннары икенчесенә карый. Тик шуннан соң гына телеграмманы бер сүзсез Зарифка суза.

Зариф *(укып)*. Нәрсә дисең... Кайта икән, димәк, кайта.

Камәрия *(сабырсызлана төшеп)*. Ник авызыгыздан сүз чыкмый: кем кайта? Кайчан кайта?

Закир *(хатынын бөтенләй игътибарсыз калдырып, энесенә мөрәҗәгать итеп)*. Син монда чакта туры килү ярады әле. Ничегрәк инде

аны? То-есть, белгән юк, ничек кайта, ничек каршыларга, дип соравым. Бөтенләй көтмәгәндә бит, панимаешь.

Камәрия *(телеграммадан күз йөртеп, шатланып)*. Бар икән, ходаем... Гомере булгач, бер әйләнеп кайта кеше... Тансык! Син кайда? Ишеттеңме, улым, Нәнә-абыең кайта.

Телеграмманы тотып, малаена күрсәтергә дип чыгып китә.

Зариф *(озак кына уйланып торганнан соң, сүзләрен үлчәп-үлчәп кенә)*. Однако, Камәрия җиңгинең, вакытыннан элек, болай очынуын мин үзем аңлап җитмәдем. Кала алып кайтмый бит кеше. Син мине дөрес аңларга тиешсең, абый. Кече энебезнең исән-сау әйләнеп кайтуы минем өчен дә, әлбәттә, зур куаныч. Ләкин... Кайчакта кешенең, үзеннән элек, күләгәсе сузылып төшүчән... Кыскасы, кайтсын, күр, сөйләш. Әлбәттә, үз положениеңне дә истән чыгарма. *(Тәрәзәгә.)* Хөсәен, әзерме син анда? Ну, бир кулыңны, җоласына китерик.

Кул кысышып көрешәләр.

Закир. Кайчан икәнен дә әйтмәгән, ичмасам. Алмага кая барырга да белгән юк.

Зариф. Анысы зур мәсьәлә түгел. Кайтам дигәч, алмага бармасаң да кайтыр. Төчеләнергә соңыннан да өлгерерсең, иң элек алды-арты белән кызыксын. Кайтуның ни төрлесе юк та, китүнең ниндие юк. *(Паузадан соң.)* Кайтып урнашкач, үзең чамаларсың, онытып бетермәгән булса, миңа — Казанга килеп чыксын. Как же, брат бит. *(Ишеккә килеп җиткәч, кире борылып, тавышын кыса төшеп.)* Әллә, минем диссертация мәшәкатьләре узганчы, кунак-кунак уйнашуларны калдырып торыйкмы?

Закир. Кунак-кунак уйнашырлыкмы? Анысын бит әле белмибез.

Зариф. Мондый чуалчык мәсьәләдә «белмибез!» дип ачык авыз булып торсаң, соңыннан бер заман шундый итеп искә төшерүләре бар. «Ай-һай ла, ник баштарак як-ягыма каранмадым икән!» диярсең. Ышан син заманага. *(Тавышына нык басым ясап.)* Юк, Закир абый, безгә белмичә торырга ярамый. Бәлки, кайтып бераз кунак булгач, күрәсен күргәч дигәндәй, ул үзе дә монда ябышып ятмас? Ну, ул чаклысын үзең чамаларсың инде, дөнья күрмәгән кеше түгел.

Чыгалар. Бераздан ишек алдыннан озату ыгы-зыгысы: «Рәхмәт хөрмәтегезгә», «Онытып бетермәгез берүк», «Фәүзия килендәшкә барыбыздан да күп итеп, күп итеп сәлам әйт» кебек сүзләр, өзек-өзек автомобиль гудоклары ишетелә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Закир Таһировлар өе. Пәрдә ачылганда, Тансык бер читтә, идәнгә чүп-чарларын теләгәнчә коеп, юнышып, нәрсәдер ясап азаплана. Бераздан, бер кочак талкышлы сүс күтәреп, Заһит керә.

Заһит *(сүс бәйләмен ишек катына ташлап, куанычлы шуклык белән)*. Менә, дус, мин дә эш таптым үземә. Иртәгесе көннән колхозга бау ишә башлыйм.

Тансык. Өйне чүплисең ич, ник өйгә апкердең? Әни ачуланса, кара аны...

Заһит. Эләксә, икебезгә дә эләгә инде, агай-эне. Син дә монда җавап бирүдән бик куркып тормагансың.

Тансык. Мин үзем себерәм, чүпләсәм...

Заһит. Ә мин юа да беләм, әгәр эш аңа килеп терәлсә...

Пауза.

Тансык *(абыйсына гаҗәпләнеп карап куя).* Ирләр идән юамыни? Әйтәсең генәдер.

Заһит. Юа шул менә, башына төшсә. *(Сүс бәйләмен кире күтәреп.)* Өйалдына чыгарырга дисең алайса бу байлыкны?

Тансык *(абыйсы әйләнеп кергәч, кызыксыну һәм беркадәр малайлык өянәге белән).* Әллә, абый, анда идән дә юдыралар иеме, син булган җирдә?

Заһит *(почмактагы китап шүрлегендә нидер актарынган җиреннән, игътибарсыз гына).* Анда, агай-эне, эшкә аптырап тормадык без... Монда гына ул кунак та кунак.

Тансык. Ни актарынасың анда? Минем китаплар арасында?

Заһит. Заманасында минекеләр дә шушында була иде... Юк менә хәзер.

Тансык. Сыер-сарык рәсемнәре төшерелгән китапларны әйтәсеңме? Беләм мин аларны. Янында шәмәхә кара белән язган дәфтәрләре дә бар.

Заһит. Нәкъ үзе. Кайда алар?

Тансык. Ә сиңа нигә кирәк? Әйт, син әйтсәң, мин әйтәм.

Заһит. Әйтергәме икән? Ну, чорт с тобой. Энекәш үземнеке, кеше-карага шаулап йөрмәс. *(Җитди.)* Мин уйлаганча барып чыкса әгәр, яңадан шул терлек-туар ягына барып егылырга исәп. *(Мактану тоны белән.)* Заманасында мин ветеринарное училище бетереп, колхоз фермасында ветфельдшер булып чапкан кеше. Белмәсәң, бел абыеңны.

Тансык. Үзе иртәгә бау ишә башлыйм, ди.

Заһит. Ул бит болай гына... тик торасы килмәгәннән генә.

Тансык *(абыйсы сүзеннән колагы торып).* Тик торасың килмиме? Тик торасың килмәсә, бер эш бар сиңа, абый. *(Төчеләнеп.)* Абыем, жаным! Мин дә синең йомышларыңны тыңлар ием: шул эшне генә эшлә инде. Әни кайтканчы.

Заһит. Бик өзелеп әйттең бусын. Әллә әниең кушып киткән эшме?

Тансык. Бакчадан бәрәңге алып, ул кайтканчы әрчеп, юып куярга.

Заһит. Шул эш һаман эшләнмәгәнме?

Тансык. Эшләнергә... *(Янындагы йомычкаларга, ясала башлап ташланган тәгәрмәч кисәкләренә ишарәләп.)* Менә бит бу эш килеп чыкты.

Заһит. Шуның янына син абыеңның сыер, сарык рәсемнәре төшкән китапларын, дәфтәрләрен табып куярсың. Шартлар ике яктан да өзеп куелган һәм һичсүзсез үтәлгән булырга тиеш. *(Чыга башлый.)*

Тансык *(аның артыннан).* Син аны йолкып кына ал, абый. Шулай ансат ул. Әни белми дә кала ничек алганны.

Заһит китә. Малай үз шөгыле белән. Бераздан Камәрия кайта.

Камәрия. Нәрсә син монда өй туздырып утырасың? Юнышыр өчен ишек алды ярамыйммыни? *(Малайның чүп-чарларын ачуланып аягы белән этәрә.)*

Тансык. Тукта! Әллә сиңа уен эш белән утыраммы?

Камәрия. Алла, бер дә харап икән, эшемне кырып утыра.

Тансык. Сиңа эш тә эш. Ә менә өйне ташлап чыгып киткән булсам? Үзе өй сакла диде... *(Чүп-чарларын теләр-теләмәс кенә җыештыргалый башлый.)*

Камәрия *(кырыс).* Өй саклау өстенә тагы бер эш кушкан ием мин сиңа: эшләдеңме мин кушып киткән эшне?

Тансык *(сүзнең уенга бармаганлыгын сизенеп, ишеккә таба чигенә-чигенә).* Заһит абый әрчи бәрәңгене. Шулай сөйләштек. *(Чыга.)*

Камәрия. Нишләтергә дә белмәссең бу малайны, зарыгып, көтеп алганыбыз үз башыбызга бәла булып төшмәсә ярый. *(Өйне җыйгалый,*

*әйберләрне үз урыннарына урнаштыра.)* Әтисе артык иркәләп җибәрде шул. Янәсе, бердәнбере...

Бер кулындагы чиләккә әрчеп юылган бәрәңгесен салып, икенчесенә чишмә суы алып

Заһит керә.

Заһит. Гафу итегез, туганым-җиңги, сез кайтканчы өлгертеп булмады. Югыйсә, пешереп тә куярга иде исәп.

Камәрия *(кырыс күренергә тырышып)*. Ай, харап иттең, хур иттең башымны, менә хәзер кайненесеннән бәрәңге әрчетә, су китертә дип бөтен авылга сөйләп йөрерләр инде.

Заһит. Сөйләмәсләр. Бу турыда безнең Тансык белән ике арада договор бар. Кеше кушуы белән түгел, үзара килешеп, ризалык белән эшләнгән эш.

Камәрия *(җитди)*. Әтисе узындыруы да җиткән, ул малайны инде син дә аздырма, Заһит. Кушылган эшне үзе эшләп өйрәнсен. *(Чүмеч алып килеп.)* Кая, ичмасам апкайткан суыңны авыз итеп карыйм бер. Бик яндырды бүген. *(Чиләктән чүмеч белән салкын су эчә.)*

Заһит. Чишмәне буралап, өстен каплап зерә дә яхшы эшләгәннәр, кайсы изге бәндәнең башына килде бу акыл?

Камәрия. Кешеләр бар хәзер колхозда, эш кенә төтсен.

Заһит. «Сиңа гына эш калмады» дип әйтүең түгелдер ич бу, туганым-җиңги?

Камәрия. Сиңа да эш табарбыз, курыкма.

Заһит. Курыкмыйм, нишләп куркырга. Бәрәңге алып, бәрәңге пешерү дә эш. Ләкин, туганым-җиңги, онытмагансыздыр дип уйлыйм: урта белемле ветфельдшер кисәге бит мин.

Камәрия. Беләм: күн букча асып, сарыклар бәрәнләтеп, сыерлар бозаулатып йөргәнең бүгенгедәй күз алдымда. Әмма озак эшли алмадың, сугыш башлануга, туйга чапкандай, шул якка чаптың.

Заһит. Туйлар булды, әйтеп тә бетерерлек түгел. *(Пауза.)* Туйдан соңгы гомердә шулай ук тик ятмадык: тимер юл салдык, таш чыгардык, сал агыздык. Ә менә терлек-туар тирәсендә специальностем буенча эшләргә туры килмәде.

Камәрия. Терлек-туар тирәсендә дә эш табылыр, күн букчаң да исән, көймә юкка. Түлке абыең әнә авыз да ачтырмый: «Ул безнең кунагыбыз, юкка кытакламасын, барасы җиренә барсын, күрәсе кешеләрен күрсен, ял итсен», ди. *(Заһит өстендәге иске гимнастерка-чалбарга күзе төшеп.)* Күрми дә торам, нишләп әле син адәм рәтле костюм-чалбарны салып, бу искеләреңә төрендең?

Заһит. Кайтканнан бирле кеше костюмында үрә катып йөрү дә туйдырды. Бу, ичмасам, иске булса да үз искем.

Камәрия. Ят кешеме сиңа абыең, үзе әйтеп тора. Юлы уңмаган көйсез кияү булып кыланасың, ачуым килмәгәе... Әйттем исә кайттым, әйтеп кенә бактым: йөри бир алайса сәләмәңә төренеп. Берәр тол хатын, җәлләп, иреннән калган иске киемне чыгарып бирмәсме?

Заһит *(җәберсенеп)*. Җиңги! Бу синме шулай каты телле?

Камәрия. Булырсың сезнең белән. Бер ата балалары, берсе икенчесенең киеменә сыймый. Яратмыйм ирләрнең шулай сырланып-кырланып торганын. Бармы кияргә? Ки. Киләме эшлисең? Йолкып ал эшне. Үз колхозыбыз лабаса.

Закир керә.

Закир *(кәрә-керешкә)*. Бу нинди тавыш өйдә? Колхоз председателенең рөхсәтеннән башка, кем ул минем колхоздан йолкып алмакчы?

Заһит. Әнә туганым-җиңги шундый усаллыкка өйрәтә... *(Камәриягә.)* Ә бер караганда, син хаклы, җиңги. Күрәсең, дөнья өйрәтеп җиткермәгән булган мине.

Камәрия *(Заһитның бу сөйләнүенә әллә ни игътибар итмәстән, Закирга).* Нишләттегез Нурислам абзыйны?

Закир. Нишләтик? Өенә алып кайтып салдык. Духтор чакырттык.

Камәрия. Тәки азаплыйбыз шул сырхау картны. Әле нинди эштә, елы нинди тагы....

Закир. Остармыйча гына. Синнән башка да беләләр. *(Өстендәге гимнастеркасын салып, Камәриягә ата.)* Син, лутчы, тегеп бир... Шул карт белән мәйханә килеп, кайда, ничек эләктергәнемне сизмичә калганмын.

Камәрия *(юып үтүкләгән икенче гимнастерка китереп).* Соң алайса, менә бусын ки.

Закир. Бәйрәм ие яңалык күрсәтеп йөрергә. Кеше монда минутка дип керә, ә ул бәхәс ачмакчы. *(Сүзне кырт кына икенчегә борып.)* Ул нинди сүс өйалдында? Колхоз председателеннән яшереп кенә берәр җирдә сүс өләшеп ятмый торганнардыр бит?

Заһит. Ә аны, завхоз Фәхри абзый белән сөйләшеп, мин апкайттым. Ферма тирәсендә караштыргалап йөргәндә, күзгә ташланганы шул булды: бау, сбруй ише әйберләрегез бик беткән. Печән күтәреп ташырлык бауга да аптырыйлар кызларыгыз. Тик ятканчы, иртәгесе көннән бау ишә башларга исәп.

Закир. Колхоз чутыннан бау иштереп, эшкә чыкмый ята торган хатынын кырга мунчаклап апчыкмакчы буламы әллә, Фәхрине әйтәм? *(Заһитка кадап әйтергә тырышып.)* Тормыштан артта калгансың, енекәш. Бау белән бәйләп ташу заманнары узды, тиздән без терлекләргә азыкны асылмалы юллар белән, двигатель ярдәмендә китерә башлаячакбыз.

Камәрия. Булачак шул асылмалы юлларны көтеп, атларыбыз тик тора, терлекләргә салам-печән ише азыкны кызларыбыз кочаклап ташый, дип тә өстә.

Закир. Нәрсәдер гел миңа аркылы килеп торасың әле син бүген, хатын? Берәр азган шөпшә тешләмәгәндер бит? *(Заһитка.)* «Ферма тирәсендә» дигәннән әйтүем, хәтереңә авыр алма, Заһит: рәхәтләнеп ял итмичә, ни калган сиңа каралты-кура арасында буталып йөрергә?

Заһит *(аптырабрак).* Колхоз эшен сагынып кайткан кешенең кызыксынып йөрүе, белмим, нишләп алай «буталып йөрү» була торгандыр.

Камәрия. Карама шуның сүзенә, уйлап сөйләшәмени ул безнеке.

Закир. Сезнеке уйламаса уйламый торгандыр, ә «безнеке» бик уйлый, Хатынбану: болай да унбиш-уналты ел илдән аерылып, хаксызга репрессияләнеп йөргән бердәнбер энемне мин инде кайткан көннең иртәгесен үк борыны белән ферма тирәсенә илтеп тыга алмыйм, бигайбә.

Камәрия. Әгәр кеше үзе эшкә ыргылып торса?

Закир. Белмисең икән, тик тор. Заһитта, я булмаса синең белән миндә генә түгел хикмәт. Я тексәң тек тизрәк, синең белән спорлашып утырырга дип кайтмаган. Культ заманасында хаксызга җәберләнгән кешеке, тиешенчә ял иттермичә, эшкә кушсаңмы? Иртәгесен үк райкомга чакырып, өстәл каршына бастырачаклар: «Син, иптәш Таһиров, яңадан культ заманнары әйләнеп кайтуын телисеңме? Кайда синең кеше турында кайгыртуың?»

Заһит. Син, абый, «партия», «райком» сүзләрен бу урында бутама, яме. Партиянең кеше турында кайгыртуы аркасында мин менә монда исән-сау басып торам. *(Пауза.)* Ачыктан-ачык сөйләшик: синеңчә, мин бәлки колхозга кирәкле дә түгелмендер? «Кит! Башка җирдә урын тап!» дип әйтеп кенә бетермисеңдер?

Камәрия. Колхоз эшенә кеше җитмәгәндә, шулай дип әйтмәгән

кайда. Син дә шул «кайттым — бар, киттем — юк!» икәнсең, Заһит. Чистый бер шабашник, ачуым килмәгәе.

Закир *(сүзне уен-көлкегә борырга тырышып).* Менә хәзер, агай-эне, икебезгә дә тигез эләгә инде. Чәй эчкәндә болай да сөтне кашык очы белән генә сала иде, моннан соң бөтенләй салмый башлар.

Камәрия *(җенләнеп, кече яктан чүлмәге белән сөт алып килеп, Закирның алдына лыркылдатып китереп утырта).* Мә, туймасаң, чүлмәге белән күтәреп эч. Әмма да синең урыныңда мин булсаммы?

Закир. Ни кырыр иең икән син булсаң?

Камәрия. Кырмасием, әмма шаккатып та тормасием. Әүвәлән килеп, эшсезлектән сөрси башлаган менә бу егетне, юкны-барны уйларга вакыт калдырмаслык итеп, фермага кадаклап куярием. Бүтән вакытта «фермага куяр кешем юк» дип зарланып бушамыйсың, гел шул бетешкән Нурислам картны йөгертәсез. Инде килеп, бүген тәмам аяктан егарга да өлгердек.

Закир. Акыллы киңәшең өчен рәхмәт, хатын. Ләкин шуны белеп тор: ферма — синең белән минем эти-әниләребездән калган частный мөлкәтебез түгел.

Заһит. Ә син үз чиратыңда шуны белеп тор, абый: мин монда эти-әниләрдән калган малны бүлешергә дип кайтмадым, эшләргә дип кайттым. Ә эштән безне бервакытта да, хәтта лагерьларда да аермадылар. Дөресен әйтеп карыйммы, абый?

Закир. Бүтәннәр дөресен әйтмиләр дип уйлыйсың икән, әйдә алайса, синең дөреслекне тыңлап карыйк.

Заһит. Ошамый миңа синең болай тегермән корып азаплануың. Үземнең туган йортымда, туган абыем белән күз кысышлый уйныйсым килми: әйе, эшлисем килеп кайттым мин! Беләсеңме шуны, төшемә керә торган иде. Малай чактагысы, күргәне, күрергә теләгәнем — барысы да бергә буталып, төшемә керә иде: әйтерсең, без Ярмәк болынындагы җәйләүдә, көтүче Зөлкарнәй абый белән икәү, терлекләрне барлыйбыз. Ә алар, имеш, исәпсез-хисапсыз... тауларга, тау кабыргаларына, шул тирәдәге болыннарга безнең нәселле сыерларыбыз таралган...

Закир *(бүлдереп).* Сугыштан кайтмады Зөлкарнәй бичара. *(Пауза.)* Частеннан командиры хәбәр итте. Геройларча башын салган. И кәнителе шулчаклы гына.

Заһит. Ә менә мин, кайтып, сезгә канитель ясадым: кая куябыз хәзер бу тынгысыз кешене? Кайткан, эш сорый. Әле җитмәсә, специальносте буенча эшләргә тели. Ярый ла, ул без уйлаганча булып чыкса? Әгәр алай булмыйча, соңыннан безгә җавап бирергә туры килсә?

Закир. Нигә? Алай уйлаучы булса, гаеп итәрсең мәллә? Әмма хәзергесе минутта минем уйлаганым ул түгел, хәзергесе минутта минем уйлаганым: иң элек берни турында да баш ватмыйча ял итәргә! И все, и баста! *(Кузгала, китәргә җыена башлый.)* Бик алай өйдә утырып арысаң, әйдә, айгырны җигеп, станциягә хәтле үзем илтеп куям, Казанга — Зариф абыйларыңа барып, аларны күреп кайт.

Заһит. Нигә? Барып кайтырга була. Айгырын җигеп бирергә әзер торучы дәү абый үзе әйткәч, бигрәк тә.

Закир. Конечно, алдан әйтү читен... кунак-кунак уйнарлык җае туры килерме-юкмы? Диссертация дигәннәре белән башы каткан соңгы вакытларда.

Заһит. Ә синең эшең юк, йөри бир җил куып. Шулай дигән кебегрәк килеп чыга бит, абый.

Камәрия. И... аның бар сүзенә дә колак сала китсәң! Сүзне уйлап сөйлиме соң ул безнең Закир. Өйрәнгән соң собраниедә өстәл төеп кычкырырга.

Закир. Кәнфитлана белмим, дөрес әйтәсең. Күңелемдә ни бар, ярам да салам. *(Заһитка якын ук килеп, бик җитди рәвештә.)* Дөресен әйт-



кәндә, Заһит дус, пока муенында камыт юк, чабып, як-ягыңа карап кал. Кешеләр әнә кайталар да нифте ягына чабалар. Белми чабалар дисеңме?

Заһит. Шулай чаба торгач, берәр җирдә кыеклап кул куеп утыра торган җиңел гено эш тә чыгып куйса?

Закир. Ник исең китте? Әллә бүтәннәрдә булган кул синдә юкмы? Үз вакытында укыйсын укыган, ике телне дә беләсең...

Заһит. Өченче телне дә өйрәндем мин анда, абый.

Закир *(төшенеп җитмәстән)*. Алай булса, бигрәк тә шәп. Сәлам дә биреп торасы түгел, барасы да керәсе берәр нифте управляющиеның кабинетына. Синең ише культ заманасында җәбер күргән кеше белән хәзер аягүрә басып сөйләшергә тиешләр.

Заһит. Әгәр аягүрә басмаса? Әгәр, менә синең кебек, андагы дәү абый да җайлап-җайлап кына үзеннән читкәрәк этәрергә тырышса?

Закир. Кара әле, кем... мин сине аңлап җитмим, егеткәем. Кем сине читкәрәк этәрергә тырыша? Канса-канис, бөтен кешегә дә колхозда чиләнергә дигән сүз түгелдер бит?

Камәрия. Сөйли белмисең икән, үстермә сүзне. Бар барасы җиреңә.

Закир. Барыгыз да миңа бәйләнмәгез әле. Ә, может, минем барасы җирем бөтенләй юктыр. *(Кигән эшләпәсен, пиджагын салып ыргыта, яңадан өйнең кыл уртасына, табуреткага килеп утыра.)* Синең, туганкай, «өченче тел» дигәнең шушы икән. Ягъни, бүгенге көндә партияправительство заданиесен үтәп башы катып беткән бертуган абыеңның башын катыру икән.

Заһит. Юк, аңламагансың, абый. Нужа теле ул минем «өченче тел» дигәнем. Аны үз җилкәсендә «укып күрмәгән» кеше икенче берәүнең йөрәгеннән тиз генә аңламый. *(Кызганнан-кыза барып.)* Икенче кабат бу турыда сүз булмасын өчен, бер авыз ачылганда әйтеп калыйм, юк, «акчалы эш» эзләп беркая да китәчәк түгелмен, абый! Миңа шушы үз жирем кадерле! Шушы җир өчен мин, түшем белән шуышып, немец пленлыгыннан качтым. Исем-фамилиямне югалтып, лагерь надзирательләре өчен коры «88» генә булып калганда да, шушы җиргә, партиягә, халыкка булган ышанычымны югалтмыйча, «Тукта, гел болай бармас!», «Тукта, бер рәтләнер!» дигән өмет белән яшәп, инде менә кайтып егылдым дигәндә... *(Нык ярсып.)* Беләсем килә: бармы минем үз өемдә яшәргә хакым? Абый әйтмәсә, туганым-җиңги, син әйт, син сизгеррәк: бармы минем, кунакка бармыйча гына, кеше кебек, бүтәннәр кебек, менә сезнең кебек, үз колхозымда эшләргә хакым? *(Кинәт һәм*

*көчле дулкынланудан һушыннан яза, Камәрия белән Закир ярдәмгә ашыгалар.)*

Камәрия *(курка калып).* Карабрак тот, ичмасам... Сөйли белмичә сүз сөйләгәч соң.

Закир. Син белгәч, шул җиткән инде. Сөлге чылатып китер, юкка остарып торганчы...

Каударлы ыгы-зыгы. Нәкъ шул минутта ишектә Тансык күренә.

Тансык. Нишләттегез абыйны? Үлә бит абыем-җаным. *(Якын килергә куркып, тирәли чабып йөри.)* Бау ишәбез дигән булган ие үзе.

Закир *(ничек тә зурга җибәрмәскә тырышып).* Шыңшыма, синнән алырмын бар ачуымны.

Камәрия *(суга чылаткан тастымалны Заһитның маңгаена куеп).* Бирегез кешегә чак кына сулыш алырга. Сатулашырга соңыннан да өлгерерсез.

Өчесе өч якта, нишләргә белмәгәндәй, аптырашып басып калалар.

Заһит *(бераздан күзләрен ачып).* Нәрсә булды соң миңа? Син дә мондамыни, абый?

Закир. Кайчан башланды мондый галәмәт? Нәселебездә юкны...

Камәрия *(аңарга телен тик тотарга кушып, ишарә ясый).* Бернәрсә дә булмаган, исегез китмәсен. Һич югы, син ятып тор, Заһит. Өй тыныч кала, без барыбыз да китәбез.

Заһит *(әкрен генә кузгалып).* Мин сеннеккә чыгып ятам, сез миңа карамагыз, туганым-җиңги.

Камәрия. Тотыбрак чыгар, ичмасам. Калдың беравык шаккатып.

Закир. Калырсың. Кем күргән мондый тамашаны. Нәселдә булмаган хәл, ата-баба күрмәгән. *(Заһитның култыгыннан алмакчы.)*

Заһит. Кирәкми, үз аякларым да бар ич минем.

Чыгалар.

Тансык. Нишләгән соң ул? Исергән мәллә?

Камәрия *(малаена җавап бирүдән бигрәк, үзе белән үзе сөйләшеп).* Исергән. Йөргән җирендә дә сыйлаганнар, кайткач әнә этиең дә берөзлексез сыйлап тора.

Тансык. Мин аның янына чыгам. Яратам исерек кешенең өстенә карап торырга.

Чабып чыгып китә.

Камәрия *(малайның артыннан кычкырып).* Тынычлап ятсын абыең, йөрмә ул тирәдә. Булыр икән бу хәтле кырыкка бер тулмаган нәстә.

Закир әйләнеп керә. Сүзсез. Бер мәл, нәрсәгә тотынырга белмәгәндәй, аптырабрак кала.

Закир *(тәрәзә каршысына туктап, үз-үзенә).* Бер караганда, минем генә ике гомер яшисем бармы? Шушы бүтәннәр үк йөргән урамнан йөрим.

Камәрия. Нәрсә авыз эчеңдә ботка пешерәсең. Калдымы ятып?

Закир. ...Шушы урамнан ук башкалар киткән җиргә китәсе... Кирәк бит авырткан башка тукмак булып төшәргә. Акылыңны җен алыштырган нәрсә.

Камәрия. Чынлап та, җенләнеп кердеңме әллә син? Сораганга җавап бирмичә, берөзлексез авыз эчеңдә ботка пешерәсең?

Закир *(кинәт кабынып).* Җенләнерсең сезнең белән. Кайсыгызны ничек тыңларга белгән юк.

Камәрия *(җайларга тырышып, әкрен генә).* Белмим тагы, минем сүздә женеңне чыгарырлык нәрсә булгандыр? «Ятып калдымы?» дип сораганга шулхәтле кызмасаң...

Закир *(кыза барып).* Калды, калды... Ятар кирәк булса, колхоз эшенә барасы түгел.

Камәрия. Колхоз эшенә барасы булса, бәлки, ул алай борчылмас та иде, Закир.

Закир. Төрлегез төрле яктан килеп башымны катырмагыз, син беләсеңме, мин беләмме, наканис?

Камәрия. Ах алла, минем энем түгел, үз энең ләбаса. Ни өчен миңа, тамак ертып, шулхәтле кычкыра торгансыңдыр? Кеше кайткан, үз өенә, үз туганнары янына дип кайткан, күпме кирәк кешегә...

Закир *(кызып, хатынын бүлдереп).* Остарма белер-белмәс. Кайткан, кайткан! Беләсеңме соң син аның ничек кайтканлыгын?

Камәрия. Акланып кайткан. Әллә кая да түгел, үзенең туган авылына, туган йортына, сагынып, эшлисе килеп кайткан.

Закир. Акланып кайткан, утырасы срогын тутыргач... Ә бер заман, бу дөньялар икенче яктан икенче төрлегә үзгәреп, «Таһиров үз канаты астына төрле разный элементларны, төрмәдән кайткан кешеләрне жыя» дип бәйләнә башласалар? Яхшы эшеңне күрмәсәләр дә, тирәндә казынучылар табылыр.

Камәрия. Алайса, кире куып җибәр инде энеңне.

Закир. Нигә куарга, ятсын, ял итсен. Вакыты җиткәч, үзе дә китәр.

Камәрия *(иренең каршына ук килеп, бик җитди рәвештә).* Аңламыйм мин сине, Закир, ничек син кеше турында шулай, бер дә исең китмичә, тыныч кына сөйли аласың? Чит кеше булса икән әле, үзеңнең бертуган энең турында. Ишеттең ич нәрсә әйткәнен. Хәлен дә күреп торасың, арып-алҗып, калган гомерен шушында — үз җирендә уздырасы килеп кайткан.

Закир *(ул да бик җитди, ул да, хатынының күзенә карергә теләгәндәй, якын ук килеп, ләкин тавышын кыса төшеп).* Үзем кимәгән костюмымны кидереп йөртәм, «ял ит!» дип бергзлексез тукып торам. кирәк дисә, айгырымны җигеп бирергә әзер. Төрлегез төрле яктан тагы нишләтер идегез мине? *(Бик нык кызып, соңгы козырен алып бәргән картежниктай.)* Беләсең килсә, бел: колхозың пар сөрү буенча койрыкка калып бара. Как председатель колхоза, иң элек шуны сораячаклар миннән, төрмәдән кайткан энекәшеңне ничек җайладың дип түгел.

Камәрия, «ичмасам, тавышы сеннеккә ишетелмәсен» дигәндәй, ян тәрәзәне ябып килә.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бригадир Мәхмүт Корбанов өе. Түбәсе шифер белән ябылган, бөтен җиреннән пөхтәлек, ныклык күзгә бәрелеп тора. Өй буенда бакча, кечкенә генә беседка. Бернчә баш такта умарта күренә. Бакча ягында ачык веранда, аннан бакчага баскыч төшә. Кыскасы, хуҗаларның — үзенең дә, хатынының да — дөнья күргән, зәвыклы һәм, шуның янына, барлык белән яшәүче кешеләр икәнлеге сизелә. Бәлки бу — аларның балалары юклыктан да килә торгандыр, балага бирeләсе мәхәббәт һәм көч шушы кечкенә бакчаны, шушы йорт-җирне, шушы умарталарны карауга китәдер.

Вакыт кичкә авышып бара. Пәрдә ачылганда Мәхмүтнең битлек киеп бакчада — умарталары янында чуалганы күренә. Өйдән Гөләндәм чыга.

Гөләндәм. Эшең беттеме, Мәхмүт? Онытылып китмә, бүген правление утырышы диган идең.

М ә х м ү т *(кесә сәгатен чыгарып)*. Миндә бөтенесе учетта, карчык. Әмма шулай да барасы җирне искә төшереп торучы хатының булу да зыян итми.

Гөләндәм веранда өстәлен әзерли. Мәхмүт береадан коштабакка җылы кәрәзле бал кисеп алып килә.

Кортларны вакытсызрак борчыдык инде борчуын да, әйдә, кирәк чакта кешеләрне дә ярыйсы гына борчыйлар. Аның каравы, кунакларга соңыннан яңа бал белән чәй эчерү ни тора.

Г ө л ә н д ә м. Шул балың белән үк мактанмасаң, минем әллә ни әзерлегем юк. *(Паузадан соң.)* Ни атна, ни шимбә дигәндәй, кайдан исеңә төште кунак дәшү.

М ә х м ү т. Нинди кунак ул — Заһит. Әллә кайчангы фронтовик дус. Аның белән минем бер тәмәкене икегә бүлеп тарткан чаклар булды.

Г ө л ә н д ә м. Шулай да... керми кергән кешене чакырып алгач, кунак була торгандыр инде ул... Табынны шушында — верандага гына әзерләргә уйлыйм мин. Яшь-җилкенчәк түгел, авыз күтәреп, җырлашып утырмассыздыр бит?

М ә х м ү т. Ә авыз күтәрмичә генә җырласак? Алдан ук барысын да вәгъдә итү кыен, карчык. Ә табынны верандага әзерлим дию — аныңсы идея. Һич югы, Заһит алдында шушы бакчабыз белән мактанырга мөмкин булыр.

Г ө л ә н д ә м. Сөйләрсең инде юк-барны, кешенең ачуын китереп. Кәмәрия апа әйтә, Заһит болай да бик пошына, ди.

М ә х м ү т. Менә колхоз эшенә җиксәк, пошынырга вакыты калмас. *(Уйланып.)* Үзара гына әйткәндә, пошынырлык сәбәпләр юк түгел егеткә. Йөргән кызы да ашыгыбрак кияүгә чыгып ташлады.

Г ө л ә н д ә м *(җәберсенеп)*. Әгәр алай әллә кайчандагыларны кузгата башласаң, мин бөтенләй өйдән үк чыгып китәм.

М ә х м ү т. Бетте, бетте, карчык. Әйттем исә кайттым, тәүбә-әстәгыфирулла. Кил әле, кирәксезгә чәпчеп куйганың өчен, бер пәп итеп алыйм әле үзеңне.

Кочып, үбеп алмакчы була.

Г ө л ә н д ә м *(чапаланган булып)*. Котырмасана көн яктысында. Чынлап әйтәм, Мәхмүт, әгәр шулай килешә торган булса, мин утырмас идем табынга.

М ә х м ү т. Әйттең син дә, иске авыздан яңа сүз. *(Уйланып.)* Димәк, Гөләндәм ханым, сезнең күңел бик үк тыныч түгел булса кирәк.

Г ө л ә н д ә м. Әллә ниләр уйлап чыгара башлады кеше. *(Назлап, иркәләп.)* Кирәкми, Мәхмүт җаным, бер кешене дә чакырмыйк. Әйберем дә юк, күңелем дә тартмый.

М ә х м ү т. Бер сөйләшенеп хәл ителгән мәсьәләгә икенче әйләнеп кайтмыйк. Ә инде әллә нәрсә уйлап чыгару мәсьәләсенә килгәндә, ул эшкә син, миңа караганда, остарак булып чыктың бит әле, карчык... *(Бик җитди.)* Я, бетте, бу турыда сүз булмады дип уйлыйк. Мин үземнең Гөләндәмемне үземә караганда да яхшырак беләм. Ә инде син әйтә торган «әллә кайчангылар»га килсәк... *(Яңадан уен-көлкегә, шуклыкка борырга тырышып.)* Мин сине бит, җүләркәем, нәкъ әнә шул «әллә кайчанда» булып узган шуклыкларың өчен яраттым да. Яшь чагында бернинди дә шуклыгы булмады икән, димәк, җавабы кыска: бер егет тә карамаган, карар җире булмаган дигән сүз.

Г ө л ә н д ә м. Әй, сиңа сүз әйтсәң соң... Чебен очкалый башлады бу бал тирәсендә, алып куйыйм әле.

Бал савытын алып, өйгә кереп китә. Мәхмүт газета караштыргалый. Ишек алды ягыннан дусларча шаулап, З а к и р килгәне күренә.

З а к и р. Парторг кайда югалды дисәң, шушында — бакчасында булыр. Правление утырышына куеп, тетмәсен теттерәм әле бер. Вак милекчелек кортына бик ирек куя башлады.

М ә х м у т. Парторг эшен правление тикшерә алмый. Ни укытып, гади бер хакыйкатьне дә төшенмәгәнсең, Закир абый. Әйдә, утырып ял ит бераз. Чабасың-чабасың, итегең төткәнгә рәхмәт.

З а к и р. Итек минем атка утырып чаба. Ә шулай да парторгның яшел тышлы китап буенча гына үстерелә торган бакчасында урындык җылытып китү ярый. *(Утыра.)* Газетта ниләр бар?

М ә х м у т. Барысыннан да азлап-азлап. Бик сагынып торган булсаң, әнә, Иран шаһы Мөхәммәт Риза Пәһләви килә. Хатыны Сәрия Пәһләви белән парлап.

З а к и р. Кадалып кына китсен, аларга мунча ягасы булыр әле. Парлап килгән кунакларны мунча кертмичә җибәрү килешмәс. Тагын да кызыклырагы юкмы?

М ә х м у т. Эйзенхауэр абыеңа операция булган, безнең маршал, президент әфәнденең тизрәк терелүен теләп, телеграмма җибәргән. Тәмле булдымы бусы?

З а к и р. Шикәрсез чәй кебек, җелеккә йөгерде. Еракта йөрмә син, якын тирәдәрәк чуал: кайсы председательгә эләккән дигән сүзем?

М ә х м у т. Әллә син дә газета аша шундыйрак берәр сәлам җибәрүләрен көтәсеңме?

З а к и р. Яхшысы эләкмәсә дә, яманы ерак йөрмәс. Сизмәдеңмени, безне сүккән райком бюросында күзлекле бер нәмәрсәкәй бертуктаусыз язып утырды, әллә хәерлегә булыр дисеңме?

М ә х м у т. Әле анысы пешеп җитмәгән, ди. Аның ул хәбәре чыкканчы, без, бәлки, койрыкларны җыеп та өлгерербез. Бераз ныграк селкенсәк, әлбәттә. *(Сәгатенә карап.)* Безгә кузгала башласак та вакыт түгелме икән?

З а к и р. Ашыкма. Синең белән мин барып җитми торып, беркая да китә алмаслар. *(Уйланып.)* Син ничек карарсың, Мәхмүт Сабирович мин ферма мөдире мәсьәләсен бу утырышта ук кузгату иртәрәк булмагае дип уйлыйм. Сиңа сугылуым да шул турыда сөйләшү өчен.

М ә х м ү т. Син, хәйләкәр төлке, юкка гына йөрмәссең. Кайсы җенең киреләнә башлады тагы?

З а к и р. Җен белән пәригә сер биргән юк анысы. Әмма кара сакалга ияреп йөри торган кара акыл әйтә: ул мәсьәләне алай талкан урынына куырып, бераз ашыкмыйсызмы, ди.

М ә х м ү т. Кара сакалны тыңладык, инде алайса колхоз председателе Закир Таһировның үз дәлилләрен тыңлап карыйк.

З а к и р. «Дәлил» дип, минем алай дәлилләп-җәлилләп әйтердәй сүзем юк, шуңарга сиңа кердем дә: ферманың элекке мөдире Нурислам абзый түшәктә ятканда, ул я теге, я бу якка хәл ителмичә торып, тәк сказать, ферма мөдире мәсьәләсен кузгату, картны чыгырыннан чыгармасмы, дим? Ничек кенә әйтмә, озак еллар шул эштә кара тир түккән кеше.

М ә х м у т. Дәлил бу. Колакка керә торган сүз, икенче төрле әйткәндә. *(Шаярткандай.)* Син, карт чыпчык, уйламыйча әйтәсеңме соң сүзне. *(Җитди.)* Әмма моны бит, хөрмәтле Закир абый, эш файдасыннан чыгып, болай итеп җайларга да була: Нурислам абзыйны без урыныннан кузгатмыйбыз, ул яткан түшәгендә ята бирә, вакытында докторын китертеп, без аны терелтү чарасын күрәбез, ә шул арада, әйтик, Заһит аның урынында вакытлыча эшләп тора. Заһит белән мин бу турыда сөйләштем, ул бөтенесенә риза, аңарга эш кенә булсын. Синең рөхсәтеңнән башка, хәтта мин аны бүгенге правление утырышына да чакырдым.

З а к и р *(бераз кыза төшеп).* Менә бусына бераз ашыккансың, ип-

тәш парторг. Ул миңа, бүтәннәргә караганда, чак кына якынрак тора, вакыты житкәч үзем дә, шәт, әйтә алган булыр идем.

Мәхмүт *(бик җитди)*. Вакыты бик житкән, иптәш председатель. Бу турыда мин дә чак кына чамалыйм шикелле. Без аны кирәгеннән артык озак кунак итәргә җыенмыйбыз микән? Миңа шулайрак тоела башлады.

Закир. Бусы инде, агай-эне, минем үз эшем. Бу мәсьәләдә кемнен дә булса туганнар арасына кереп, «син аны кунак итмә!» дип әйтергә хакы юк.

Мәхмүт. Ике бармак арасына ит үсми, димәкче буласыңмы?

Закир. Бармагы вак мәсьәлә. *(Гаять җитди рәвештә.)* Син миңа менә шуны әйт: бу эш соң югарыгы оешмаларда, әйтик, райкомда сөйләшенгәнме?

Мәхмүт. Ә... менә нәрсә өркетә сине. Өйрәнгәнсең син бөтен нәрсәдә райком абый җилкәсе артына посып барырга. Һич булмаса, бер мәртәбә, агаем, үзеңчә тәвәккәлләп, үз башың белән җавап биреп кара.

Закир *(шуклыкка әйләндерергә тырышып)*. Алайса, үз башым белән җавап биреп әйтәм хәзергесе моментта, тыңла: мин бүгенге правлениедә ферма мөдире мәсьәләсен башук кузгатмыйм. Менә шул.

Мәхмүт. Ә аны халык, әйтик, колхозчылар кузгатса? Парторг буларак, менә мин кузгатсам? *(Җайларга тырышып, әкрен генә.)* Юкка шикләнәсең, Закир абый, ферма мөдире эшен ышанып тапшырсак, эшли алачак Заһит. Үзе белән сөйләшеп карадым, үзе дә шул терлек-туар ягын каера.

Закир. Ул нәрсә каермас. Кичә генә кайтып төшкән кешегә колхозда бөтенесе сабан туе. Ә каш ясыйбыз дип күз чыгарып куйсак? Ул чагында бит беребезнең дә башыбыздан сыйпамаячаклар. Ә җавапны барыннан да элек председатель Таһировтан сораячаклар. Менә мине нәрсә уйландыра.

Мәхмүт *(кискен рәвештә)*. Ә кеше язмышының һавада асылынып торуы бер дә уйландырмыймы? Рядовой колхозчылар бу мәсьәләдә синең белән миннән кыюрак уйлыйлар. Сугышка киткәнче фермада эшләгән, ветеринария училищесы бетергән. *(Кул селтәп.)* И нигә соң мин гел бер сүзне кабатлап торам, шуның өчен бит халык бар. Халыкка киңәш итеп карарбыз, үзебез генә хәл итә алмасак. Әмма син мәсьәләнең икенче ягын онытма, Закир абый: Заһитны күрше «Кызыл Байрак» совхозыннан нәкъ ул теләгән эшкә, специальносте буенча эшләргә чакырып торалар.

Закир. Ах алла, нишләмәк кирәк, китсә китә инде, ихтыяры. Көчләп тотып булмый кешене.

Мәхмүт. Тотып була, әгәр без үзебез аңарга карата кеше була белсәк. Шуны да истә тот: Заһит безнең үз колхозыбызга кирәкле кеше һәм аны җибәрсәк, безгә җүнле күз белән карамаячаклар, шуны белеп тор.

Закир. Анысы шулаен шулай да...

Мәхмүт. Шулай булгач, тагы нәрсә кирәк? Әйдә, калганын юлда сөйләшә барырбыз. Соңга калабыз.

Закир. Ашыкма. Сөйләшенәсе сүзнең монда, икәүдән-икәү генә чакта, сөйләшенеп беткән булуы яхшы. *(Кыза төшеп.)* Син әйтәсең: теге дә бу. Янәсе, ышаныч күрсәтү, җаваплы пост, сынарбыз. Ә син сынап өлгергәнче, ул сынып китсә? *(Тавышын кыса төшеп.)* Аннары, как парторг, син миңа шуны әйтеп бир: ничек кенә димә, утырып кайткан кеше бит ул Заһит. Мине мәсьәләнең бигрәк тә шул ягы уйландыра. Дөрес, соңыннан ул акланган, дүкәмитләре барысы да үзе белән.

Өстәл хәзерләү хәстәрлеге белән Гөләндәм чыкканы күренә. Закир шундук сүзне икенчегә борырга тырыша.

Быел алма бирә дисең алайса бу агачларны. Алма бәлеше ашап сездә кунак буласы көннәребез бар икән әле, насыйп булса...

Гөләндәм. Ни өчен пешмәгән алманы күтәп торырга, Закир абый. Мәхмүт бүген, правление утырышыннан соң, үзенең фронтовик дусты Заһитны алып кермәкче була. Кунак өй хуҗасыннан башка йөрмәс. Шунда бергә, Камәрия апаны да алып, керерсез инде.

Закир. Бик тә колакка ятышлы сүз бу. Әменә бу кеше *(Мәхмүткә ымлый)*, күпме вакыттан бирле башымны катырып, ул турыда хәтта теш арасыннан да чыгармый.

Мәхмүт. Кунак өндәү хозяйка эше, мин кунак чакырмыйм: Заһит дус белән бер сөйләшеп утырырга иде исәп. Энесе сыйган җиргә агасы да сыяр.

Гөләндәм өйгә кереп китә.

Закир. Алайса без хәзергесе минутта төгәл генә бер карашка килә алмадык булып чыга?

Мәхмүт. Димәк, шулай булып чыга, синеңчә. Сүз тирәнгә киткәнче, әйдә, безне анда көтәләрдер. *(Чыгышлый.)* Әшулай да, Закир абый, әйтү яхшы: Заһитны фермага беркетү мәсьәләсен бу утырышта кузгатмасак та, озакка сузмыйча, барыбер кузгатачакбыз. Моны белеп тор.

Закир. Миңа хәтта яхшырак та. Соңыннан сүзе була-нитә калса— парторг белән бергәләп җавап бирербез.

Китәләр.

Гөләндәм ялгыз, өй белән веранда арасында керә-чыга йөреп, табын әзерли башлый.

Гөләндәм *(үзалдына сөйләнеп)*. Каушарга сәбәп тә юк кебек бер караганда, ә никтер каушыйм... *(Игътибар итмәскә тырышып.)* И... әллә кайчандагыларны уйлый китсәң... Нишләгән соң мин ул хәтле? Моннан биш былтыр элек... әллә кайчан, биш кат тузан астында калганны... *(Тревога белән.)* Әменә биш кат тузан астында калмаган булса?..

Гадәтенчә, әллә кайдан ук шаулап Шома Әкълимә керә.

Әкълимә. Борыны ис сизеп йөри, димә, кергәч сизә башладым, таба исе чыгаргансың, Гөләндәм. *(Әзерләнгән табынны күреп.)* Ә... алай икән, сизәсе юк, бөтенесе күз алдында икән... Нәчәнник кешеләрдә, мәйтәм, урак өстендә кунак, кунак өстендә бурлат... Берәр кунак буласы ахры?

Гөләндәм. Кунак дип... әйтеп булмый, күрше-күлән.

Әкълимә. Тотлыкмыйча гына сөйлә, миңа ни... нәчәнник-мазар булмасак та, кунакка барырга аптырап торганым юк. Бүген менә ике җиргә чакырулы. Әле шуның өчен керүем, теге чакта, мәйтәм, Татарстан бәйрәмендә дип әйтимме, әллә Нурулла Хәдичәсенең кызыл туен үткәреп яткандамы икән, хәтердә ачык калмаган, клубка бик матур бер брошка кадап барган идең, Гөләндәм. Тәки күзем төшеп калган бит шул малыңа.

Гөләндәм. Белмим шул, алай күз төшәрлек нәрсә булды икән миндә...

Әкълимә. Курыкма, бүген кичкә генә... Бар ич теге зәңгәр кашлы брошкаң...

Гөләндәм *(өйдән брошка алып чыгып)*. Каядыр җыенасың булса кирәк... Үзеңдәгеләр генә ярамагач...

Әкълимә. Үземнекеләр туйдырып бетерде. Гадәтем шулай алама бит, малай, нишләтәсең: күлмәк алып, бер күлмәкне тузганчы кия алмыйм. Алка-йөзек алып, алка-йөзекне озак саклый алмыйм. Бер иргә чыгып, аның белән мантыганым юк...

Г ө л ә н д ә м. Юкны-барны сөйләнгән булып, тәки эзне югалтмакчы кеше дигәнең... Кая барырга җыйналасың соң болай?

Ә к ъ л и м ә *(сер бирмәскә тырышып)*. Һәй, кая бармас ирекле тол хатын! Аннары бит, Гөләндәм җаным, теге ягы булган эшнең бу ягы да бар. Күршеләребездә генә өйләнмәгән карт егетләр ишәеп тора, шуларның берәрсен аздырып булмасмы, дим.

Г ө л ә н д ә м. Син беләсең инде... кирәген-кирәкмәгәнен.

Ә к ъ л и м ә. Син дә белер иең дә, койрыгың бозга каткан. *(Мактанып, җилбәзәкләнеп.)* Булдыра алмас дисеңме Әкълимәне? Чынлап тотынсаммы? Китер ата шайтанынның үзен. Иртәгесен йокыдан торганда ефәктәй сузыла торган тәүфыйклы иргә әйләндермәсәм, баскан урынымнан купмыйм. Шушы фирүзә кашлы брошканы теге фельдшер хатыны тегеп биргән зәңгәр күлмәгемнең күкрәгенә кадап, мин сиңайтим, иңбашларымны сикерткәләп, чама белән генә көлемсерәгәндәй итеп... Түлке ни... бөтенесе дә чама белән кирәк, малай. Ир булган егет чамасыз кыланганны сыразы сизеп ала. «Егет» дигәннән искә төште әле, малай, бу сезнең күрше Мотыйк Заһиты сезгә кереп-чыгып йөри торган кеше түгелме?

Г ө л ә н д ә м *(сагая калып)*. Бусы ни дигән сүзең булды тагы? Нишләп безгә кереп-чыгып йөрсен, ди, ул.

Ә к ъ л и м ә. Мәхмүт абыйның фронтовик дусы ла ул, керсә дә гаҗәп түгел.

Г ө л ә н д ә м. Беткән ие Мәхмүт абыеңның бүтән эшләре, әллә кайчандагыларны искә төшереп тормаса... *(Шундук төзәтергә ашыгып.)* Чакырсаң ник кермәсен, керер. Бүген менә правление утырышыннан соң алып кайтам дип китте.

Ә к ъ л и м ә *(тантана белән)*. Менә бит ул, кыек атып, туры тидерү кайда. Кем морҗасыннан нинди төтен чыкканны сразы сизәм мин. *(Житдиләнеп һәм ялвару белән.)* Гөләндәм апа, җаным, мин дә синең сүзеңне тыңлар ием бер, очраштыр мине шул Заһит белән. Еландай телемне чыгарып сорыйм.

Г ө л ә н д ә м. Әлеге теге фельдшер хатыны тегеп биргән зәңгәр күлмәгеңне киеп килер идең бугай... Очраштыр дип, мин үзем дә булмам әле, бәлки... Табынны әзерләрмен дә этиләргә төшеп китәрмен. Мәхмүткә дә шулай дип калдым.

Ә к ъ л и м ә. Синең булуың-булмавың миңа кирәк түгел, булсаң — үз эшең, булмасаң — үз эшең. Һич уен-көлкесез әйтәм, Гөләндәм апа, алар сездә утырганда керимче... Кашык-аякларыңны гына булса да юышыр идем.

Г ө л ә н д ә м. Ах алла, кермә дип кем әйтер икән күршесенә.

Ә к ъ л и м ә. Простой күрше генә дә түгел, колхоз үзешчәннәренең танылган члены. Бәлки, миңа аны күрергә кирәктер? Бәлки, миңа аны күреп сөйләшү, булдыра алсам, аны үзебезнең түгәрәккә тарту эше югарыдан кушылгандыр?

Г ө л ә н д ә м. Кушылгач, эшлисең инде... Тик менә алдан шуны белергә кирәк: җырлыйсы килеп кайтты микән соң кешенең?

Ә к ъ л и м ә. Әйе, әйе... Нәкъ менә шуны белү өчен күрергә телим дә. Димәк, сөйләштек, сүзебез бер булсын: бүген мине Мотыйк Заһиты белән очраштырасың.

Бөтенесен дә үз файдасына хәл иткән кешедәй, ак-кара күрмичә, атылып чыгып китә.

Г ө л ә н д ә м *(аның артыннан, тынгысыз уйларга күмелеп)*. ...Ә менә анысы инде миннән булмас, Әкълимә... Күрәләтә кешене юлдан яздырырга йөрүче белән сүзем бер булмас, юкны сөйләмә! *(Нәрсәгә тотынырга белмичә, аптырабрак.)* Тукта әле, нишләп болай мин буталырга тиеш, ди, алар арасында? Нәрсә калган миңа? Минем аларда ни эшем бар? Кайнаша бирсеннәр үзара...

Касыйм керә. Өсте-башы майга, автолга каткан.

Касыйм *(коры гына)*. Кунак уздырырга җыйнала кешеләр, ә безгә ни гу-гу...

Гөләндәм. Правление утырышыннан кайтышлый җизнәң күрше Заһитны алып керәм дип китте.

Касыйм. Заһит абыйда минем дә бер йомыш бар иде инде барлыкка да... нишләрсең, чакырылмаган җиргә кысылып булмый.

Гөләндәм. Йомышың булса, әйбәтләп кенә әйт әнигә: чыгарсын каклаган казын, ә син йөгереп кенә кибеткә барып кил, чакыр Заһит абыеңны өйгә. Аның янына, бәлкем, Мәхмүт җизнәң белән Гөләндәм апаң да сыяр.

Касыйм. Акылың алтын икән, башың сөяк кенә булса да. Сезнең табынга без сыймаганбыз бит әле.

Гөләндәм. Ах алла. Бер дә җавап тапмассың безнең бу тел бистәсенә. Алай иренең бик кипшергән икән, нәрсә ялманып торасың, сал да эч үзеңә кирәкне.

Касыйм. Юк, иренем кипмәде, апа җаным, рәхмәт яхшы сүзеңә. Җизни белән Заһит абыйның ике ара серләрен бүлдереп, чакырсаң да утырмаган булыр идем. *(Сүзләренә мәгънә салырга тырышып.)* Нинди сүз булмас заманасында икесе бер кызны яраткан егетләр арасында.

Гөләндәм *(апаларча шелтә белдереп)*. Күпне белә башладың син, такылдык. Йомышың булса, йомышыңны әйт тә, әйдә бар, атыңны куала.

Касыйм. Гафу итә күр, апа җаным, кунакка чакырылмаган ачудан чыга барысы да. Йомышым шул: теге көн тышлы, немецтан кайткан чемоданыгызны биреп тор әле.

Гөләндәм. Нәрсәгә чемодан? Эш өстендә курортка җыенмый торгансыңдыр бит?

Касыйм. Курорт нәрсә ул? Аннан шәбрәгенә. Механизаторлар курсына китәргә җыенам бит мин. Түлке менә үземнең дуриндулетка утыртып калдырырга алмаш кирәк, диләр. Заһит абыйны да шуның өчен күрмәкче идем. Безнең эш белән таныш кеше бит ул.

Гөләндәм *(чемодан чыгарып)*. Белмим, бәлки таныштыр. Ә минем үземнең танышлык... Җибәрәләр икән, укы да кайт. Апаң белән җизнәңнән хәер-дога.

Касыйм. Догасы-дугасы кадалып китсен. Түлке син, апа җаным, бер җай туры китереп, җизнинең дә колагына сал әле: парторг кеше, күндерә алмасмы шул Мотыйк Заһитын минем дуриндулетка утыртырга. *(Чыга.)*

Гөләндәм *(аптырабрак)*. Бертуган энем... Аның да тел төбендә әллә ниләр бар. Барысы да шул Мотыйк Заһиты кайтканнан соң. Кайтмаса — кайтмасын, кайтса — вакытында кайтсын икән кеше. *(Өстәлгә каплана, өстәлдәге рюмкаларның берсе идәнгә төшеп челпәрәмә килә.)*

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Моннан элекке үк күренеш. Пәрдә ачылуга, Әкълимә йөгереп керә. Ул, гадәттәгечә, шау-шулы, хәтта бу юлы артыграк та шау-шулы түгелме икән?

Әкълимә. Гөләндәм апа, җаным! Баягысы барышлый булса, бусы кайтышлый. Сөенеч алырга керүем бусы.

Гөләндәм. Нәрсә өчен ул хәтле сөенеч?

Әкълимә. Теге «Ике җиргә чакырулы» дигәнемнең икесе дә пус-

тяк булып чыкты. Бер куркагы, мин киләсе булгач, өннән үк чыгып качкан. Икенчесе белән талаштык.

Гөләндәм. Шуннан миңа нинди «сөенеч» ди инде?

Әкълимә. Заһит абый сездә чакта мин дә сездә булам диган сүз. *(Житди.)* Чынлап менә, Гөләндәм апа, бик тә буласы килә Заһит абый янында.

Гөләндәм *(кырыс)*. Иң элек шунысына аптырыйм: нишләп әле мин сиңа «апа» булдым? Бергә уйнап үскән бер тирә кызлары ич без.

Әкълимә. Һич югы шуның өчен: синең ирең бар, ә минем ирем юк. Шушы, миңа караганда, бәхетлерәк булып яралуың өчен генә дә апа син миңа. «Мотыйк Заһиты ни өчен абый?» дип тә ник сорамыйсың?

Гөләндәм *(коры гына)*. Сорамыйм. Аның синнән чак кына олырак икәнлеген беләм.

Әкълимә. Яшьтә түгел хикмәт. Белеп булмый, бәлки ул тиздән минем нәчәннигем булыр. «Фермага куялар» дигән хәбәр йөри кеше теләндә. *(Яклана төшеп.)* Заһит абыйны безнең фермага куйсалар, әммә дә эшләр ходка китә инде безнең! *(Яшерен серен чишкән кешедәй, хәйләкәр рәвештә күз кысып.)* Алдан күрәзәлек итәсең дисеңме? Миңа, Гөләндәм җаным, шунсыз һич кенә дә ярамый. Ник дисәң, бүгенгесе көндә миңа, синең парторгың кебек үк дәү түрә булмаса да, шулай да нәчәнникләр тирәсеннәнрәк бер ир җүнәтергә кирәк. Ә Заһит абыйга килсәк, ул, карт булса да, өйләнмәгән егет.

Гөләндәм *(ачуын эчкә йотып)*. Нәрсә дип әйтергә дә белмим сиңа, Әкълимә. Бу чаклы уйсыз кеше булырсың икән.

Әкълимә. Синең Мәхмүтең уйласын, ул парторг. *(Чыга башлагач, кире кереп.)* Үпкәләттем моны, дип тынычланып калма. Кич, Заһит абый сездә чакта әбәзәтелни керәчәкмен. Кашык-аяк юарга булса да керәчәкмен.

Гөләндәмнең җавап бирүен дә көтмичә, ашыгып чыгып китә.

Гөләндәм *(ялгыз)*. Булса да булыр икән кеше. Бөтенләй аптырап калдым бер шай. *(Пауза.)* Бер уйлаганда, нигә миңа ул чаклы аптырарга икән?

Өйгә кереп китә. Бераздан, ишек алды ягыннан әйләнеп, Мәхмүт белән Заһит кайтканы күренә.

Мәхмүт *(юлда башланган әңгәмәне дәвам итеп булса кирәк)*. ...Син аны аңларга тиешсең, формаль яктан ул хаклы булып чыкты бу очракта. Нишләмәк кирәк, бөтен эшне югарыдагылар белән килештереп эш итә өйрәнгән! Хатыны белән мунча керүен дә алдан килештереп кайтмый микән дим әле мин аны. Дөресен әйткәндә, син тыныч бул, ул ягын без аның тиз тотачакбыз. Иртәгә үк райкомга үзем китәм. Әй, сиңайтәм, син кайда? Кунаклар кайтты, ә каршы алучы юк.

Заһит *(аның дулкынлануы тышка бәреп чыккан, сүзләре өзек-өзек, ничектер бәйләнешсез чыга)*. Син, Мәхмүт... нәрсә дип әйтим икән? Баеп беткәнсең, кыскасы... умарталар, алма бакчасы, «Сиңайтәм...»

Гөләндәм керә. Ул пөхтә генә киенеп алган. Заһитны, кайтканнан бирле, болай якыннан беренче күрүе булса кирәк, ничектер, сискәнеп киткәндәй итә, ләкин сиздерми, үзен бик тиз кулга ала.

Гөләндәм *(Мәхмүткә)*. Алдан хәбәр иттерермен дигәч, мин тәге... Кайтканына күпме Заһит абыйның, кереп тә карамый безгә. Исәнмесез? *(Кул очы белән генә күрешә.)*

Заһит. Вакыт тими, кардәш-ыру арасында кунакта йөреп бушаган юк. Тукта әле, тукта... шул без яшь чактагы Гөләндәмме соң бу?

Мәхмүт. Әллә «бик картайткансың!» дип дәгъва белдермәк буласыңмы?

Гөләндәм (*уңайсызланып, китәргә омтылып*). Бүтән рәтлерәк сүз тапмадың, ахры, Мәхмүт... Кеше алдында хатыныңны кызартудан тотынмасаң... Ичмасам, кунакка урын куяр идең. Утырыгыз, Заһит абый.

Заһит (*һаман басып торган килеш*). Утырырга өлгерербез. Менә Мәхмүт күршенең байлыгына бер сокланыйм. (*Гел үз уйларында калып, үзе белән сөйләшкәндәй.*) Шулай да... Бер дә үзгәрмәгән дөнья... Хәтерлисезме, бер вакытны өчәүләшеп Чиләп күле буена җуа җыярга барган идек...

Мәхмүт. Ялан аягы белән кәлтә еланга басып, Гөләндәмнең шыр акырып елап җибәргәненме?.. Нишләп хәтерләмәскә?

Заһит. Аннары... аннары менә болай булып чыккан... (*Үзен кулга алып.*) Ә сезнең төп йортта кем соң хәзер?

Мәхмүт. Теге малай. Ул «теге малай» дигәннең дә хәзер өч малае бар. Ә син, дөнья үзгәрмәгән, дисең.

Заһит. Бая әйттем мин аны, хәзер әйтмим. Бая, димәк, шулай әйтерлек сәбәбе булгандыр.

Гөләндәм (*өйдән чыгып*). Нишләп соң Закир абый белән Камәрия апа юк? Әйткәнсеңдер ич аларга, Мәхмүт?

Мәхмүт. Әйттем, алар озакламый килеп җитәргә тиешләр. Камәрия апа өстен алыштырырга дип кенә кереп калды.

Гөләндәм. Нәрсәгә инде өс алыштырып торырга, чит-ят кеше булса икән... (*Заһитка күтәрелеп карамыйча гына.*) Ишеттем, сезнең турыда да сүз булган икән бүгенге правлениедә, Заһит абый. Бик әйбәт инде үз колхозыбызда калуыгыз.

Заһит. Сез шулай әйтәсез әйтүен дә, кайбер кешеләр алай уйламый булса кирәк.

Гөләндәм (*аптырабрак, Мәхмүткә текәлә*). Аңламадым, бу нәрсә дигән сүз булды, Мәхмүт?

Мәхмүт (*шаярту тоны белән*). Мин әйтмәдем бит, әнә Заһит әйтте. Заһитның үзеннән сора. (*Җитди.*) Бу — безнең борынгы ярканат Заһитыбыз бераз гына кылчыкка әйләнә башлаган дигән сүз. Кыскасы, шул: безнең бөтен эшне югары оешмалар җилкәсе артына посып эшләргә өйрәнгән председателебез Закир карт бу юлы да үзенең кыюсызлыгын райком исеме белән каплап калдырырга маташты. Ләкин мин уйлыйм, мондый маташтыруларның да бер чиге булырга тиештер. (*Гөләндәмгә борыла төшеп.*) Син ничек уйлыйсың, сиңайтәм, әгәр ферма мөдире итеп куйсак, эшли алачак бит безнең бу егетебез?

Гөләндәм (*уен-көлкегә борып*). Мине чакырмадыгыз бит правление утырышына. Чакырган булсагыз, анда әйткән булыр идем. (*Җитди.*) Әйдә, монда да җыелышка әйләндермә, болай да зарыктырып бетергәнсеңдер инде Заһит абыйны.

Нидер йомыш тапкан булып, өйгә кереп китә. Гомумән, Гөләндәм бу минутларда үзен сәер бер тартынкылыкта, әнәләрен калкыткан керпедәй тота.

Заһит. Күрәсең, Гөләндәм дә ачык кына әйтеп бетермәде, шунлыктан мин абыйның бераз икеле-микелерәк маташуын, бер карaганда, аңлыйм да кебек. Бик озак аерылып торылган, кайберәүләрнең ышанып җитмичәрәк каравы, күрәсең, табигыйдер.

Мәхмүт. Аерылып торса соң, акча белән сатып алган курортын түгел ич. И, гомумән, ташла син, Заһит, алай кылчыкланып торуны. Мәсьәләне хәл ителгән дип уйла. (*Өстәлгә якынрак килеп, рюмкаларга эчемлек коя.*) Кил әле якынрак, башларына төкер озак көттерүче назлы кунакларның. Узганы, бүгенгесе, киләчәге һәм, гомумән, син чуар

йөрәкнең үз җиребезгә исән-сау кайтып егылуы өчен берәрне күтәрик әле.

Заһит. Егылуы өчен түгел, киресенчә, аякка басуы өчен! Шулай да... Гөләндәм ханым кайда соң? Беренче тостны аның белән бергәләп тотарга иде ич.

Мәхмүт. Менә бит, бөтенесенә баш та житеп бетми. Әй, сиңайтәм, кайда син? Чык әле монда.

Гөләндәм (*ишектә*). Минем чак кына эшем бар иде.

Мәхмүт. Куеп тор эшеңне. Әнә Заһит, беренче тостны Гөләндәмнән башка эчмим, ди.

Гөләндәм, каршы килә алмыйча, өстәлгә якынлаша, рюмканы кулына ала, нәрсә әйтергә, нишләргә белмичә, уңайсызланып басып кала.

Заһит. Я... Гөләндәм! Нәрсә өчен эчик бу беренче тостны!

Гөләндәм. Нәрсә өчен дип... Белмим инде мин ни дип әйтергә дә... Әйт шунда, Мәхмүт, минем өчен нәрсә булса да.

Мәхмүт. Акылың алтын икән!.. Табын янында да ире җилкәсенә утырып чыкмакчы. Синнән сорадылар, син әйтергә тиеш.

Гөләндәм (*кинәт башын күтәрә төшеп, Заһитка тыелгысыз бер караш ташлап*). Әйдә, алайса сезнең исәнлеккә, Заһит абый.

Эчә һәм кинәт кабынып, авызын томалап, өйгә атылып кереп китә.

Заһит. Ялгыш иттек эчмәгән кешене кыстап.

Мәхмүт. Һәй, дус кеше, ялгышлар күп булды бу дөньяда. Кем белә, бәлки, Гөләндәмнең әтисе бүләк иткән әнә ул придан умарталарның минем бакчада утырулары да ялгыш эштер? Бәлки, алар синең бакчада утырырга тиешле булганнардыр?

Заһит. Аңламадым. Дөресрәге, аңлыйсым килми.

Мәхмүт. Мәктәптә безгә әдәбият теориясеннән Ишмаев абый шөлдер кебек яңгырый торган матур сүзләр өйрәткән иде, бөтенесе онытылып бетте шуларның. Тик берсе әле дә булса тел очында әйләнә. Метафора. Метафора. Нәрсә була әле ул метафора дигәннәре?

Заһит. Әйтергә теләгәнне чуарлап, чачаклап-чуклап әйтү түгелме?

Мәхмүт. Бик үк дөрес түгел түгеллеккә, әмма киртәсенә керде. Мин менә шуны әйтмәкче булам: давай, бүген кич метафорасыз гына сөйләшик әле. (*Рюмкаларга эчемлек коеп.*) Әйдә, бусы булган үпкә-сапкаларны эретеп, өскәрәк калкытып чыгару һәм, мөмкин булса, озакка сузмыйча бөтенләй бетерү өчен!

Заһит. Иң элек аңлап китик: нинди үпкә? Кемдә? Нәрсә өчен?

Мәхмүт. Миңа калса, нәрсә өчендер син минем яңакка сугарга тиешле кебек күренә миңа.

Заһит. Үзебез метафорасыз гына сөйләшергә булдык, ә үзебез...

Мәхмүт. Гафу ит, алайса, метафорасыз гына: син миңа Гөләндәм өчен ачуланмыйсыңмы?

Нәкъ шушы минутта Гөләндәм үзе күренә, Мәхмүт тиз генә икенчегә борып.

...Конечно, бер җаена төшкәнче, ансат булмас, моңа исәп тотма. Колхозлар хәзер теге чактагы колхозлар түгел.

Гөләндәм. Закир абыйлар ни көттерә инде? Җылы аш чыгармый торам, шулар кергәнче дип...

Заһит (*кинәт һәм кискен борып*). Ә нигә без Гөләндәмнең үзеннән сорамыйбыз ул турыда? Метафорасыз икән, метафорасыз. (*Гөләндәмнең каршына ук килеп.*) Сез әйтә алмыйсызмы, Гөләндәм, ни өчен мин Мәхмүтнең яңагына сугарга тиешмен икән?

Гөләндәм (*тәшвишләнә калып*). Аңламадым, Заһит абый.

М ә х м ү т. Аңламасаң, мин аңлатып бирәм: Заһитның дөньяда икәнлеген бөтенләй истән чыгарып, аның йөргән кызына өйләнгәнлегем өчен мин хәзер аның алдында нинди дә булса уңайсызлану хисе кичерергә тиешме, юкмы?

Г ө л ә н д ә м. Әллә кайчандагыларны казып чыгармасагыз, бүтән сүзегез беткәндер шул.

М ә х м ү т. Юк, җаваптан качма син, Гөләндәм, әйтеп бир өчебез бергә чакта: ни өчен без кешене бөтенләй истән чыгарып ташладык? Кайчан да булса кайтыр, дип уйлап та карамадык?

Г ө л ә н д ә м. Бер без генә булсак икән, барыбыз да шулай уйладык ул чагында. «Андыйларга кайту юк икән» дип чыгардылар бит.

З а һ и т *(кинәт айнып һәм сискәнеп киткәндәй)*. Бу юлы мин аңлап җитмәдем: кемнәр булды икән соң алар, сезнең «андыйлар» дигәнегез?

Г ө л ә н д ә м. Әнә Мәхмүт әйтсен инде ул чаклысын. Урыны түгел вакытта сүзне ул кузгатты.

М ә х м ү т. Урыны, Гөләндәм. Кайчан да булса бер кузгалачак сүзне нигә томалап, үзебездән үзебез яшереп азапланырга.

З а һ и т. Шулай да минем Гөләндәмнең үз авызыннан ишетәсем килгән иде: кемнәр булды «Андыйларга кайту юк» дип караган кешеләр?

Г ө л ә н д ә м *(сүзсез)*.

М ә х м ү т *(Гөләндәмгә ярдәмгә килергә ашыккандай)*. Яңакка сугуның менә шундый төрлеләре дә була...

З а һ и т. Гөләндәм әйтмәсә, алайса син әйт, Мәхмүт: кайчан да булса, нинди дә булса шаукымга бирелеп, син минем турыда «Заһит — немец шпионы» дип башыңа китердеңме? Башыңа китерә алдыңмы?

М ә х м ү т *(сүзсез)*.

З а һ и т. Янган танк эчендә бергәләп таранга барган иптәшең турында? Юк, син миңа күңелеңдә ни бар — шуны әйт: китерә алдыңмы?

М ә х м ү т *(эндәшми)*.

З а һ и т. Дөрес, госпитальдән соң безнең юлларыбыз аерылды. Без бер-беребезне белмәдек.

М ә х м ү т *(Заһитка җавап бирүдән бигрәк, үзе белән үзе сөйләшкәндәй)*. Юк, без бер-беребезне онытырга тиеш түгел идек. Түгел идек! Нәрсә әйтмәсләр безгә? Без шуларның барысына да сукыр рәвештә ышанырга тиеш булдык микәнни? Кайда иде соң безнең үз башыбыз?

З а һ и т. Синеке кайда булгандыр, ә менә Гөләндәм ханымның үз башы үзендә булган: кайтмастай егетне көтеп, саргаеп торганчы...

Г ө л ә н д ә м *(көчле өзгәләнү белән Заһитны бүлдереп)*. Заһит абый, дим!.. *(Мәхмүтнең күкрәгенә авып, үксеп.)* Ни әйттем, утырмыйм, дип... Бөтенесенә син гаепле, Мәхмүт.

М ә х м ү т. Юк, икебез дә гаепле... *(Гөләндәмнең башыннан сыйпый, иркәли.)* Һәм бер бу мәсьәләдә генә дә түгел. *(Баягы авыр уйларыннан әле һаман арынмаган килеш, тиктомалдан гына.)* Ә шулай да... без сине алай тиз онытырга тиеш түгел идек, Заһит дус.

З а һ и т *(паузадан соң.)* Һәй, дус кеше, кайтып, күзгә күренгәннән соң да сискәнеп калучылар юк түгел.

Г ө л ә н д ә м. Баткан кеше кинәт калкып килеп чыкса, сискәнмәсәң, бар.

М ә х м ү т *(ялгыз гына кереп килүче Камәрияне күреп.)* Менә, ичмасам, Камәрия апаны әйтсәң дә җирендә. Сәгатен бераз саташтыра саташтыруын да, но көнен саташтырмый. Ә *үзе* кайда?

К а м ә р и я. Тәрәге булгач, житкән. Баганасы булмаса да.

Г ө л ә н д ә м. Көттереп йөрисең, Камәрия апа. Әллә нәрсә бар кебек.

Камәрия. Мин әле көттереп килсәм дә килдем, ә менә Закир абыегыз бөтенләй, башы белән үк юкка чыкты. Папирос алам дип кенә чыгып киткән кеше...

Мәхмүт. Кайтыр... Эзли чыкмаганны белсә, шундук әйләнеп кайтыр. Ә безнең аны эзли чыгарга вакытыбыз юк. Өстәлдәге ризык суына. Әйдәгез, табынга якынрак узыгыз.

Гөләндәм. Әйдә, Камәрия апа, миңа иптәш булырсың, ичмасам. Югыйсә, ялгыз башым менә бу ике фронтовик арасында бөтенләй аптырап калган идем.

Камәрия. Каршы килеп булмый. Шул Заһит аркасында безнең дә менә кунак булып йөргән көн.

Заһит. Дөрес әйттең, туганым-җиңги, шул Заһит аркасында барысы да... Абыйның менә болай тәртәгә тибеп качып йөрүләре дә шул Заһит аркасында булса кирәк. Ни тырышып карадым кайтмаска. Бер башыма кайда да эш тапкан булыр идем. Туган авыл, агай-эне, дус-иш тартты...

Мәхмүт. Фактически, ул дус-ишләрнең кайберләре мине башук оныткannар, диген. Кайтып, күзгә күренгәч, сискәнеп калдылармы?

Гөләндәм *(кисәтеп)*. Мәхмүт! Бер телеңә хуҗа була белмәдең син дә.

Заһит. Шулай ачыктан-ачык әйтә белүче туры сүзле кешеләр күбрәк булсын иде. Әллә, Мәхмүт дус, шушы изге теләкнең тормышка ашуы өчен тагын берәрне күтәрикме?

Камәрия *(сүзне икенчегә борырга тырышкандай)*. Ул Ибени Локманына ни җитмәгән тагы? Бүгенге утырышта тәкерек чәчә-чәчә сөйләвен тыңлап тордым да эчтән генә уйлап куйдым: «Әллә, мәйтәм, Закир абыйсы урынына председатель булып каласы киләме бу яшь әтәчнең?»

Мәхмүт. Ә мин, Камәрия апа, синең бу сүзләреңне ишетеп, уйлап куйдым: терәк булгач терәк — бағананы бер дә аударасы килми Камәрия апаның.

Камәрия. Терәклегем күпмедер? Иллә-мәгәр иремне теләсә кайда, теләсә кем авызыннан сүктереп торасым килми. Алып ташласыннар председательлектән — сүзем юк, әмма чабып торган килеш черетмәсеннәр кешене.

Мәхмүт. Ә ул, әйтик, бүтәннәр кагылганчы ук, чери башлаган булса? Бүгенге утырышта Закир абый үзенең кем икәнлеген янә бер кат күрсәтте. *(Шаяру тонына күчеп.)* Менә бит әле, юктан гына үпкәләп, үзең белән кунакка да кермәгән.

Гөләндәм *(үз уйларына күмелеп, сүзсез калган җиреннән кинәт айнып киткәндәй, Заһитка)*. Кайтышлый Казанга тукталмадыгызмыни, Заһит абый? Анда бит сезнең зур урындагы абыегыз бар.

Заһит. Минем Казан тирәсендә генә буталып каласым килмәде, казанның астына, учакка кереп, ут булып янасым килде. *(Барысына берьюлы.)* Нәрсә сез гел минем белән авыз чайкый башладыгыз, җәмәгать? Әллә кайтып, кемгә булса да комачаулый башладыммы? Менә бит ул — озак еллар югалып торуның бәласе.

Гөләндәм. Син тагы гаепкә алма, Заһит абый. Мин аптыраганнан әйтәм.

Мәхмүт *(хатынының бу сүзләрен бик үк ошатып җиткермичә)*. Мин үзем аптыраганнан каты итеп чәй эчәргә яратам. Төче сүзләргә караганда файдасы күбрәк чәйнең.

Нәкъ шул минутта ишек алды ягыннан «лап-лоп» басып, нидер мыгырдана-мыгырдана, Закир килгәне күренә.

Закир *(ул инде кайдадыр шәп кенә «төшереп» өлгергән)*. Тукта! Кемнән башка бу кәеф-сафа? Закир Таһировтан башкамы? Барып

чыкмас бу хәзергесе көндә... *(Килеп, веранда кырыена сөялә, ләкин табынга якынлашмый. Шул рәвешчә, барысын да берәм-берәм күздән үткәрә.)* Хәзергесе минутта, минем хатын да монда утыра икән. Шулайга китте алайса хәзер. Ирне көтеп тору юк. *(Заһит каршына туктальп.)* Синең күк капусы төрле яклап ачылырга тора, энекәш. Нурислам картның аяк сузганын гына көтәбез. Ул аяк сузуга — сине ферма мөдире итеп куячакбыз. Парторг белән болай әшнә торсаң, бәлки әле аны да көтмәбез. Тульке ни... сөт, май, йон сорый башласалар, мин җавап бирәчәк түгелмен. Әнә парторг, әнә минем бик оста хатын...

Мәхмүт *(аны тынычландырырга тырышып)*. Кара әле, Закир абый... Яңартмыйк монда ул сүзләрне. Килгән икәнсең, утыр, кунак бул.

Закир. Ә мин утырмыйм, шабаш! Ни өчен утырмыйммы? Утырасым килмәгәнгә утырмыйм, менә ни өчен утырмыйм. Сез анда, җыйнаулашып тотынып, минем сүзләрне юкка чыгарырга тырыштыгызмы? Тырыштыгыз. Бүгенгесе көндә колхозчылар алдында кайда минем афтаритетлыгым калды? Мин әйткәндә сүзсез калып тыңлап тормагач... И шунлыктан утырмыйм табыныгызга.

Мәхмүт. Утырмаслык булгач килмәскә дә иде, эзләп алмадык ич.

Закир. Кайда инде ул эзләү, карт кадрларның поты бер тиен хәзер... Ә шулай да сугыш елларында, муеныма камыт суктыра-суктыра, мин үстерәп алып чыккан колхозга җыелалар... Мин дә андыйларны чакырып кайтармадым, югыйсә.

Камәрия *(ирен тыйнаклыкка чакырырга тырышып)*. Син ни сөйлисең, адәм көлкесе? Авызың сөйләгәнне колагың ишетәме синең? Эчтем дигәч тә...

Заһит. Ә син тыйма аны, туганым-җиңги, әйтәсе сүзен әйтеп бетерсен.

Закир. Ә сиңа әйтәсе сүзем шул, энекәш: кайттың да бөтен тынычлыгыбызны боздың.

Мәхмүт. Ул кайтмаса да, барыбер бозылачак иде синең тынычлык. Вакыты җиткән иде.

Закир. Барыгыз бер сүздә торып, бәлкем, экренләп мине читкә кагарга уйлыйсыздыр... Әлек теге ягың ярамый, аннары бу ягың, аннары килеп, бер ягың да ярамый, и әйтерсез бер дә бер көнне: син карт ишәкнең кирәге калмады хәзер, диярсез. Локман башлады ич бүген. Сезнең котырык белән ул. Әллә белми дип уйлыйсызмы?

Камәрия *(ачуланып)*. Әйе, мин котырттым Локманны. Болай киртә сикерә башласаң, иртәгә бөтен колхозны котыртачакмын: «Бетте, артык эшли алмый Закирыгыз, алып ташлагыз!» — диячәкмен.

Иңрәп, әмма яшен ничек тә күрсәтмәскә тырышып, Гөләндәмнең күкрәгенә каплана.

Гөләндәм. Куйчы, исерекнең сүзләренә карап соң... Барысы да утыралар тузга язмаганны сөйләшеп. *(Мәхмүткә.)* Алып чык үзен, айныгач керер. Ни әйттем, кирәк түгел, дип... Күңелем тартмаган иде аны.

Мәхмүт *(Закирның каршынарак килеп)*. Актык сүз шул: син безнең табында утырырлык кеше булып чыкмадың, картлач.

Закир. Минем утырганым да юк сезнең табынга и утырасым да юк.

Чыга башлагач, кире килеп, Мәхмүтнең каршысына туктый.

Әмма шуны белеп кал: Закир Таһиров белән болай сөйләшмиләр иде моңарчы. Әгәр дә инде кайбер кешеләргә минем урыным кирәк икән, райком җибәрсә, мин иртәгә үк китәм. Мәгәр райкомнан башка берәүнең дә миңа теше үтмәс. Моны белеп торыгыз.

З а һ и т *(Мәхмүткә).* Болай булгач, сез аны тынычсызламагыз, Мәхмүт. Бөтен тавышка мин сәбәпче булдым кебек килеп чыга.

З а к и р. Ә башкача кем? Без моңарчы Мәхмүт белән бер сыныкны икәү бүлеп каба торган кешеләр идек. Парторглыкка мин аны үзем күтәрдем.

М ә х м ү т. Нәкъ менә шулай булгач, нәкъ менә шушындый тар карашлы, кеше язмышы турында кайгырта белми торган кеше икәнлеген төшенгәннән соң, без аны тынычсызларга, аның киләчәктә дә колхоз председателе булып эшли алу-алмавы мәсьәләсе турында җитди уйланырга тиеш булырбыздыр.

З а к и р. Өркетмә, егет. Синнән берничә баскыч югарыдарак утыручы райком абыең бар.

М ә х м ү т. Нәкъ менә шушы мәсьәлә буенча мин үзем иртәгә үк райкомга китәчәкмен.

З а һ и т *(сүзгә кушылмыйча, бер читтәрәк торган Гөләндәмнең каршына килеп).* Әйтегез әле, Гөләндәм: гел шулай талашлымы сезнең монда? Әллә, чынлап та, мин кайтып сәбәпче булдыммы?

Бишесе биш якта, әйтер сүз тапмагандай, катып калалар. Авыр тынлык. Нәкъ шул уңайсыз минутта, урыны түгел вакытта, Ә к ъ л и м ә-шаркылдык килеп керә. Киенгән-ясанган, тәкәллефсез рәвештә алга уза.

Ә к ъ л и м ә. «Керәм» дип әйттем ич, Гөләндәм, тәки кердем. Әллә мине шулай аягүрә басып каршылавыгыз инде? *(Заһит каршысына килеп.)* Таныйсыңмы, Заһит абый? «Әкълимә» дигән бер чәтерчән кызыгыз бар иде ич. Менә шушы кеше инде ул!

Күрешергә кулын суза, Заһит, кул бирергә дә, бирмәскә дә белмәгәндәй, аптырабрак кала.

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге обстановка. Таһировлар өе. Иртә. Пәрдә ачылганда, З а һ и т н ы ң, әллә ни кабаланмыйча, җыенганы күренә.

К а м ә р и я *(кече яктан чыгып).* Ник болай бик иртә кузгалдың? Өлгерер идең әле бераз соңрак та. Барасы җирең юктыр бит?

З а һ и т. Ник алай бик кистереп әйтәсең, туганым-җиңги? Мин шулай беркая да бара алмаслык егет түгелдер ич әле?

К а м ә р и я *(кече якта, үз эшләре белән шөгыльләнгән җирдән).* Соң кайттың кичә. Йокларга иде, дигән сүзем.

З а һ и т. Абыйны күрәсе иде бит... Яхшы түгел аны күрмичә.

К а м ә р и я. Төн озын бурсып чыкты бүген, рәтле йокы күрмәде. Шул инде анькы, аз гына эчсә, буена сеңдермичә, ташып чыга да, соңыннан үзенә дә уңайсыз була бугай. Ә юк, җә юк, әнә бит, таң тишегеннән чыгып киткән.

Заһит җыенасын җыйнап бетте булса кирәк, юл капчыгы янында, идән уртасында, капчыкны иңенә алырга да, алмаска да белмәгәндәй, бер мизгел аптырабрак калды. Ниһаять, эндәшергә, әйтергә булды.

З а һ и т. Булмаса, мин әйтәсе сүзне абыйга син генә әйтерсең инде, туганым-җиңги... Минем үз җилкәм дә бар, аның җилкәсенә утырырга дип кайтмадым, коты очмасын.

К а м ә р и я *(тәшвишләнеп, кече яктан чыгып).* Ялгыш ишеттемме дип әйтим? *(Гаҗәпләнеп, аптыранып.)* Бу ни дигән сүзең тагы, ошамаганны?



З а һ и т. Ошаганы да, ошамаганы да үз арабызда гына калсын, җиңги, мин сездән китәргә булдым. *(Кулын сузып күрешергә килә.)*

К а м ә р и я. Күрешмим дә, күрмим дә... Янәсе, абыйсының исерек баштан әйткән сүзенә кылтайган. Әйтер иен инде сине дә...

З а һ и т. Күрешмичә дә мөмкин, «Кызыл Байрак» совхозы ерак җирдә түгел. Абый сагыныр дип уйламыйм, әмма үзем сагынганда кайткаламый булдыра алмамдыр.

К а м ә р и я. Бер дә харап, укасы коелган кешенең... Читтә-чатта йөреп өйрәнгән кеше шулай инде ул: бер генә урында утырып тынгы тапмый.

З а һ и т. Бала-чага кебек сөйләшмик, туганымҗиңги. Мин сине акыллы кешегә саныйм. Кайтканнан бирле ничегрәк йөргәнен күреп тордык лабаса. Без күреп җиткермәгәнне, салмыш баштан, кичә үзе әйтеп бирде.

К а м ә р и я. Кайбер нәрсәләрне колак яныннан уздырып җибәргәндә дә ярар иде. Яхшымы-яманмы, ул сиңа абый.

З а һ и т. Нәкъ менә абый булганга күрә дә аны артык тынычсызлыйсым килми... *(Пауза.)* Шуның янына тагы, совхозда миңа специальностем буенча эш тәкъдим итеп торалар. Берәүне дә тынычсызлыйсы түгел, үзләре тәкъдим итеп торалар.

К а м ә р и я. Нишләмәк кирәк, үзең беләсеңдер яраганын-ярамаганын. *(Пауза.)* Шулай да, самовар кайнап чыгып, абыең белән бер утырып чәй эчәрлек кенә түземлегең калгандыр ич? Мин хәзер аны апкайтам.

З а һ и т. Чәй эчү өчен түгел, әйтмичә калган сүз-

ләрне әйтү өчен көтсәм инде... Юкса аның, курыкты, качып китте, дип тә чыгаруы бар.

Камәрия китә. Заһит ялгыз.

Заһит *(үз-үзенә)*. Кеше аягы кузгалганчы чыгып китәрмен дигән идем, булмады. *(Тәрәзәгә күз салып.)* Әнә көтү дә куа башладылар. Карап торсаң, гел шул иске тәртип: иртән куалар, кич апкайталар... Бәрәңге — җирдә, борчу — әдәм башында үсә. Ә алып кара баштан шул борчуны, баш дигәнең эчен алган кабак булып калачак.

Ишектә Әкълимә күренә. Юл капчыгы янында басып торган Заһитны күреп, ул бераз аптырабрак кала.

Әкълимә. Кунакка йокларга да бирмәгәннәр болар... *(Белмәгәнгә сабышып.)* Әллә берәр яры җыйналасыз инде, Заһит абый?

Заһит. Күрәсең, җыйналам булса кирәк, ахры. Туганым-җиңгидәме сезнең йомыш? Ул өйдә юк шул.

Әкълимә. Ул өйдә булмаса да... шулай да керергә булдым әле мин. Көтү куышлый Камәрия ападан сезнең китәргә җыйналу хәбәрегезне ишетеп, кермәс җирдән керергә булдым... *(Гадәттәге шуклыгына борырга тырышып.)* Тәки безнең колхозны ошатмадыгыз алайса?

Заһит. Нәрсәне ошатканны, нәрсәне ошатмаганны сөйли башласаң, озакка китә бит, Әкълимә. Аннары тагы кемгә кирәге бар аның?

Әкълимә. Бер сүз әйтеп карыйммы, Заһит абый? Әгәр ачуланмасаң...

Заһит. Белмим, нинди сүздер бит алай кисәтеп әйтелә торган сүз? Һич югы, сез түргәрәк уза төшегез, Әкълимә. Бала-чага кебек, ишек төбендә таптанып торасыз.

Әкълимә. Мин шушыннан да ишеттерә алам, әгәр әйтсәм...

Заһит. Нәрсәдер бик серле сүз булса кирәк... болай бик авыр чыккач?

Әкълимә *(гадәттәге дуамаллыгына бирелеп, кинәт)*. Серле дә, керле дә түгел, әйтсәм әйтим инде алайса: мин бүген төнлә чак кына да йоклый алмадым, Заһит абый.

Заһит. Я шуннан? Монда минем ни катнашым бар?

Әкълимә *(чын ихлас күңелдән, хәтта эчкә йотыла барган сулкылдау белән)*. Әйтә генә алмадым: бар шул менә. Сине җәлләп йоклый алмадым мин.

Заһит *(уенга борырга тырышып)*. Ай-яй! Бусы инде бөтенләй киртәгә сыймады, Әкълимә. Тавыклар куначадан төшмәс борын, кайдан телеңә шундый шук сүзләр килеп тора?

Әкълимә *(үпкә белән)*. Син алай димә, Заһит абый. Әллә мине белми, сизми дип уйлыйсыңмы? Читендер сиңа абыеңнар өендә. Кара, кичәгенәк ничек ыргылып ташланды. Өйрәнгән соң ул терсәкне теләгәнчә киереп.

Заһит *(җитди)*. Кирәгеннән артык күпне беләсең икән син, чибәрем. Кайда соң, кайтмады бу туганым-җиңги дә. Андадыр бит синең йомышың?

Әкълимә *(ярсып, үҗәтләнеп)*. Ә син сүзне икенчегә борырга азапланма, беләм мин, барысын да сизеп торам: читен сиңа абыеңнарда! Китәргә йөрүең дә шуннан, яшермә.

Заһит *(җитди, хәтта яхшы ук кырыслык белән)*. Кем кушты сиңа минем турыда алай кайгыртырга? Кем әйтте, абыйларда миңа читен, дип?

Әкълимә *(әкрен генә иңрәп)*. Ә миңа, кеше әйтмичә, белергә ярамыймыни? Минем үземнең йөрәгем юкмыни? *(Күңелендәген яшереп кала алмыйча, кинәт кызулык белән.)* Күч син минем өйгә, Заһит

абый. Мин үзем әниләргә барып торырмын, бер башым, миңа кайда да барыбер, күч! *(Йөзен читкәрәк бора, тыелып кына сулкылдый.)*

З а һ и т *(паузадан соң).* Кара әле, Әкълимә, хәзер генә күргәндәй булдым: син бер дә үзгәрмәгәнсең, гел шул сабый чактагы Әкълимә булып калгансың бит, кызый! Исеңдәме икән? Бервакытны, әле минем малай чак иде, Таш чишмә болынында икәүләп сезнең ала бозауны куып йөргән идек. Тирләп-пешеп чыктык, тәки тоттырмады үләт.

Ә к ъ л и м ә. Әллә кайчандагыларны казып чыгарды кеше дигәнең...

З а һ и т. Анда да шулай елап җибәргән идең шикелле.

Ә к ъ л и м ә. Син көлмә, Заһит абый... Мин чынлап әйтәм.

З а һ и т. Яхшы тәкъдимең өчен рәхмәт, Әкълимә. Шулай да син үз өеңә үзең хуҗа булып кал инде.

Ә к ъ л и м ә *(сагая төшеп).* Ә син... китәргәме?

З а һ и т. Әйе, мин китәргә булдым... авылдан.

Ә к ъ л и м ә *(үпкәләгәндәй).* Бер дә харап... кайтып күренүе булды — китеп баруы булды. Кайтып йөрмәскә дә иде алай булгач. *(Исәнләшеп тә тормыйча, ашыгып чыгып китә.)*

З а һ и т *(үз-үзенә).* Кайтып йөрмәскә дә иде... Бәлки, дөрестер дә, бер уйлап карасаң.

Пауза. Бераздан З а к и р һәм К а м ә р и я керә.

З а к и р *(керә-керешкә).* Кайда ул көйсез кияү? *(Заһит каршынарак килеп.)* Нәрсә син? Тора торгач, дигәндәй...

З а һ и т. Тора торгач түгел, күрә торгач... Булды, дәү абый, куйган сыйларың өчен рәхмәт, китәргә уйладым мин сездән.

З а к и р. Үз башың үзеңдә, иллә-мәгәр үпкәләп китә күрмә, нани... Өй иркен, бала-чага юк, ризык ягына кешегә чыкмыйбыз, белмим, нигә кузгалырга уйлагансыңдыр? *(Камәриягә.)* Нәрсә шаккатып калдың? Табын әзерлә, кичәгедән соң болай да баш чатнап тора иде...

З а һ и т. Юк, кирәкми... Буласы булды. Кеше аягы кузгалганчы юл ала торырга кирәк.

З а к и р. Кешедән качырып эшли торган эшең юктыр ич ул хәтле? Болыннан атлар кайтып җитсен, ат җигеп озаттырырмын.

К а м ә р и я. Качмаса да, кешедән бик уңай түгел түгеллеккә. Кайтып унбиш көн тормаган, имештер, туган авылын ташлап китә.

З а к и р. Анысы белән син, карчык, артталыгыңа барасың. Йөргән, дөнья күргән кешегә хәзер бөтен җирдә туган ил.

З а һ и т. Ул хаклы, туганым-җиңги... утырып кайткан энеңне үз тирәңдә калдырып, сүз ишеткәнче, болай тынычрак та булачак.

З а к и р. Син, малай, кыек атып туры тидерергә маташма. Сиңа «кит» дигән кеше юк ич, тора бир.

З а һ и т. Бу дөньяда без барыбыз да кунакка гына килгән кешеләр, кунак була бир, дисең инде син?

З а к и р. Алай безнең сүз ярамагач, бернәрсә дә димим, теләсәң нишлә. *(Аракы чыгарып.)* Юл аягы өчен менә шуны тотыйк та...

К а м ә р и я *(шелтә белән).* Безнекенең бар белгәне шул аракы инде аның... «Юл аягы» имеш... Абый кеше булып ныклап бер сөйләшәсе, ишекне биклә куясы урында...

З а һ и т. Нәрсәсен сөйләшәсең, әйтмичә дә аңлашылып торганны... *(Пауза.)* Шулай да юл аягы өчен абыйның үзенә генә, якын кеше итеп, бер сүз әйтер идем.

З а к и р. Алай якын кеше итеп әйтелә торган сүзне тыңламый ярамас. Җиңгәң алдында әйтәсеңме, әллә үземә генә әйтелә торган сүзме?

З а һ и т. Туганым-җиңгинең ишетеп калганы ярый, әмма синең үзеңә карата гына әйтелә торган сүз: елан йөзгә житкәч аждаһага,

аждаһа йөзгә җиткәч юхага әйләнә, имеш. Хәтерлисеңме, без бәләкәй чакта әни шулай ди торган иде.

Закир. Әнине искә төшерүең ярый. Иллә-мәгәр бу сүзеңнең нөктәсен тотып җиткезә алмадым.

Заһит. Нөктәсе шул: йөзгә җитеп аждаһага әйләнгәнче, син, дәү абый, кит бу председательлек эшеннән: картайгансың да, күп нәрсәне аңламый да башлагансың...

Закир. Төрмәдән кайтып, анысын менә син аңлатып биргәч, рәхмәт инде... *(Кызып.)* Аңлыйммы, аңламыйммы, әлегә минем үз колгам үзем белән. Тавык-чебешләрем дә үз янымда... Синең кебек, кеше колгасына, күрше тавыкларына күз төшереп йөрисе түгел.

Заһит *(Камәриягә якынрак килеп)*. Рәхмәт, туганым-җиңги, абыйны алып кайтып безне соңгы мәртәбә рәхәтләндереп бер серләштердең.

Кулын бирә, капчыгын кулына алып, ашыгып ишеккә борыла.

Закир *(аның артыннан)*. Абыеңа кул да бирмәдеңмени? Мә сиңа, ун көн кунак иткәннең рәхмәте.

Артыннан чыга, берáздан ялгызы гына әйләнеп керә. Тәрәзә каршына килә төшеп, китеп барган энесе белән сөйләшкәндәй, ялгыздан-ялгыз сөйләнүен дәвам итә.

Ә кем сиңа «кит!» диде? «Кит» дигән кеше булмады, үзең сыймадың... Ә үпкә сүзе — дәү абыйга... *(Пауза.)* Шулаймы соң бу хәзергесе минутта? Дөресен әйтәсеңме син, дәү абый? Монда синнән башка берәү дә юк, дәү-абый, әйт кырламыйча-сырламыйча гына: все-таки, әшәке эшләдең син бертуган энеңә карата. Ә нишләп әшәке? Совхозда ул югалып калачакмы? Югалмаган кайда! Таһировларны югалтырсың, бар... *(Яңа бер аклану юлы тапкандай, кинәт ачылып.)* Ә соң син кызыксындыңмы, малай? Ни өчен сине совхозда колач җәеп каршы алырга булдылар? Әһә! Кызыксынмыйсыз сез ул ягы белән. Бактың исә, совхозда кочак җәеп каршы алулары шушы сөйкемсез дәү-абыең тырышлыгы түгелме икән соң? Совхоз директоры Николай Иванович белән кем сөйләште? Шушы сөйкемсез дәү-абыең сөйләште. Ә син аңарга кул да бирмичә китеп бардың. Алай ярамый ул, син теге... сайрыйм дигәч тә, сандугач дип уйлама үзеңне...

Камәрия әйләнеп керә.

Киттеме?

Камәрия. Әллә әйләнеп кайтыр дип шүрләп тора идеңме?

Закир. Болай да баш катып бетте соңгы көннәрдә. Кичә кич теге интеллигентта булган сүздән соң, рәтле төн йокысы күрмәдем. Хәзер әнә бу имгәге, кулын да бирмичә, чыгып китте. Җитмәсә тагы, кирлемырлы сүзләрең белән син башны катырасың. Каты гына итеп чәй пешереп китер.

Камәрия *(өзгәләнеп)*. «Чәй» дигәч искә төште: карасана, чәй дә эчермичә җибәрдек бит Заһитны. Сүз белән ыгы-зыгы килеп соң... *(Ирена, үпкә белән.)* Күңелең булгандыр инде: бертуган энеңне, чәй дә эчермичә, өеңнән куып җибәргәч?

Закир *(уен-көлкегә борырга тырышып)*. Чәй нәрсәгә аңарга, егет кешегә. Мәен биреп карадым, тотмады. Исең китмәсен, энкәсе, Таһировлар беркайда да югалып кала торган малайлар түгел алар! Тем более, андый реабилетларны хәзер төрле яклап артларыннан этәреп торалар.

Камәрия. Синең кебекме? *(Йөрәк белән.)* Нәрсә дип әйтергә дә белмим сиңа, Закир. Кайта-кайтышыннан, керпедәй энәләреңне торгызып, тәки өйдән чыгып китәргә мәҗбүр иттең шул баланы.

Закир. «Шул бала»га хәзер утыз өч яшь. Аның яшендә мин, бөкремне чыгарып, койрыкта сөйрәлүче шушы колхозны тарта идем.

*(Кинәт кабынып.)* Нәрсә сез барыгыз да миңа каныктыгыз? Әллә аны куып җибәрүче кеше булдымы? Китмәсен иде. Киткән икән, юлына ак җәймә. Юкка исең китмәсен, Таһировлар алар югалып кала торганнардан түгел.

Камәрия *(ирен беренче кат күргәндәй, сәер итеп, аптырап, ярым гаҗәпләнү, ярым кызгану белән, озак кына сүзсез карап торганнан соң).* Хәтереңә авыр алма, Закир, син аның турында югалып калганда да әллә ни көймәдең. Белмим, ничек коммунист итеп тоталардыр сине?.. Кеше турында шулай гамьсез караучы кешене?! *(Әйтер сүз таба алмыйча, беравык аптырап торганнан соң.)* Тәрәзәләрне ачыйк, ичмасам! Тынчый башлады бит безнең бу өй!

Тәрәзәләрне ача. Урам чатындагы радиорепродуктордан иртәнге музыка яңгыраганы ишетелә.

Пәрдә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ ЯКИ ЭПИЛОГ

Шул ук Закир Таһировлар өе. Өч айдан соң. Обстановкада нык кына үзгәреш сизелә. Телефон юк, Закирның элеккечә гөрләп чыга торган тавышы ишетелми. Аны председательлектән алып ташлаганнар, хәзер трактор бригадасында водовоз булып эшли. Аңарга аксак бер ат беркеткәннәр, кай көнне атының аягын сылтау итеп, кайсы көнне үз аягындагы ревматизмнан зарланып, күбрәк вакытын өйдә кырын ятып үткәрергә ярата һәм, шулай ялгыз гына калган чакларында, хатыны өйдә булса — хатынына, хатыны булмаса — үзенә-үзе, председатель чактагы данлы хәлләрне сөйли, хәзерге җитәкчелектән зарлана.

Пәрдә ачылганда, бу юлы да аның ялгыз өйдә, аягын сөлге белән караватт башына күтәреп бәйләгән хәлдә, түшәмгә карап уйланып, узгандагылар белән хыялланып ятканы күренә. Урам яктагы ачык тәрәзәдә тракторчы Касыйм тавышы.

Касыйм. Закир абый, әллүр бригадага. Су бетеп килә.

Закир *(яткан җиреннән генә тәрәзә ягына борыла төшеп).* Кара әле, кем, Касыйм, синме ул? Аяк сызлаганга бер дә чама юк бит, малай, бүгенгә шул бар булганын җиткезә алмассызмы икән?

Касыйм. Синең дә кылыгың китте, Закир абый. Председатель чагында гына әтәчләнеп йөргәнсең икән.

Закир. Председатель чактагы ул башка, анда мин раматизмны кадерләп, тарантаска гына утыртып йөртә идем.

Касыйм инде китте, ә Закир, борып җибәргән машина кебек, берүзе сөйләнә дә сөйләнә.

Закир. ...Аннары аның беркеткән аты әдәм рәтле хайван булса икән, ике атламый, ашаган сыек үләнен коя тора, кайдан килсен ул бичарага көч... *(Үзе шулай да әкрен генә сөлгене чишә, аякны идәнгә төшерде, нәрсәнедер тапмагандай, өйдә арлы-бирле селкенә башлады, ә үзе авыз эченнән мыгырдана да мыгырдана.)* Ни әйттем ул дүрт аяклы имгәкне колхоз техникасына якын җибәрмәгез, дип. Олы кеше әйткән сүзгә колак салалармы соң хәзер, җыен бала-чага. Колхоз техникасына кадер юк, Нух заманыннан калган аксак алаша, имештер, бөтен бер бригаданы су белән тәэмин итәргә тиеш, ошамаганны. Эшне белеп эшләү җитми, вәт нәрсә җитми хәзерге әдәм баласына...

Камәрия кайта.

Камәрия. Син дә өйдә икәнсең, иртә кайткансың бүген нишләптер.

Закир. Әле китә алганым юк, аякны түшәмгә асып куярлык булып яттым. Сызлый. Тагын яңгыр буласыдыр.

Камәрия. Машина җибәреп алдырмадылармы соң? Син дә колхозда эшлим дип селкенеп йөргән буласың инде, ходай бәндәсе.

Закир. Машина ук җибәрмәгәннәр, но килеп, тәрәзәдән кычкырып киттеләр.

Камәрия. Нигә артыңнан кеше йөртәсең? Үзең теләп алган эш ич.

Закир. Ачу китереп сөйләнеп торган булма. Сезгә үч итеп башымны бәйләдем мин ул алаша койрыгына. *(Кузгала башлап.)* Су бетә, ди, анда. Теге малайны гына йөгертергә иде, кая олакты үзе?

Камәрия. Иртәнчәк олы тавыш белән мәктәпкә куганыңны оныттыңмыни?

Закир. Әйе, дөрес. Син аңарга тел-теш тидермә, әнисе. Укысын. Хәзергесе көндә укуда бөтен хикмәт. Укып чыгып, берәр зуррак урынга утырса, мин сиңа әйтим... Безгә акча җибәрә башласа... Аннары син мине, карт алаша койрыгына карап, водовоз итеп йөртермен димә инде.

Камәрия *(кече якта ашарга әзерләгән җиреннән түзә алмыйча чабып чыгып)*. Итәгеңне киңрәк җәй! Борынгы ярлы кешенең тары ярмасы кебек, малаең эшләп китергән акчаң идәнгә чәчелмәсен. *(Ачуланып, үртәнеп.)* Без дә үстердек бала. Укытучы Дәмин урамда туктатып әйткәч, җир тишегенә керерлек булдым: мәктәпкә укырга дип киткән малаең сумкасын турник баганасына элгән дә, ди, үзе ише берничә исәрне ияртеп, колхоз бакчасына киткән, ди. Алмагач ботагыннан сөйрәп төшергәннәр үзләрен.

Закир. Тукта әле, кызма. Үчлек белән әйтә торганнардыр. Минем Тансык андый малай түгел ул.

Камәрия. Хурланып үләрсең, билләһи... Үзем правление члены, үземә я шул малаең, я синең арканда гел сүз ишеттереп торалар.

Закир. Минем турыда җүнле кеше начар сүз әйтмәс. Теге малайны әйт син миңә. Колхоз бакчасында, диме? Агач башыннан сөйрәп төшергәннәр, дисеңме? Кайтып күземә генә күренсен, шул үзе күтәреп йөри торган сумкасы белән яңакламасам мин аны, әдәм хурлыгын...

Кызып арлы-бирле чабып йөри һәм кинәт ухылдап кәкрәеп төшә, аягын кочаклый.

Беттем, беттем. Тагы кузгалды... Тагы борып алды. Китер тизрәк мич башыннан җылы киез итекне... Белмәгән кеше кебек шаккатып торасың.

Камәрия *(авырткан аяк өчен сыңар гына киез итек алып килеп)*. Өйдә киез итек... Килде килешең синең дә.

Закир. Килер шул, килмичә.. Ат урынына эшләп торганда, төрле яктан нервымны какшаттыгыз да, инде миңә утыр түр башында аягыңа киез итек киеп...

Капкада бер-бер артлы кыска-кыска автомобиль гудогы.

Кайсысы тагы анда? Берәр корты кыймылдаганы әҗәт түләтергә дип йөрмиме? Председатель чакта сыйлаганы өчен.

Камәрия. Кем йөрсен икән көзге эш өстендә. Җыеныбрак утырчы, шулай да. Килешеңне әйтер идем.

Кабаланып чыгып китә.

Закир *(хатыны артыннан)*. Әй, син, хозяин өйдә юк, кем булса да... Вакытлы-вакытсыз нәфесләрен сузып йөрмичәрәк торсыннар.

Бераздан Камәрия Зарифны ияртеп керә.

Зариф *(керә-керешкә гөрләп)*. Әле ярый, җиңги-абыстай бар. Юкса, туган йортның бусагасында каршы алучы да булмас иде. *(Аягындагы киез итектән уңайсызланып, бер читтә бөрешебрәк утырган Закирга.)* Нишләп болай шиңеп калды әле бу колхоз аристократиесе? Исәнлекме?

З а к и р. Исәнлекне үзең күреп торасыңдыр. Түр башында киез итек киеп утыргач, шуннан билгеле инде.

З а р и ф. Чынлап та, киез итекне бераз иртәрәк кигәнсең син, абый. Гомумән, үзгәрешләр бар булса кирәк сездә?

К а м ә р и я *(уңайсыз тартынкылык белән)*. Әйе, үзгәрешләр бар бездә, Зариф. Бик үк яхшы якка булмаса да.

З а р и ф *(сагая төшеп)*. Ничек аңларга моны? Теге малай аркасында ул-бу булмагандыр ич?

К а м ә р и я. Әнә үзе әйтер нәрсә булганын... Мине гафу итегез, Зариф, теге якта вак-төяк кенә эшләрем бар иде.

Кече якка үтә.

З а р и ф *(укымышлы кеше һәм, гомумән, дәрәҗәле кеше югарылыгында торып)*. Алайса, сине тыңлап карыйк, иптәш Киез итек. Нәрсәләр булды сезнең монда?

З а к и р. Нәрсәләр, дип, ни... үзең күргәнсеңдер, авыл үз урынында. *(Кинәт кабынып.)* Кызыксынуың шулхәтле генә булгандыр, агайэне. Әгәр кызыксынсаң, һич югы ишетер идең. Башка файдаң тияр дип уйлаган юк инде.

З а р и ф. Рәтләбрәк сөйлә: теге малай аркасында берәр бәла килеп чыкмагандыр ич? Кстати, аңарга шул «Кызыл байрак» совхозыннан гаере җир таба алмаган икәнсез. Абыйсының аяклары арасында буталып йөрсен дигәнсездер инде.

З а к и р. Кая киткәнен, ни өчен киткәнен безгә әйтеп тормады ул, сыймады безнең бу кечкенә өйгә.

К а м ә р и я. Сыйдырсак, бик сыясы иде дә...

З а к и р *(хатынын кырыс кына бүлдереп)*. Син анда, хатынбану, үз эшеңне бел һәм мөмкин чаклы тизрәк. Күрәсең, профессор энебез мыекны кабартып килгән, сыйлап, авызын томаларга кирәк үзенең. *(Зариф һәм Закир, бер-берсен күз карашлары белән «укыгандай», сүзсез генә карашып калалар.)*

З а р и ф. Күрәм, аякка киез итекне киеп алгач, борын күтәрелгән синең, картлач. Бер энеңне йорттан ук куғансың, икенчесе белән... сыртны кабартып сөйләшәсең.

З а к и р. Яшерер хәлем юк, кәефем начар түгел, энекәш. Югалтасы афтаритетым калмады, тапканым менә шушы раматизлы аяк. *(Ачулы киная белән.)* Үзара гына әйткәндә, син дә бик алай ашыкмадың агайэнеләр турында кайгыртырга. Элек «иртәрәк булмагае» дип курыктың, хәзер соңга калдың.

З а р и ф *(мыскыллы горурлык белән)*. Гафу итә күрегез, хөрмәтлебез дәү-абый. Докторский диссертациямне яклап, фән өчен, авыл хуҗалыгын фән нигезендә алга җибәрү өчен көрәшәсе урында сезне уч төбемдә тирбәтә алмаганмын икән, тагын бер мәртәбә үтенәм, гафу итә күрегез. Аның каравы бераз соңгарак калып булса да, менә кайттым. Әгәр Мөхәммәт тауга килмәсә, тау үзе Мөхәммәт янына килер, ди.

З а к и р. Без алай китап сүзләре чәйнәп өйрәнгән кеше түгел, энекәш. Син безнең авызга чәйнәбрәк сал: профессор иттеләрме соң инде үзеңне?

З а р и ф. Тәбрик итәргә можете: докторскийны уңышлы якладым, кафедра бирделәр, но, әгәр телисез икән, авыл буена кычкырып йөрегез, сүзем юк: Кара зирек авылының Китек колак Мотыйк малае Зариф — профессор Зариф Таһиров хәзер.

З а к и р *(куперенке тантана белән)*. Менә, ичмасам, моны әйтсәң дә була! Молодец, энекәш. Безнең эше вак-төяк кешеләрне чабуыңа ябыштырмыйча меңдең дә киттең тау башына и менеп тә җиттең. Мин

дә шулай уйлаган идем... Синеке кебек биектән үк булмаса да, үземә күрә, минем дә тавым бар иде...

Зариф. Тукта, ревматизм гына түгел синдә, абый. *(Кече якка эндәшеп.)* Камәрия җиңги! Куйчы юк-бар эшләреңне. Чыгып, аңлатып бирче нәрсә булганын. Мин бит утырмага кайткан кеше түгел, белеп китәсем килә все-же.

Камәрия *(кухня ягында эшләп йөргән җиреннән чыгып)*. Кая кабаланасыз шулхәтле? Әллә нидә бер күренеп, дигәндәй. *(Ире ягына ымлап.)* Нигә? Үзе сөйләмимени бу «дәү абый?» Шулайдыр шул, бик алай шапырынып сөйләрлек эшләр юк безнең якларда.

Закир *(кинәт кабынып)*. И яшереп калып була торган эш тә юк. Кыскасы шул: мине колхоз председательлегеннән тотып аттылар, Зариф.

Зариф. Ревматизм сызлануы гына түгелдер дип әйттем ич... Димәк, сине дә тәбрик итәргә кирәк бу килештән. *(Паузадан соң.)* Ни өчен икәнлеген төпченмәстән, дипломатия сатып тормыйча гына шуны әйтим, Закир абый: чәпчемичә генә уйлап караганда, син инде күптән үк җитәкчелек эшенә ярамый башлаган идең... Беләсеңме син кем? Кайсы чор җитәкчесе? Сталин чорыннан калган дисәм, авырга алырсыңдыр, һәрхәлдә: «Давай! Давай!» чорыныкы. Ә хәзер «Давай! Давай!» белән генә барып булмый, кешеләргә үзең дә бирә белергә кирәк. Җитәкчедән хәзер әнә шул һәм, әлбәттә, чак-чак кына грамота да сорала.

Закир *(бу юлы инде яхшы ук кызып)*. Нәселдән бер профессор булгач, шул җиткән, энекәш. Ә инде теге син әйткән юмартлык, кешеләргә бирү мәсьәләсенә килгәндә, синең белән мин бик күп бирдек, әйтеп бетерерлек тә түгел. Безнең шулай юмарт булуыбыз, «диссертация яклаганчы, минем тирәмдә буталып йөрмәсен!» дип каравыбыз аркасында, кече энебез, әти белән әнинең иң яраткан баласы Заһит, унбиш ел читтә нужа чигеп кайтып, я синең янда, я минем янда урын таба алмыйча, яңадан өйдән чыгып китәргә мәҗбүр булды... *(Күз яшен күрсәтмәскә тырышып, читкә борыла.)* Ә купшы сүзләргә без оста.

Зариф. Ревматизмныкы гына түгел дип әйттем ич. Ревматизмнан кеше, серьезный дигәндә, аяксыз кала, ә син, картлач, башсыз ук калгансың лабаса.

Закир. Ә мин синдә хәтта шундый раматизм да кузгалмаганга аптырыйм. Яшең бар бит синең дә...

Зариф *(тантана белән)*. Спорт белән шөгыльләнәбез, абый. Икенчедән, барометрдан да дөрес файдаланам булса кирәк. Дымлы һава агымы килергә торганда, һәрхәлдә, трусиктан гына чыгып йөгермим... *(Мәгънә салырга тырышып.)* Ә соңгы елларда һавалар гел алышынып тора... Кыскасы шул: бата-калка уйнаучы көйсез кияү Заһит өчен, әллә кайчан үлгән әти белән әнине гүрләреннән кузгатып, алар исеменнән мине кызартырга маташма. *(Закирга якын ук килеп.)* Барып чыкмас, агай-эне. Үзара гына әйткәндә, бик тәбәнәктә калгансың...

Чыга башлый.

Ярый, хушыгыз... Еракта урап кереп, шатлык сүзләре әйтеп чыгыйм дисәм...

Камәрия *(каршы төшеп)*. Рөхсәт юк, Зариф... Бер утырып чәй дә эчмичә, теге ни... Үзең әйтмешли, онытканда бер сугылып...

Зариф. Сиңа рәхмәттән башка сүзем юк, җиңги-абыстай. Әмма чәйләп утырырга туры килми. Шулай ук әнә ул *(Закир ягына ымлап)* председательлектән төшкәч, аеруча акыллыланып калган карт мудрец белән сүз көрәштереп торырга да вакытым юк.

Камәрия. Аңарга үпкәләмик, Зариф. Аның болай да үзенеке үзенә җиткән... Ә Заһитны «көйсез кияү» дип атавың өчен, теләсәң нәр-

сә диген, минем күңел дә риза түгел. Өе юкның көе юк, ди халык. Иң элек без аңарга өен табып бирергә булышырга тиеш идек, ә без ул эшне эшли алмадык.

З а р и ф. Бу да бер ук. Чыгып барганда, җилкәгә төбәп атылган ук булса да... *(Бусагадан кире борылып, пафоска бирелә төшеп.)* Безнең өебез менә мондый дүрт стена белән генә чикләнми, безнең өебез — безнең илебез ул. Ә безнең илебездә кеше бервакытта да югалмый. Әгәр эчендә җаны булса, Таһировлар исемен пычратырга теләмәсә...

Чыкмакчы була. Ләкин өлгерми, тырылдап капка төбенә килеп туктаган мотоцикл тавышыннан бераз аптырашып калгандай, сүзсез генә бер-берсенә карашалар. Ул да түгел, ишектә М ә х м ү т. Аның күңел күтәренкелеге йөзенә бәреп чыккан.

М ә х м ү т *(керә-керешкә шаулап)*. Тукталып, сөенче алмыйча, турыгыздан үтеп китә алмадым... *(Зарифны күреп.)* О, кунак бар икән, исәнмесез, Зариф абый.

З а р и ф *(кулын биреп)*. Танып та бетерә алмассың хәзерге яшьләрне. Кем дип әйтим?

З а к и р *(арага кереп һәм җиңелчә генә кадарга тырышып)*. Бу — таныта торган егет, Зариф. Баштарак мин дә танымаган булган идем дә... *(Мәхмүткә.)* Я әйт, тагын кайсыбызның башына җитәргә дип килдең?

М ә х м ү т. Башыңа җитәргә түгел, үзем белән алып китәргә. Анда бит сине көтәләрдер, Закир абый?

З а к и р. Кайда? Буш мичкә янындамы? Ул турыда синнән башка да кайгыртучылар булды.

М ә х м ү т. Кирелегеңне кунак алдында да күрсәтмә. Сине ындыр табагына весовщик итеп беркетүебез турында кичә чакырып әйттек ич.

З а к и р. Мин дә әйттем әйтәсе сүземне: я куясыз фермага, я шул аксак алашам белән калам.

М ә х м ү т. Ферма мәсьәләсе хәл ителде. Фермага Заһит кайта. Кстати, нигә әле мин сөенче алмыйча торам? Райкомнан кайтышым: безнең ул героебызны партиягә восстановить иттеләр.

З а к и р. Тукта әле син, интеллигент. Җунләбрәк сөйлә.

К а м ә р и я. Шуннан да җүнлесе тагы нәрсәдә? Кеше алдында бакча карачкысыдай басып торасың. Ичмасам, сал итегеңне.

З а к и р *(бераз җиңеләеп киткәндәй)*. Итеккә калсамы? Салабыз аны итекне. *(Сыңар аягындагы киез итекне салып, атып бәрә. Оекчан гына калган килеш, өй буенча титаклап.)* Кая соң, әнкәсе... чыгарчы тизрәк капкалап алырга. Минем монда... теге ни... Юк шул, акылга утырды хәзер Закир абыегыз. Чәй белән булса, мөмкин...

К а м ә р и я *(Закирга)*. Тукта инде, чапма, койрыгы пешкән мәче кебек. Кешегә әйтәсе сүзен әйтеп бетерергә бир.

З а к и р. Какой сүз шуннан да зуррагы. Таһировлар үз урыннарына кайталар.

М ә х м ү т. Менә бусын дөрес чамаладың, Закир абый: әйе, Таһировлар үз урыннарына кайталар. Райкомда нык кына сөйләшә торгач, Заһитны үзебезнең колхозга — ферма мөдире итеп кайтарырга күндердек. Хәзергә — менә шул!

Китә.

З а к и р. Әттә генәсе икән! Утыртып булмады бит теге шома егетне чәйгә. Болай булгач... икебезгә генә кала дигән сүз, энекәш.

З а р и ф *(мәгънә салырга тырышып)*. Юк, болай булгач, теге малайны да счет төймәсенә керт инде син, Закир абый. Һәм тагы шуны да счет төймәсенә сал: ат җигепме, җәяүләп кенәме, сиңа ул егетнең хозурына барып, җайлап кына бер сөйләшергә кирәк булыр. *(Камә-*

*риягә.)* Әйттем ич мин сезгә, Камәрия җиңги... «Безнең илебездә кеше югалмас» дип әле яңарак кына әйттем түгелме? Однако, сез мине гафу итегез, озаграк юанып калдым, минем әле совхозга сугыласым бар. *(Китәргә җыена.)*

Камәрия. Бер дә килешмәде инде бу, Зариф. Утка чапкан кебек, күзебезгә күренәсез дә югаласыз.

Закир *(кинәт уйчанланып).* Сиңа хәзер, Зариф туган, иркенрәк йөрергә дә була торгандыр инде. Аласы профессорлыкны алдың, аяк астында буталып йөрүче теге малай юк.

Зариф. Күлмәгең белән генә ике кат син, абый... Нишләмәк кирәк, илле җиде яшькә җитеп кермәгән акыл кермәс шул. *(Җитди.)* Ә син беләсеңме шуны, бәлки шушы син өнәп бетерми торган профессор энеңнең кайда булса да, кем алдында булса да бирәр сүз әйтүе кирәк булгандыр? Барометрың дөрес эшләми синең, абый, һаваларның ничек торганлыгын дөрес чамаламыйсың и шуннан әнә ул ревматизмың, и шуннандыр бәлки төшә баруың да... *(Сәгатенә карап.)* Сәгать дигәнә бара. Гафу итә күрегез, киттем, ашыгам, йөрисе җирләрем, күрәсе кешеләрем бар.

Ашыгып чыга. Закир аны озата.

Камәрия. Һаман ашыга, һаман күрәсе кешеләре бар бу Зарифның!.. Белмим, әллә сөенде Заһит хәбәрен ишетеп, әллә сөенмәде?

Чыга. Ачык тәрәзә аша ишек алдыннан саубуллашу сүзләре, автомобиль гудогы ишетелә.

Пәрдә.

## МОРДВА МӘКАЛЬЛӘРЕ

**Теле белән он тарта, кабарга ипие юк.**
**Бармак төртеп күкне тишеп булмый.**
**Ачыны татымаган — татлының тәмен белмәс.**
**Усал сүз — күзгә сипкән тоз.**
**Ут йотканның авызында һәммә нәрсә дә ачы.**
**Кеше киндеренә ышанып күлмәксез-ыштансыз калган.**
**Җилкә баштан өстә булалмый.**
**Чүлмәк чуенга иш түгел.**
**Балдак бармак күрке түгел, бармак балдакның күрке.**
**Гомер буе тукыса да, тукран столяр түгел.**
**Буе — агач, акылы — чикләвек.**
**Буш капчык басып торалмый.**
**Хәйләкәр эт һәркемгә койрыгын болгап өрә.**
**Кыю кулда кылыч үткенрәк була.**
**Нинди генә зур булса да, куян күзе куркак күз.**
**Әгәр вакытсыз өзсәң — барча алма да әче.**
**Каты бөксәң, карама да сына.**
**Ике кат ялгышканны өченче кат алдап булмый.**
**Шаулап үскән агачта да коры ботаклар була.**
**Кешегә дип әлмәк үрмә — үз муеныңны кысмасын.**
**Йоны бик еш коелса да, бүренең холкы үзгәрми.**
**Саран бай фәкыйрьдән дә ярлырак.**
**Дусларын онытканның үзен дә онытырлар.**
**Юләр юлдаш дошманнан яман.**
**Кеше тавыгын аша, үзеңнекен суя тор.**

# Очерклар

*Дифгать Сирай*

# ТӨРЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Бу язманың авторы шактый вакыт колхоз парткомы секретаре булып эшләде. Бу язмаларын ул үзе турыдан-туры аралашкан, кайгыларын да, шатлыкларын да бергә уртаклашкан шул колхоз кешеләренең эшләренә һәм язмышларына багышлый.

## Тагын юлда

Үзенең күз яшедәй саф тамчылары, ястык калынлыгы боз кантарларын бер-берсенең маңгаена чәкештерә-чәкештерә яр читләренә ыргыла торган куәтле ташулары, ала-кола сыер төсенә кергән басулары, кыяр-кыймас кына баш калкытып килүче болын чәчәкләренә бер сирпелүдә җан кертеп җибәрерлек шифалы нурлары белән шаулы яз килде.

Шатлыклы яз авазына челтерәп аккан гөрләвекләр тавышы, ишек алларында сыртларын кояш нурларында җылытып торучы мал-туарларның яшел үләннәрне сагынып ямансу мөгерәүләре, капка башларындагы кечкенә «өйләрендә» кайнашып йөрүче сыерчыкларның сызгыруы килеп кушылгач, күңелләрдә дәртле бер симфония тирбәнеп киткәндәй булды. Озак та үтмәде, иркен сулыш алып, бакчадагы алмагачлар бөре җибәрделәр, шомыртлар чәчәк атты.

Кадерле кунак кебек сагынып көтелгән Май бәйрәмнәре дә тиз генә үтеп китте. Шушы вакытны безнең якларда, гадәттә, җәйнең башы дип йөртәләр, чөнки күпчелек елларда яз бәйрәмен иртә культуралар чәчүне төгәлләү белән каршылыйлар иде. Быел бу турыда авыз ачып ләммим дигән кеше булмады: басу өсләрендә кара-кучкылланып кар сулары җыелып тора, берничә көннәр буена рәттән өзлексез рәвештә чиләкләп яңгыр коя. Көн аязып җибәргән вакытларда да кояш нурлары туфракны киптерергә өлгерми калалар, көтмәгәндә әллә кайдан килеп чыккан кара болыт күк йөзен тагын томалап китә.

Шундый көннәрнең берендә мин химия эшчеләре поселогы Бондюгтан егерме километрлар чамасындагы «Таң» колхозына барырга булдым. Беренче очраган йөк машинасына утырып, унике километр үткәннән соң, җәяүләп, Балан авылына илтә торган юлга чыктым.

Пычрак сыланган итекләремне көчкә-көчкә генә сөйрәп колхоз идарәсенә килеп кергәндә, җитәкчеләр инде төшке ашка таралганнар иде. Биш километр арада никадәр кадерле вакытымны югалтканымны стенадагы сәгатькә күз салгач кына аңлап алдым. Хәер, транспорт булмау аркасында мин генә түгел, парткомның башка работниклары да, колхозда файдалы эшләр белән шөгыльләнү урынына, күп вакытларын юлда машина көтеп үткәрергә мәҗбүр булалар иде.

Бераздан өй алдында тавышлар ишетелде. Ишектән беренче булып тәбәнәк буйлы, кысык күзле, футбол тубына охшаган йомры гәүдәле мари егете — колхозның баш бухгалтеры килеп керде. Аның артыннан утыз ел эшләү дәверендә басу мәшәкатьләре җилкәләрен иңрәйтеп төшергән агроном карт, өсләренә майга тапланган җылы сырмалар, пинжәкләр кигән механизатор егетләр күренде. Аларның җитди карашларыннан, киеренке хәрәкәтләреннән аяк-кулны бәйләп торучы яңгырларга, чәчү өчен яхшы срокларның үтеп баруына тирән борчылу аңлашылып тора иде.

— Кичә басуга чыгып караган идек, — диде үз фикерләрен бөртекләп аңлатырга яратучы агроном. — Трактор белән түгел, аяк белән дә кереп булмый. Бата...

Аннары ул миңа көндәлек мәгълүматлар язылып барыла торган бер калын дәфтәр сузды.

Ләкин андагы буш графаларга күз йөртеп чыгарга да өлгермәдем, сайлау вакытларыннан калган кечкенә генә кызыл тумбочка өстенә куелган иске телефон зеңгелдәп куйды. Трубканы алуга, мең төрле шытырдаулар аша, ерактан партком инструкторының өзек-өзек тавышы ишетелде. Ул мине сорап шалтырата иде.

Сөйләшү озакка бармады. Юл мәшәкатьләре турында сорашканнан соң, әлеге инструктор әйтеп салды: «Әле генә район үзәгеннән Беренче шалтыратты. Хәзер үк сине Калинин исемендәге колхозга җибәрергә кушты. Анда барып, партия җыелышы әзерләргә кирәк булыр...»

Ул колхозның партком секретарен икенче колхозга председатель итеп күчергәннәр иде. Бу эшкә яраралык кулай кеше табылмаганлыктан, аның урыны берничә айлар буенча буш торды. Менә бүген мин моннан кимендә утыз километр ераклыкта булган шул колхозга барып, җыелышның алдан хәстәрен күрергә тиеш. Ләкин ни өчен башка кеше түгел, ә мин? Егерме-утыз километрдан мине чакыртып йөргәнче, телефон төбендә утыручы шул ук инструкторны җибәрергә мөмкин түгел-мени?

Шундый каршылыклы фикерләр белән ишеккә таба борылдым, һәм, председательгә бер-ике көннән яңадан килергә вәгъдә итеп, тагын юлга чыктым.

Тирә-якта элеккечә яз сулый. Пычрак ерып, үрләргә менә-төшә алга атлыйм. Әмма тормышыңның кайсы үрләрендә тукталып каласыңны белмисең икән шул. Парткомның партоештыручысы сыйфатында бу колхозга икенче тапкыр бер вакытта да әйләнеп кайтмаячагымны мин күңелемә дә китермәгән идем...

## Беренче көннәр

Киң итеп ачылган тәрәзәләр аша бүлмәгә ургылып иртәнге саф һава керә. Челтәрле пәрдәләр җиләс җилдә талпынып-талпынып куялар да, чабуларын күтәреп, тәрәзә борысларына ешыналар. Таң җиле, авылга килгәч тә туган каршылыклы уйларны, икеләнүләремне күңел түреннән куып чыгарырга теләгәндәй, йомшак кына җиңнәремә кагылып, мине каядыр шау-шулы урыннарга, урманнарга, елга буйларына чакыра шикелле.

Өйдән чыккач та, колхоз идарәсе урнашкан кечкенә генә бинага юл тотам. Аның ишегенә гадәттә ашлык амбары бикли торган зур кара йозак эләп китәләр. Иртәнге сәгатьләрдә ничә генә килсәң дә шундый күңелсезлеккә юлыгасың. Икенче авылда яшәгәнлектән, председатель әле бу вакытта килеп җитми. Хәер, аның торган авылы да колхозның бер бригадасы бит, ул инде күптән басуга чыгып китә торгандыр... Тик менә Сөзәк Үр бригадасында кешеләр соң уяналар. Кайберәүләр көтү

киткәнен дә сизми калалар, тәрәзәгә кояш төшкәнче, мендәрләреннән башларын күтәреп карамыйлар. Андыйлар, бригадирның радио аша эшкә әйтүен ишетсәләр, юрганнарын тагын да тартыбрак куялар.

Мондый күренешләргә каршы көрәшүе җиңел булмаячагын, коммунистлар арасында да андый хәлләрнең очраштыргалаганын алдан ук колакка төшереп куйганнар иде инде.

Беренче көннәрдә хуҗалык белән колхоз председателе Зиннур Шакиров таныштырды. Холкы аның бик сабыр, юкка-барга күкерт кебек дөрләп китми. Әмма әйткән сүзеннән кире кайтырга яратмый, кирәк чакта ярдәм кулы сузарга әзер тора. Озын телле җилкуарлар белән йомшак кына сөйләшеп, каты гына итеп утырта да белә.

Төсе-битенә карап, Зиннурга беркем дә илледән ким бирмәс. Күз төпләренә уелып кергән тирән җыерчыклар, әле бөдрәләрен җуярга өлгермәгән сирәк кенә көмеш чәчләре, олы яшьтәге кайбер ирләргә генә хас була торган басынкылыгы, моның өстенә вакытыннан элек тулылана баруы аны бераз картрак итеп күрсәтә. Ә аңа әле нибары утыз тугыз яшь.

Минем күз алдымда аның ике рәсеме тора. Берсе — хәзергесе, икенчесе — армиядән кайткач төшкәне. Беренчесенә карап, гомуми сызыклар буенча гына аның хәзерге Зиннурга беркадәр охшашлыгын шәйлисең. Армиягә киткәндә Зиннурга унсигез яшь була. Сигез ел буена солдат шинеле җилкәсеннән төшми. Туган илнең бик күп урыннарында була, бик күп вакыйгаларны башыннан кичерә ул. Йөргән юлларында күңелне әсир итәрлек бик матур яклар очрый аңа. Ләкин туган кырлары, Кызыл Яр басуларында каерылып үскән ашлыклар бервакытта да күз алдыннан китмиләр. Аның шунда кайтасы, сөйгән кызы белән кушыласы, үзе ялан аяк сабан сөреп йөргән басуларда кабат иген игәсе килә.

Кырык җиденче елдагы корылыклар аркасында йончыган авыл сөмсерләнеп кенә каршы ала аны. Моның серенә тиз төшенеп алган Зиннурга, хәзер армиядән кайткан кайбер яшьләр кебек, айлар буе типтереп йөрергә туры килми. Ул трактор бригадасына эшкә керә. Тырышлыгы, күндәмлеге белән башка яшьләрдән аерылып торган Зиннурны авылда гына түгел, районда да бик тиз күреп алалар, аңа колхозның буш кассасы белән таушалып беткән печатен тапшыралар.

Башта бер колхоз булып яшәгән Кызыл Ярга Тургай авылын китереп кушалар. Шулай итеп «Кызыл комбайн» хуҗалыгы барлыкка килә.

— Беренче елларда бик тә авыр булды, — дип сөйли торган иде Зиннур. — Уңыш аз алынды. Кешеләр дә ачлы-туклы яшәделәр. Ә терлекләр турында әйткән дә юк. Баш саны да күп түгел иде түгелен...

Мыскаллап-мыскаллап җыелган колхоз байлыгы әкренләп арта бара. Ә соңыннан, колхозчыларны унлы лампалар да канәгатьләндерми башлагач, артель авылларында дәүләт электр линиясе сузарга кирәклеге турында сүз кузгала.

Кечкенәрәк кенә бер колхоз өчен унсигез-егерме чакрымга линия сузарга теләүче булмый, әлбәттә. Күршедәге гомердән-гомергә мантымаган хуҗалыкны — Чапаев исемендәге колхозны кушу турында сүз кузгала.

Озак та үтми, биш авылны берләштергән, алты мең гектарга якын сөрүле җире булган Чапаев исемендәге зур колхоз барлыкка килә. Председатель итеп Шакировны калдыралар.

Бик табигый: колхоз кинәт кенә сикереш ясый алмый, әлбәттә. Моның өчен күп тырышлыклар куярга, тәмле йокылар белән дә хисаплашмаска туры килә.

Бу чорларда КПССның тарихи XXI—XXII съездлары булып үтә. Шулай ук КПСС Үзәк Комитеты Пленумнары кабул иткән карарлар да хуҗалыкны алга җибәрүдә гаять зур этәргеч булалар...

# Күңелсез очрашу

Май урталары иде. Сергей югалган дигән хәбәр бер колактан икенчесенә күчеп, шул көнне үк колхоз авылларында уртага салып сөйләшерлек вакыйгага әйләнде.

Мин ул кешене якыннан белми идем. Председатель аның ферма мөдире булып эшләве, соңыннан баш-аягы белән аракы шешәсенә «чумганы» турында сөйләгән иде инде. Сергей — кайчандыр район газеталарында макталган, ясалма орлыкландыру техникы булып эшләгән вакытларда исеме телдән төшмәгән кеше. Ә менә бүген, атна буе эчеп йөргәннән соң, ферманы ташлап каядыр чыгып киткән.

Сергейның кинәт кенә юкка чыгуы барыбызны да аптыраушта калдырды.

Икенче көнне бүлмәгә елый-елый күзләре кызарган, нәфис гәүдәле бер кыз килеп керде. Алсу йөзле, кыйгач кара кашлы бу кыз Сергейның кызы Мария иде. Мин аның күптән түгел җәйләүдә сыер сауганын күргән идем.

— Әтиең табылдымы?

Ни әйтергә белми аптырап торган кызга председательнең беренче соравы шул булды.

— Юк, — диде Мария ишетелер-ишетелмәс кенә. — Район үзәгендә күреп кайтканнар дип ишеттек, чынмы-ялганмы...

Керфекләрендә моңа кадәр сабыр гына мөлдерәшеп торган яшьләр бите буйлап агып төштеләр...

Ике-өч көннән соң бүлмәгә тәбәнәк буйлы, чандыр гәүдәле, күз кабаклары шешенеп беткән Сергейны чакырып керттеләр.

— Чит җирләрдә ямансу түгелме? Коммунист кешегә шулай йөрү килешәме?

Сергейга төбәлгән һәр караш та менә шундый сорауларны укырга була иде. Чыннан да, бу очракта, ферманы, өендәге берсеннән-берсе бәләкәй җиде баласын онытып, кайдадыр типтереп йөргән кеше белән коммунист дигән кадерле исем арасында ниндидер уртаклык табу кыен иде.

Без аның барысын да төкми-чәчми сөйләп бирүен сорадык. Ләкин, сөйләү урынына, кызганыч кыяфәттә басып торучы Сергейның яңак сөякләре генә әле түбән төшеп, әле югары күтәрелеп биешәләр иде.

— Күрше совхозга күтү алырга дип бардым. Сез бит мине партиядән чыгаргансыз. Шулай булгач, монда минем бөтенләй кирәгем калмаган, — дип тезеп китте ул, озак кына фикерләрен җыйнап торганнан соң.

Аннары пинжәк җиңе белән ирексездән бәреп чыккан күз яшьләрен сөртеп алды. Һәм ул эчеп йөргәне өчен дә, ферманы ташлап китеп, эшкә зыян китергәне өчен дә, ниһаять, партиядән чыгарылуга кадәр барып җиткәне өчен дә бик нык үкенәдер кебек тоелды.

Әйе, партоешманың берләштерелгән җыелышы чыгарган шул турыдагы карар минем сейфта ята иде. Мәсьәлә Андреевның үзеннән башка гына хәл ителде. Шунда бу гафу ителмәслек нәрсәнең парткомның беренче секретаре кодрәте белән эшләнгәнлеге кылт итеп исемә төште. Ләкин ул вакытта сүзнең нәрсә турында барганын абайламый да калганмын, чөнки үземне шул җыелышта партком секретаре итеп сайладылар. Күрәсең, күңелдә туган төрле уйлар, киеренкелек мәсьәләнең асылын ахырынача аңларга ирек бирмәгән.

Партком бюросы бу ялгышны үз вакытында төзәтте. Ләкин кешенең йөрәгендә гомерлек яра калды. Дөрес, Сергейның кыйланышлары болай гына үтмәде, аңа эчеп йөргәне өчен каты шелтә белдерелде. Тик бу җәза, аның катнашыннан башка партиядән чыгаруга караганда, бик күп мәртәбә җиңелрәк иде бит.

Сергей тиз арада үз хатасын аңлап алды. Тәртибе үзгәрде, узган ялгышларны кабатламый башлады. Җыелышларда да гомуми мәсьәләләрне тикшергәндә авыз йомып утырмый, үз фикерләрен әйтергә тырыша. Соңыннан колхоз правлениесенә килеп, ул сыерлар көтүен үзенә тапшыруны үтенде. Бер үк вакытта ясалма орлыкландыру техникы вазифасын үтәүне дә үз өстенә алды.

Сергей үзенә тапшырылган эш өчен зур җаваплылык тоеп эшләде. Бу тырышлыгы аңа мактау китерде. Ул, сыерларны ясалма орлыкландыру буенча матур күрсәткечләргә ирешкәне өчен, республика күләмендәге бүләккә лаек булды.

Партком утырышларының берсендә җаваплы эш тармакларында партгруппалар оештыру турында карар кабул иткән идек. Андый группаны Сөзәк Үр товарлыклы-сөтчелек фермасында да оештырырга булдык. Терлекче коммунистлар җыелышында бу турыда сүз чыккач, алар үзләренең җитәкчесе итеп бертавыштан Сергей Андреев кандидатурасын күрсәттеләр.

— Дүрт аяклы ат та сөртенә. Ә кешене, барыннан да элек, ышаныч күрсәтү белән дәваларга кирәк, — диештеләр алар, Сергейның үткәндәгеләренә ишарә, шул ук вакытта кисәтү ясап.

## Өйләр, өйләр...

Беренче карашка, Сөзәк Үр авылының үзенә тартып торырлык бер матурлыгы да юк кебек. Бер-береннән әллә ничә метрлар ераклыкта тезелеп киткән өйләре белән тарау гына дүрт урамы, бер якта машина-трактор паркы белән мастерской, икенче якта берничә йөз баш мал сыйдырышлы терлекчелек каралтылары, һәм яз айларында кечкенә күперләрне дерелдәтеп, такталарын үзенә иярте алып китүче, җәй көне чыпчык эчәрлек тә суы калмый торган инеше бар.

Башта шулай шыксызрак күренгән авыл тора-бара нәрсәсе беләндер үзен яраттыра башлады. Эш белән районга яки берәр җиргә чыккан чакларда да аны юксына башлыйсың. Тау астында карт таллар арасында челтерәп агып ятучы «ак чишмәсе» (авыл кешеләре аны «изгеләр чишмәсе» дип йөртәләр), инеш буендагы еламсыр таллары, башларын янтайтып утыручы карт өянкеләр кинәт кенә берьюлы күңелне билэп алалар.

Бу авылда керәшен татарлары яши. Колхозга кергән башка авылларда, алардан тыш, күп кенә рус семьялары да бар. Дөресме-ялганмы, бу милләтләрнең берләшүе царизмның башка милләтләрне руслаштыру политикасы үткәргән заманнарга барып бәйләнгән дип сөйлиләр. Ләкин хикмәт анда түгел: биредә русы да, татары да бик тату яши, чөнки алар — колхозның үз хуҗалары.

Авыл кырына сөзәк кенә тау терәлеп тора. Аның өстенә менеп карасаң, барыннан да элек, урамнарда күкрәк киереп торган яңа өйләрне күреп аласың. Авылның әле бер, әле икенче очында күптән түгел күтәрелгән буралар чират житкәнен көтеп торалар.

Мәскәү янындагы машина-трактор сынау станциясеннән килгән бер карт инженер да яңа йортларны күреп соклануын яшерә алмаган иде. Ул болай дип сорау бирде: «Нинди хисапка төзиләр аларны?»

— Үз хисапларына, — дип җавап бирдек без аңа.

— Ә төзү материалларын кайдан аласыз? — диде ул, тагын да төпченебрәк.

Чыннан да, колхозның егерме-утыз километр әйләнәсендә бер төп агач кисәрлек тә урман юк. Шуңа да карамастан, кешеләр яңа өйләр салалар, каралтыларын яңарталар.

Удмуртиянең тирә-юнь авыллары белән безнең колхозның дуслыгы, ярдәмләшүе инде традициягә әйләнгән. Алар бездә, без аларда — кө-

телгән кунак. Нинди үтенеч белән мөрәҗәгать итсәң дә, буш кул белән кире борып җибәрмиләр. Колхоз өчен дә, колхозчылар өчен дә агач материалларның күпчелеге әнә шуннан кайтарыла инде. Үз чиратында, без аларга салам, печән, кайчакларда фураж белән дә ярдәм итәбез.

Авылдагы төзелешләр турында сүз чыккач, бер вакыйгага тукталып үтәсем килә.

...Районнан кайтып килә идек. Янымда руль тотып утыручы Михаил Васильев нигәдер башка вакытлардагы кебек ак тешләрен күрсәтеп көлми, мин биргән сорауларга да теләр-теләмәс кенә җавап кайтарып бара. Ә күзләре юлга, юл кырындагы дулкынланып утыручы бодайларга төбәлгән. Ул нәрсә турындадыр уйлый һәм, шуларның очына чыга алмыйча, газаплана кебек тоелды миңа.

— Нишләп болай бик уйчанланып киттең әле син? — дидем мин авылга җитәрәк.

Ул җавап кайтарырга ашыкмады. Авыл башына килеп туктагач кына, мунчага охшаган җил капкалы кечкенә генә бер өйне күрсәтте. Аннары:

— Менә шунда сигез җан гомер итәбез инде, — дип көрсенеп куйды. — Олы малай бераз ярдәм итәргә булган иде. Аның акчасына гына әллә ни майтарып булмастыр, ахры... Яңадан бер өч йөз сумлап табылса, яхшы булыр иде. Иске өйне дә сатмый булмас.

Кайткан көнне үк мин бу турыда председатель белән сөйләштем. Ул моңа каршылык күрсәтмәячәген, әмма кассада акча булмау сәбәпле, бер-ике көн көтеп торырга кирәк булачагын әйтте, һәм:

— Үзе килеп сорарга батырчылык итмәгәндер, ахры. Аның гадәте шундыйрак инде. Кукрәгенә мылтык төзәсәләр дә, кирәк нәрсәсен башлап сорарга үзе килмәс. Ул йорт турында мин үзем дә аның белән сөйләшергә йөри идем әле,— дип елмаеп куйды.

Бер атна арасында колхоз шоферы коммунист Васильев авыл читендәге бәләкәй өен калдырып, зур якты йортка күчте.

Колхоз идарәсенә шундый сорау белән мөрәҗәгать итүчеләр бер Васильев кына түгел, әлбәттә. Аларның барысы да диярлек, берничә елдан кайтарып бирү шарты белән, кассадан әҗәткә кирәк кадәр акча алып китәләр.

Бер вакыт колхоздан бурычка акча алу тәртибендә салынган өйләрне санап карадык. Сөзәк Үр авылында гына соңгы дүрт ел эчендә кырыктан артык хуҗалык яңа өй туйлары үткәргән булып чыкты.

Бу хәлне колхоз экономикасының үсә баруы белән генә аңлатырга була. 1962 елда ук биредә колхозчылар хезмәт хакын акчалата ала башладылар. Сыер савучыларның, механизаторларның хезмәт хаклары совхоз эшчеләренекенә тигезләнде.

Зур мәйданнарда борчак игә башлау колхозларга бик күп файда китерде. Бу культурадан мул уңыш алган беренче елны ук колхоз аякка басты. Икенче елны борчак мең, аннан да соңгы елны исә мең ике йөз гектар мәйданда чәчелде. Шуның нәтиҗәсендә кышка җитәрлек яхшы сыйфатлы силос салып куелды, яңа елның теге ягына колхозчыларның хезмәтенә алты ай түләргә җитәрлек акча чыгып калды.

Менә нәрсә хисабына салыналар алар — яңа өйләр!

## Гаеп кемдә соң?

Басулар кардан әрчелде. Кояш үзенең нурларын юмарт сибә башлады. Җир өстеннән пар күтәрелә. Кайбер урыннарда инде тракторлар гөрелтесе ишетелә. Механизаторларның күптәннән зарыгып торган куллары, рульләрне боргалый-боргалый, агрегатларны бер-бер артлы басуга чыгаралар.

— Көткән идек — башланды! — дип куйды председатель, үр буйлап басуга менеп баручы тракторларга таба күрсәтеп. — Хәзер чыдап кына тор инде. Сынатмасак ярар иде...

Өркетерлек әллә нәрсә юк инде югын. Машиналар нигездә ышанычлы. Механизаторлар да бурычларын яхшы беләләр. Һәр ике партоешмада да агитаторлар сайлап куелды. Бригада саен сыйфат инспекторлары билгеләнде. Ярыш шартлары җир-су кипкәнче үк аңлатылды. Барлык партоешмаларда, бригадаларда җыелышлар үткәрелде. Алай гына да түгел, 97 коммунистның, йөздән артык комсомолецның барысы да диярлек язгы кыр эшләрендә катнашалар.

Беренче көннәрдә чәчү уңышлы гына башланып китте. Ләкин соңга табарак партком членнары белән кайбер мәсьәләләрне ахырынача чишеп җиткермәгәнебез дә ачыкланды. Моңа беренче бригада бригадиры Әхмәтҗанов сәбәпче булды. Ул, бөтен эшне механик өстенә ташлап, машиналарга үткәрелгән ремонтның сыйфаты белән бөтенләй кызыксынмаган. Янәсе, ул, бригадир буларак, барыннан да элек гади колхозчылар белән генә эш итәргә тиеш. Ә чынлыкта, аны үзе тракторчы булганы, кирәк чакта яшь механизаторларга ярдәм күрсәтә алуы өчен бригадир итеп билгеләгән идек. Ул моны акламады, әйбәт көннәрдә агрегатларның ватылып тору очраклары булды.

Чәчүне төгәлләгәч, гадәттә, ашлыкны урып-җыю турында уйлый башлыйлар, Ләкин Әхмәтҗановны басуда өлгереп килгән арышлар да, борчаклар да кызыксындырмады, ул көннең теләсә кайсы вакытында бары тик үз хуҗалыгын гына кайгыртты. Яхшылап әйтүләргә, үгетләүләргә колак салмагач, партком утырышында, учет кенәгәсенә язып, каты шелтә белдерергә мәҗбүр булдык, эшеннән алып, гади тракторчы итеп калдырдык. Әлбәттә, аңа иске трактор тәкъдим ителде.

— Мин ул тракторда эшләүдән баш тартам, — диде ул, кырт кисеп.

— Үзең төзәт тә, үзең эшләп күрсәт,— диделәр аңа партком членнары һәм бу карарны тормышка ашыруны миңа тапшырдылар.

Икенче көнне Әхмәтҗановның авылдан эзе суынган иде инде.

Бер ай чамасы узгач, ул, минем янга килеп, партия учетыннан төшерүне таләп итте. Мин аңа колхозда эшләргә кушып, беркая да җибәрмәячәгебезне әйттем.

— Өем дә иске, торырлык түгел, китәм, — диде ул кирелэнеп.

Председатель белән бергәләп, өй салу өчен колхоздан акча алырга тәкъдим ясадык. Ул безне тыңлап торырга да теләмәде, ишекне шап итеп ябып чыгып китте. Әмма бу кирелекнең сәбәбен без соңыннан гына аңладык.

Идарә парткомына барып, шушы хәлне сөйләп биргәч: «Сезнең коммунист бит, кайтартыгыз», дип кенә җавап бирделәр, һәм миңа секретарьлардан кемнеңдер, аны учеттан төшереп, күрше совхозда эшләвен дәвам иттерергә кушканлыгын әйттеләр. «Безнең белән киңәшмичә, моны беркем дә эшләргә булдыра алмый», дигәч, Үзәк Комитет инструкцияләрен начар белгәнлегемне төшендерделәр.

Ул арада Әхмәтҗанов совхозның таштан салынган яңа квартирасына күчте. Аннары: «Монда тракторчылар җитми, килегез», — дип, авылның башка механизаторларын котырта башлады.

Парткомның вакытында кул сузмавы менә нинди авыр нәтиҗәләргә китерде. Эш аның белән генә бетмәде. Бераз вакыт үткәч тә, Михайлов дигән колхозчы, партия учетыннан төшмичә, шул ук совхозга эшкә барып керде. Аның артыннан яхшы тракторчыбыз Иван Александров. семьясын алып, совхоз авылларының берсенә китеп барды. Күп тә үтмәде, ике яшь коммунист механизаторыбыз каядыр чыгып китте.

Парткомның эндәшмәвен сизеп алгач, совхоз дирекциясе аларны үзенә кабул итә торды. Ә бит боларның барысы да партия учетыннан төшмәгән, колхоз правлениесенең рөхсәтен алмаган кешеләр иде.

Идарә парткомына берничә тапкыр бу турыда язма рәвештә сигнал биргәч, кайбер бюро членнары: «Сез үзегез кадрлар белән эшли белмисез», дип безне гаепләделәр.

Бик күп көч куйганнан соң, киткән коммунистлардан бары тик бер Иван Александровны гына үз арабызга кире кайтарта алдык. Аны да зур кыенлыклар белән колхоз парткомы членнары үзләре хәл иттеләр.

Кайберәүләр кадрларны тәрбияләүдә, оператив житәкчелектә һәм хуҗалык планнарын үтәүдә партия һәм хуҗалык органнарын үзгәртеп коруның файдасы гаять күп булачак дип бәяләделәр. Мин, делегат буларак, өлкә партия оешмасының XXXI конференциясендә дә бу хакта кайбер чыгышларны ишеткән идем. Ләкин аның зыяннан башка бернәрсәсе дә булмады. Без, партия органнарында турыдан-туры эшләүчеләр, аның кыенлыкларын үз күзләребез белән генә күреп калмадык, үз җилкәләребездә дә татыдык.

## Кирәкмәгән ярдәм

Тышта буран котыра. Берничә адым атларга да өлгермисең, эзләрне шунда ук кар тигезләп китә. Шундый буранлы көннәрнең берендә колхоз идарәсе янына озын яллы бер күк ат килеп туктады. Чана түренә, толыпка төренеп, ике кеше утырган иде.

Толыпларын култык астына кыстырып идарәгә кергән юлчыларны без шунда ук танып алдык. Берсе — идарәнең баш ветврачы, икенчесе әле күптән түгел генә участок лечебницасына куелган ветеринария работнигы иде.

Алар безгә үзләренең белгечлекләре буенча ярдәм итәргә килүләре турында әйттеләр.

— Менә күптән шулай кирәк иде, — дип, хуплап каршы алдык без аларны.

Шундый ният белән килүләренә куанмаска мөмкин түгел. Чөнки колхоз бу өлкәдә дүрт аякка да аксый иде. Мин эшләгән вакытта колхозда бер генә юньле ветеринария работнигы да юк иде дисәм, ялгышмам. Җибәрелгән кешеләр, тиешле шартлар тудырылуга да карамастан, куелган таләпләргә түзә алмыйча, китеп бардылар, яки бу эшне без генә эшләп бетерә алмабыз дигән кебек, артка чигенделәр. Шундый бер фактны искә төшереп үтәсе килә.

Безгә Мөнир исемле бер егетне зоотехник итеп җибәрделәр. Комсомолец, яшь белгеч иде. Килгәч тә торак урыны, азык-төлек белән тәэмин иттек. Тик егетне болар гына канәгатьләндермәде. Ул авылда кино залларының, театрларның булмавыннан зарлана башлады. Яхшылап эшкә тотыну, өйрәнү урынына күпчелек вакытын йоклап үткәрде. Нәтиҗәдә, эштән бушатырга туры килде.

— Белгечләр булмаудан безнең ничек интегүне үзләре күреп китсеннәр әйдә, — дидек без, председатель белән икәүдән-икәү генә калгач.— Бәлки, хәлне аңлап, нинди дә булса берәр җаен эзләп табарлар.

«Кунаклар» бездә ике көн тордылар. Фермаларда булдылар, кешеләр белән сөйләштеләр. Ә инде китәсе көнгә каршы минем кулга эшләгән эшләре турында төзелгән акт тоттырдылар. «Таныштым дип, кул куегыз», — диде баш врач, актны миңа сузып.

— Сез ярдәм итәргә түгел, булган фактларны теркәргә, тырнак астыннан кер эзләргә килгәнсез икән. Әмма сез теркәгән фактларның яртысы да чынбарлыкка туры килми, ә калганнары — бу актсыз да күптән инде сезгә мәгълүм.

Шундый кискен җавапны ишеткәч, барыбер кул куймаячагымны аңлап, толыпларын алдылар да урамга чыгып киттеләр.

Берничә көннән колхоз председателен, ревизия комиссиясе председателен һәм башка работникларны район партия-дәүләт контроле ко-

митетына чакырттылар. Алар, актта күрсәтелгән фактлар һәм дуңгызларның күпләп үлеменә юл куйган өчен каты кисәтү алып кайттылар.

Дуңгызлар салкын тию, чир аркасында гына үлмәделәр. Ул елны фуражга да кытлык иде. Иген уңмауга да карамастан, ашлыкны ташыттылар да ташыттылар. Дәүләткә ун мең центнерга якын ашлык озаттык. Барлы-юклы ашлыктан колхозчыларның һәр семья членына 1 центнер да 70 килограмм исәбеннән ашлык өләштек. Бу, әлбәттә, бик аз иде. Амбар төпләре дә такыраеп калды. Калган фуражны исәпләп карагач, аның ярты кышка да җитмәячәге ачыкланды. Комбиазык сорагач, бирмәделәр, шуның аркасында утыз, хәтта егерме килограммга җитмәгән дуңгыз балаларын да ит комбинатына илтеп тапшырырга туры килде. Алар арасында йодрык кадәрлеләре дә бар иде бит. Шулай итеп, колхоз ит җитештерүдәге төп резервтан колак какты. Икенче елны да ит сату планнарының үтәлмәвен бары тик шуның белән генә аңлатып була. Ит җитештерүне җайга салу, элекке хәленә кайтару өчен генә дә ике елдан артык вакыт кирәк булды.

Без мондый «ярдәмнәргә», әлбәттә, мохтаҗ түгел идек.

## Рәхмәт әйттеләр

Авылдан чыккач, районга бара торган юлның бер читендә түбәсе шифер белән ябылган зур таш бина тора. Кышкы айларда да, җәй көннәрендә дә аның тирәсендә хәрәкәт, көлү һәм җыр тавышлары бервакытта да тынып тормый. Яшьләр хәтта клубтан да бизеп беттеләр, кичләрен гел шунда килә башладылар.

Бу бина китапханә дә, бию залы да түгел, ул — терлекчеләр йорты. Бөтен әһәмиятле чаралар менә шунда үткәрелә иде.

Ул бинаның салынып кына яткан вакытларын хәтерлим. Шул чакта ук инде аңа югарыдан теш кайрап йөрүче «агайлар» бар иде. Алар: «Терлек абзарларыгызның рәте юк, ә үзегез шундый йортны терлекчеләр кунып ята торган җиргә әйләндерергә уйлыйсыз. Монда бит кимендә йөз баш бозау тотарга була», — диделәр. Бигрәк тә аңа сыерларны мамык түшәкләрдә тотарга әзер торучы белгечләр хасландылар.

Без аларның сүзләренә колак салырга ашыкмадык. Терлекчеләргә эшләү өчен тиешле шартлар тудыру бурычын хәл итәргә тиеш идек. Терлекчелек каралтылары чыдарлык иде әле. Яңаларын да салмыйбыз түгел. Шул ук елны дуңгызлар өчен Тургай авылында таштан салынган типовой абзарны файдалануга тапшырган идек.

Терлекчеләр өчен аерым йорт кына булдырып калмадык, анда, чыннан да, рәхәтләнеп ял итәрлек, буш вакытны культуралы итеп үткәрерлек чаралар да күрдек: язучыларның рәсемнәрен, лозунглар элдек. Караватлар, җитәрлек санда кыйммәтле урындыклар, өстәлләр алдык. Күчмә китапханә булдырылды. Тыңларга теләүчеләр өчен радио керттек. Тәрәзә пәрдәләре дә элеп җибәргәч, йорт эче тагын да ямьләнеп китте. Бер сүз белән әйткәндә, терлекчеләр йорты терлекчеләр клубына әйләнде.

Йортның икенче яртысында ашханә оештырылды. Ай саен була торган терлекчеләр җыелышларын без бик күңелле итеп үткәрә идек. Тәҗрибә алышкач, бүләкләр тапшырылгач, терлекчелектә эшләүчеләр өчен аш әзерләтәбез, аннары шунда ук кино күрсәтәбез. Кинодан соң яшьләр төн уртасына кадәр күңел ачалар.

Йортның шулай җиһазландырылуына сәбәп тә бар. Башка авыллардан килеп эшләүчеләр өчен ул бигрәк тә уңайлы булды.

...Әле без белмәгән бик күп яшьләр бу йортның ишекләрен ачып керерләр. Алар шушы өйләрдә ял иткән, фермада җиң сызганып эшләгән апаларның — колхозның алдынгы сыер савучылары Валентина Козлова, Александра Игнатьева һәм башка бик күпләрнең тәҗрибәләрен өй-

рәнеп, әйбәт терлекчеләр булып җитешерләр. Шушы йортларны салдырган, аларга киләчәктә рәхәтләнеп эшләр өчен шартлар тудырган өлкән абыйларын да искә алмый калмаслар...

## Язмыш төрле була

Берничә көн рәттән Ефим тынгылык бирми.

— Укуым әрәм була бит. Тагын бер тапкыр сөйләшеп кара әле, бәлки җибәрер.

Сүз председатель турында бара. Миңа мөрәҗәгать итүче — яңарак кына бригадир итеп билгеләнгән кеше — Чистай авыл хуҗалыгы мәктәбендә читтән торып укучы Ефим Николаев. Кышкы сессиягә бару турында сүз чыккач, председатель аңа быелга сабыр итәргә кушкан. Моны фермада килеп чыккан кыенлыклар белән аңлатырга тырышкан. Әмма аларны бер Ефим генә төзәтә алмый, шуңа күрә аны җибәрмәүнең дә мәгънәсе юк. Аннары читтән торып укуның гадәттән тыш авыр икәнен дә аңларга кирәк бит. Ә Ефим инде өченче курсны тәмамлап килә. Моның өчен бик күп көч куярга туры килде аңа. Контроль эшләрен күтәреп минем янга килгән чаклары да аз булмады.

...Ефим ир уртасы кеше. Төрле кызыклы хәлләр турында сөйләргә ярата. Көлгән чакта аның бөтен әгъзалары хәрәкәткә килә кебек. Көньяк халыкларныкына охшаган какчыл йөзенә шатлыклы вакытта кояш чыккандагы кебек алсу яктылык җәелеп киткәндәй була, ачулангандa — ул кара төнне хәтерләтә. Кырык яшь тутырып килүенә дә карамастан, башында бер генә чал чәч бөртеген дә тапмассың. Андый чәч дөньяның кайгы-хәсрәтләрен күрми яшәгән кешеләрдә генә була диләр. Моның дөреслегенә ышануы кыен.

Ефим Бөек Ватан сугышында катнашкан. Ул фашист лагерьларындагы җәберләүләрне дә үз җилкәсендә татыган. Әмма аңа фашистлар тырнагыннан котылып, туган якларын кайтып күрергә, аның киң басуларында җиң сызганып эшләргә насыйп булган.

Сугыштан соңгы елларда колхозга беренче кайткан машинага утыручы Ефим булган. Колхозның механигы дәрәҗәсенә беренче булып күтәрелүче дә ул булды.

— Җиде класс белән генә тукталып калмадым,— ди ул, үткәннәрне исенә төшереп. — Алдынгы кешеләр белән бергә атлыйсым килде...

Ефим ул елны да укырга барып, өченче курсны уңышлы тәмамлап кайтты.

Ефимга иярүчеләр дә шактый табылды. Элекке колхоз шоферы Алексей Петров тагын бер елдан Чабаксар авыл хуҗалыгы мәктәбен тәмамлап чыга. Моннан ике ел элек колхоз бригадиры Василий Степанов Ефим укыган мәктәпкә керде. Андыйларны хәзер күпләп санарга була.

Ефим, партком секретаренең беренче урынбасары буларак та, күп эшләрдә эшләп йөрде. Җыелышларга, партия комитеты утырышына материаллар әзерләүдә күп кенә эшләр башкарды. Моннан тыш аны партия-дәүләт контроленә булышлык группасы председателе итеп сайладылар. Бу группа хуҗалыктагы җитешсезлекләрне ачты, әрәм-шәрәм итүчеләрне, колхоз милкенә кул сузарга яратучыларны фаш итте.

Николаев хәзер дә туган колхозында эшли.

## Сабан туенда

...Бондюг стадионына килеп кергәндә, әле сабан туе башланмаган иде. Эсселектән алҗыган кешеләр лареклар тирәсендә кайнашалар. Биредә химия заводы эшчеләре дә, авыллардан килгән колхозчылар да, ераклан кайткан кунаклар да бар.

Озакламый радиодан сабан туе программасын хәбәр иттеләр. Түгәрәк эчендә көрәш башланып китте.

Сабынланган баганага менүче егетләрнең житезлегенә сокланып карап торганда, көтмәгәндә каршыбызга матур чәчәкле күлмәкләр кигән бер төркем кызлар килеп чыкты. Карасам, әлеге мин эшләгән колхозның сыер савучылары икән. Алар бирегә сабан туе карарга килгәннәр. Кызлар авылларында үткән сабан туе турында сөйләп алдылар, кунакка килмәгән өчен дусларча гына әрләп тә куйдылар. Алар арасында колхозның яхшы савымчылары, кайчандыр колхоз путевкасы буенча Идел буйлап сәяхәттә йөргән Александра Игнатьева кебек кызлар да бар иде.

— Сөт савып алу буенча быел алда барабыз, — дип куйдылар алар.

Аннары үзләренең тормышлары һәм эшләре турында сөйләделәр. Алардан аерылып китәргә дә өлгермәдем, безнең якка таба салмак кына атлап килүче Шакиров үзе күренде. Озак вакыт күрешми торганнан соң, кабат очрашуга икебез дә бик шат идек.

Ул быел тагын да картая төшкән. Күз төбендәге сызыклар тирәнәеп, гәүдәсе тулыланып киткән.

Хәл-әхвәл белешкәч, колхоздагы үзгәрешләр турында сүз чыкты.

— Теге урман полосасы янындагы ташлы урынны хәтерлисеңме? — диде Зиннур, минем беләктән алып, һәм без мәйдан тирәли йөреп киттек.

Әйе, мин ул участокны яхшы хәтерли идем. Елның-елына иген уңмый торган участок иде ул. Берничә бөртек чәче тырпаеп торган такыр башны хәтерләткән әлеге участокны җәй урталарында яңадан сөреп, яшел азык өчен үлән чәчә идек. Алай да мантымадык. Ә хәзер, культураларны дөрес чиратлаштыргач, анда күкрәп бодай үскән.

Бөртекле ашлыкларны сатып алу бәяләрен күтәрү, колхозларга льготалар бирү, колхозларны авыл хуҗалыгы машиналары белән җитәрлек күләмдә тәэмин итү буенча партиянең март Пленумы эшләгән чаралар турында сөйләшү аеруча кызыклы булды.

— Ашлыкны хуҗалыкта бераз кысып калу теге вакытта ни өчен эшләнә иде соң? Фәкать терлекләрне исән-сау кышлатып чыгару, азмы-күпме продукт алуны арттыру өчен генә дияргә мөмкин. Дәүләткә планнан тыш ашлык саткан өчен, әлбәттә, мактадылар, ләкин аның өчен барыбер артыгын түләмәделәр. Мактау сүзләрен ишетүгә караганда, артык ашлыкны терлекләргә өстәмә фураж итеп бирү берничә тапкыр файдалырак бит. Без, мәсәлән, ел саен дәүләткә унике мең центнерга якын ашлык сатабыз. Хәзер икмәккә бәяләр дә бермә-бер күтәренке диярлек. Уйлашып карашкач, безнең колхозчылар план белән генә чикләнеп калмаска булдылар...

Зиннур бу турыда сөйләгәндә, ашлык сатудан кергән артык акчаның хуҗалыкның иң мөһим тармакларында тотылачагын, шуның белән бергә колхозчыларның хезмәтенә түләүнең яхшыртылачагын әйтте. Бик табигый: бу нәрсә хезмәт җитештерүчәнлеген, кешеләрнең активлыгын күтәрүнең мөһим чарасы булачак.

Колхозда машиналар саны да артырга тиеш. 1953 елда алынып, инде күптән эшләү сәләтен югалткан техника урынын яңа ашлык комбайннары, төрле маркадагы тракторлар алыштырачак. Соңгы алты-җиде ел эчендә бирегә бер генә йөк машинасы да алынмады. Булганнары да, запас частьлар җитмәү сәбәпле, сезонның әйбәт вакытында да эшсез тик торалар иде...

...Зиннур белән очрашу миңа бәйрәм өстенә бәйрәм кебек булды. Без аның белән әле сабан туе ярышларын карап, әле баштан кичкәннәр һәм киләчәккә планнар турында сөйләшә-сөйләшә караңгы төшкәнче диярлек йөрдек...



## *Данте Алигьери*

*Италиянең бөек шагыйре Данте Алигьери 1265 елда, Флоренциядә туа. Ул үз дәверенең иң укымышлы кешеләреннән санала. Папачылык һәм феодаль анархия дошманы Данте гомеренең күп елларын сөргендә үткәрә һәм шунда үлә дә.*

*Иҗат юлын ул итальян телендә язылган шигырьләре белән башлый (ул вакытта итальян әдәбиятында латин һәм француз телләре киң кулланылган).*

*Аның «Илаһи комедия» исемле бөек әсәре, үз заманындагы зур политик проблемаларны күтәреп чыгу белән бергә, итальян әдәби теле камилләшүенең тиңсез үрнәге булып та санала.*

# ИЛАҺИ КОМЕДИЯ

## Егерме беренче җыр

*(Сигезенче түгәрәк. Бишенче чокыр. Ришвәт алучылар.)*

Шулай, минем комедиямә чит
сүзләр сөйли-сөйли, икәү без
бик күп күпер үттек, күрергә дип

Каһәр упкынын һәм мәгънәсез
яңа бик күп газапларны; шунда
кара упкын күрде күзебез.

Венециянең арсеналында
Кайнаталар сумала кышын;
Көймәләрен вакыт бар чагында

Тизрәк сылап калдыру өчен;
Кайсы ишкәк ясый, кайсы ямый
Көймәсенең тишелгән төшен;

Кем койрыгын, кем борынын җайлый,
Кем яңасын ясый тырышып,
Кем җилкәнен, кем арканын барлый.

Упкында да бер ходай кушып,
утсыз кайный кап-кайнар сумала,
биек ярга чәчрәп, ябышып.

Быкырдый ул, күбекләр чыгара.
Мин, күрмичә эчтә ни барын,
карап тордым беравык шуңарга.

Күзәтмәкче идем мин тагын,
«Кара, кара!» — диеп нәкъ шул мәлне
тартты дустым, сузып кулларын.

Мин, өстенә килгән зур казадан
күзен ала алмый, куркынып
карый-карый чапкан кеше сыман,

күзем салсам артка борылып,
нәрсә күрәм! — кап-кара бер шайтан
безгә таба килә йөгереп.

Шундый ямьсез үзе, кабахәт җан!
Кот очарлык булып күренде
килгәндә дә хәтта ул ерактан.

Ботыннан ул тотып берәүне,
капчык кебек салып җилкәсенә,
бер кыяга менеп үкерде:

«Зобаныйлар! Бу старшина менә.
Бүләк сезгә Изге Дзитадан.
Ә шәһәрдә алар күбәү генә.

Кабат китәм мин шунда табан.
Анда кемнәр генә ришвәт алмый! —
Бер Бонтуро түгел бит һаман».

Ыргытты да аны, күз дә салмый
шундый чапты, эт тә алай тиз
чапмас карак куган чакта, җаный!

Калкып чыккач сумалалы йөз,
кычкырдылар шайтаннар күпердән:
«Танымыйбыз Изге Йөзне без!

Серкьо түгел бу син йөзеп йөргән!
Теләмәсәң безнең ыргакны:
«Чум син төпкә!» Йөзләп ыргак бердән

кадалдылар тегеңә шул чакны.
«Бие, ләкин башыңны күрсәтмә;
төптә уйна, булма беркатлы!»

Пешекчеләр нәкъ шулай күзәтә:
чыгармасын өчен ярдәмче
Казанда кайнаган итне өскә.

Әйтте дустым: «Ят мин килгәнче
шушы кыяда син посып кына,
күреп алыр юкса берәрсе.

Минем өчен ләкин һич курыкма:
беренче кат килмим мин монда,
күнеккәнмен алар гаугасына».

һәм күпердән китте ул шунда;
тыныч тотты үзен ул алтынчы
текә ярны үткән чагында.

Узган чакта ярлы берәр юлчы
ташланган күк этләр таларга,
ярсу белән шайтаннарның барсы,

ыргакларын тотып, аңарга
ташландылар, эләктерергә теләп;
ул кычкырды явыз җаннарга:

«Ашыкмагыз өзгәләргә тешләп!
Өлкәнегез кайда? Сүзем бар.
Аннан ни эшләтсәгез дә рөхсәт!»

«Чык, Койрыклы!» — диде шайтаннар.
һәм Койрыклы, мыгырданып, килде:
«Нәрсә бар?» — дип. Юлбашчым аңар:

«Әйт, Койрыклы, миңа шуны, — диде, —
Ходай белән язмыш кушмаса,
исән җитәр иде димсең мине

сезнең янга? Юл бир, ичмаса!
Үтәсем бар берәү белән бергә
сезнең шушы утлы җир аша».

Куеп шайтан ыргагын шул җирдә,
горурлыгын җуеп куркудан:
«Кул сузмагыз!» — диде тегеләргә.

Әйтте миңа юлбашчым шуннан:
«Чык та посып яткан җиреңнән син,
курыкмый бар минем артымнан!».

Киттем шундук аның янына мин,
омтылдылар алга шайтаннар.
Үзем куркам: «Алдыйлар болар», — дим.

Курыкканын шулай күргән бар
бер взводның, чыккач Капронадан,
күреп алда бик күп дошманнар.

Юлбашчыма сыенып куркуымнан,
мин тик тордым, шүрләп аларның
күзендәге ачу утларыннан.

Берсе әйтте явыз җаннарның:
«Арт саныннан эләктереп, әллә
акыртыйммы алда барганын?»

Ләкин безнең белән сөйләшергә
чыккан шайтан әйтте шунда ук:
«Әй, Алҗыткыч! Куй ыргагың, тимә!»

Аннан безгә әйтте: «Алда юк
бу сырт буйлап үтү мөмкинлеге:
күпер җимерек әллә кайчан ук.

Ләкин барыйк дисез икән инде,
китегез вал буйлап. Үзе ул
илтеп куяр кирәк җиргә сезне.

Уникe йөз алтмыш алты ел
һәм биш сәгать тулды кичә әнә
өзелгәнгә ул якларга юл.

Тик ятмыймы халык ул тирәдә,
карыйсы бар шуны безнең дә.
Бергә китегез, курыкмый һич кенә дә.

Кыекканат! Картлач! Сезнең дә
урын шунда. Сакал башлык булыр.
Көчек белән Җирән өстенә .

Эт Кычуы белән Чукмар барыр.
Сакал тагын Карт Чучка Телен,
Аждаһа һәм Кыланчыкны алыр

һәм күзәтер сумала күлен.
Ә боларны озатыгыз әнә
үткәнгәчә якын тау үрен».

«Ходай өчен, — дидем җитәкчемә, —
юлдашсыз да безгә бик ярар.
Үзең дә син юлны беләсең лә!

Ныграк кара: әнә бит алар
Ымлашалар нидер барысы да
һәм тешләрен шыкырдаталар».

«Борчылма син,— диде дустым шунда,—
сумалада кайнаучыларга
шулай итеп яный алар монда».

Бар да китте аннан сул валга...

*Әхмәт Исхак* тәрҗемәсе.

## ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ ҖЫРГА ИСКӘРМӘЛӘР

Венециядәге атаклы кораб верфе турында сүз бара.

Зобаныйлар — җәһәннәмдә эшләүче рухлар — шайтаннар.

Изге Дзита — Лукка шәһәрендә яшәгән изге (XIII гасыр). Биредә шәһәр урынына шуның исеме телгә алына.

Старшина — Лукканы идарә итүчеләрдән берсе.

Бонтуро Дати — Луккадагы зур дәрәҗәле кеше. Иң мәшһүр ришвәт алучы.

Изге Йөз — Лукка шәһәрендә кара агачтан эшләнгән Христос сыны.

Серкьо — Лукка янындагы елга.

Капрона — 1289 елны Лукка һәм Флоренция гаскәрләре тарафыннан алынган замок. Яшь Данте шул гаскәрләр сафында булган.

Уникe йөз алтмыш алты ел — Христос үлгән минутта җир тетрәү вакытында җәһәннәмдә дә тетрәү булып, шунда күпернең җимерелүе турында сүз бара. Христосның 34 яшьтә үлүе турындагы легенданы исәпкә алганда, Койрыклы сөйләгән вакыт 1300 нче ел булып чыга.

*Фуат Вәлиев*

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ЮВЕЛИРЛЫК СӘНГАТЕ

**Ювелирлык әйберләре халкыбыз сәнгатенең матур һәм үзенчәлекле бер төрен тәшкил итәләр. Төрле төстәге асылташлардан һәм затлы металлардан эшләнгән бу әйберләрнең (аларны элек «зиннәт нәрсәләре» дип атап йөрткәннәр) күбесе, инде кулланылыштан төшеп калуларына, музей коллекцияләрендә яисә аерым олы буын кешеләрнең сандык төпләрендә генә саклануларына да карамастан, бизәкләренең матурлыгы, эшләнешенең гаҗәеп нәзеклеге белән хәзерге буын кешеләрен дә җәлеп итәләр һәм татар халкының көнкүреш сәнгате тарихына бик кызыклы һәм әһәмиятле материал бирәләр. Без бу мәкаләдә әнә шул зиннәт әйберләренең — бизәгечләрнең төрләре һәм аларның нинди техник алымнар белән эшләнүләре хакында кыскача мәгълүмат бирмәкче булабыз.**

Культурабызның бүтән тармакларындагы шикелле, бу өлкәдә дә безнең традицияләребез болгарларга барып тоташа. Шәһре Болгарда һәм янәшә-тирәдәге бүтән шәһәрләрдә, берничә гасыр соңрак Казан шәһәрендә атаклы ювелирлар, шул заман татар теле белән әйткәндә, «зәргәр»ләр һәм алтынчылар яшәгән — археологик казынулар вакытында Болгар чоры һәм Казан осталары эшләгән кыйммәтле әйберләр әледән-әле табылып тора. Ул әйберләр буенча без болгар-татар ювелирлык сәнгатенең яңа формалар, яңа мотивлар белән баеп килүен, декоративлыкның тагын да көчәя баруын күзәтә алабыз. Затлы металларның көнкүреш сәнгатендә, бигрәк тә, феодалларның көнкүрешендә киң кулланылуы хакындагы мәгълүматлар шул заманның төрле әдәби әсәрләрендә дә сакланган. Мәсәлән, Казан ханлыгы тарихы буенча бик кызыклы истәлекләрне һәм халык авыз иҗаты әсәрләрен эченә алган «Казан тарихы» әсәрендә (ул XVI гасыр уртасында билгесез бер рус кешесе тарафыннан язылган) без хан сарайларындагы җиһаз һәм феодалларның кием-салымы хакында шундый мәгълүмат табабыз: «Хан асыл таҗын киде, табынга алтын-көмеш савыт-саба тезделәр»[1]. Шушы ук автор, Казан шәһәренең яулап алынуы турында сөйләгәндә, Казаннан алынган төрле әйберләрнең — алтын-көмеш савытларның, затлы киемнәрнең уникe көймәгә төяп Мәскәүгә озатылуы турында хәбәр итә[2].

XVI—XVII гасыр татар ювелирлык сәнгате әсәрләре, мәгълүм сәбәпләр аркасында, бик аз сакланган. Бу чорда эшләнеп тә, хәзергә безгә мәгълүм булган әйберләрдән алтын каптырмаларны һәм алкаларны күрсәтергә мөмкин[3].


Болардан тыш, әлегә хәтле махсус өйрәнелмәгән, әмма эшләнү техникасы, орнаментикасы, стиле белән татар сәнгатенә якын булган тагын берничә әйбер бар (мәсәлән, «Казан таҗы» дип йөртелә торган алтын таҗ). Металл эшкәртү сәнгатенең (шул дәвер татар теле белән әйткәндә, «мәгъдәнчелек»нең) ни дәрәҗәдә торышын без XVII йөзләрдән сакланып калган җиз кувшиннан да белә алабыз[4].

Алтын каптырмалар болгар-татар ювелирлыгының традицион техник алымы —

---

[1] Казанская история. Рус телендә. СССР Фәннәр академиясе нәшрияты. 1954 ел, 55 бит.
[2] Шунда ук, 98 бит.
[3] СССР халыкларының Ленинградтагы этнография музеенда саклана.
[4] Бу кувшин Казан педагогия институты доценты Ә. Ишморатовта саклана.

филигрань белән эшләнгән. Каптырмалар, төрле-төрле чәчәк бизәкләре төшерелеп, асылташлар белән бизәлгән. Алты почмаклы йолдыз мотивы да гомуми композициягә бик тә килешеп тора. Каптырма өслегендәге сурәтләр яфрак рәвешле булып, аларның эчке



Билбау каптырмасы.

өлешенә тагын да филиграньлап эшләгән вак-вак бизәкләр төшерелгән. Бизәкнең очлаеп торуы, сызыкларның киеренкелеге бөтен композициягә динамика һәм тантана төсе бирә. Татар ювелирлык сәнгатенең орнаментикасына хас яфрак сыман бу бизәкләр Болгар сәнгатенең бөтен төрләрендә дә бик киң кулланылган [1]. Безнең халыкта аның семантикасы күптән инде югалган, ул тәмам стильләшеп беткән. Күңелдә ямьле табигать, гөл чәчәкләргә хас күркәмлек һәм яз шатлыгы ассоциациясен уята торган бу бизәк лалә чәчәгеннән алынып үзгәртелгән булса кирәк. Бу төр зиннәтләү формасы Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия халыклары сәнгатенә дә хас, белгечләр аны «көнчыгыш баррокасы» дип йөртәләр [2].

Татар халкы рус дәүләте хакимлеге астына кергәннән соң, татар ювелирлары металл эшкәртү эше белән шөгыльләнә алмыйлар — патша хөкүмәте рөхсәт итми. Шуңа да карамастан, татарлар үзләренең күп гасырлык ювелирлык сәнгате традицияләрен югалтмыйлар, осталыкларын һәм һөнәрләрен яңа буыннарга калдыра киләләр. XVIII гасырның икенче яртысыннан башлап Казан татарлары белән Төркстан, Урта Азия халыклары арасында сәүдә һәм культура мөнәсәбәтләре көчәеп китә. Шушы мөнәсәбәтләр аша югары катлауларда Дагстан, Кавказ һәм Урта Азия осталары эшләгән ювелирлык әйберләре дә кулланыла башлый. Ләкин алар татар ювелирларының сәнгать техникасы алымнарына да, орнаментикасына да сизелерлек йогынты ясый алмаганнар.


Элегрәк — XVI гасырның урталарыннан XVIII гасыр урталарына кадәр — ювелирлык сәнгатенең төп үзәге Казан арты авылларында (Кышкар, Әтнә, Мәңгәр) генә булса, XVIII гасырның икенче яртысында инде Казан шәһәрендә дә ювелирлар күренә башлый. Капиталистик мөнәсәбәтләр көчәйгән саен, кустарьчылык эше дә күбрәк тарала һәм Казан губернасының Мамадыш, Лаеш, Тәтеш өязләрендә дә ювелирлык эше нык кына тамыр җәя. Шулай да, иң оста эшләүчеләр, татар ювелирлык сәнгатенең күп гасырлык күркәм традицияләрен лаеклы дәвам иттерүчеләр булып Казан арты осталары санала. Алар эшләгән әйберләр татарның төрле төбәкләре һәм этник төркемнәре арасында гына калмыйча, Башкортстанда, күрше фин халыклары арасында һәм хәтта Урта Азиядә дә күпләп тарала. Чит базарларда татар осталарының филигрань техникасы һәм асылташлардан инкрустацияләп эшләгән әйберләре аеруча кыйммәт йөртелә. Татар ювелирлык әйберләренең төрле чит халыклар арасына үтеп керүе ул халыкларның ювелирлык сәнгатенә дә тәэсирсез калмаган. Татар ювелирлык сәнга-

[1] П. М. Дульский. Народное искусство Татреспублики. «Художественная культура советского Востока» исемле җыентыкта. Мәскәү. 1931 ел, 80 бит.

[2] Б. Засыпкин. Монументальное искусство советского Востока. Алда телгә алынган җыентыкта, 40—41 битләр.

тенең башкорт халык сәнгатенә йогынтысы бигрәк тә зур булган [1]. Үзбәк халык сәнгатенә булган йогынты турында исә сәнгать белгече А. Морозова менә болай яза:

«XIX гасырда Казан Россиянең көньяк-көнчыгыш районнары өчен үзенә бер төрле культура-мәгърифәт үзәге шикелле иде. Урта Азиягә Казаннан укытучылар һәм тәрҗемәчеләр килә, китап шуннан китерелә, төрле-төрле товарлар — татар мастерларының ювелирлык әйберләре, тегү машиналары, тамбур белән чигелгән кара бәрхет тукымалар китерелә һәм алар халыкның хәлле катлаулары арасында бик киң тарала иде» [2].



Яка чылбыры.

XIX гасыр азакларында татар ювелир сәнгате өлгеләренә иярүчеләр рус мастерлары арасыннан да табыла. Бу яктан караганда, элекке Лаеш өязе Балык Бистәсе авылындагы рус осталарының эшләре характерлы. Алар арзанлы металлардан беләзекләр, чулпылар, алкалар, чәч тәңкәләре эшлиләр. Ләкин рус мастерларының ювелирлык әйберләре, сәнгатьчә һәм техник эшләнешләре ягыннан, ул чаклы затлы түгелләр, җитмәсә, аларда эклектик модерн сәнгатенең йогынтылары да сизелә. Бу әйберләр һәр яктан да түбән зәвыклы сатып алучыларга исәпләнгәннәр. Шуңа да, рус осталарының эшләре татарлар арасында киң тарала алмаган: алар, күбрәк, Эрбет, Мәкәрҗә һәм Минзәлә ярминкәләре аша, ераграк, чит җирләргә озатылганнар.

XVIII—XIX гасыр татар ювелирлары иҗат иткән әйберләр арасында эшләнү техникасының камиллеге, формасының һәм, гомумән, бизәгенең — сәнгатьчә сурәтенең килешле булуы белән сокландыра торганнары байтак. Бу әйберләрнең күбесен хатын-кызлар бизәнү өчен кулланганнар. Алар арасында беләзекләр, йөзекләр, төймәләр, каптырмалар, муенсалар, чылбырлар, чулпылар һәм башка шундый әйберләр бар.

Татар ювелир сәнгатенең иң күркәм әйберләреннән берсе — яка чылбыры. Халкыбызның көнкүрешенә беренчеләрдән булып игътибар иткән Каюм Насыйри аны менә болай тасвирлап китә:

«...Муенга кия торган нәрсә бар, яка чылбыры диләр. Әүвәле укадан яка ясыйлар. Ул каты була, аны тамак астыннан китереп каптырмалыйлар. Каптырмасы була көмештән. Дәхи аңа асалар — көмештән ясаган чылбыры була. Ул чылбыр башларына көмеш тәңкә тагалар, һәркем хәленә күрә; яки, тәңкә булмаса, көмештән бертөрле нәрсә ясыйлар, челтәр дип әйтәләр...» Каюм Насыйри бу бизәнү әйберенең тарихы, каян килеп чыгуы хакында да уйлана һәм болгарлардан калуына ишарә ясый [3]. Бизәкләренең күп төрлелеге, композициясенең килешлеге, челтәрнең асылташ кашларыннан сирпелгән нурларының әледән-әле елкылдап китүе белән яка чылбыры чын мәгънәсендә гүзәл сәнгать әсәре була ала.


Шундый ук бизәнү әйберләреннән икенчесе — үзенең чыны белән шагыйрьләрне дә илһамландырганы — чәч чулпысы. Бизәгечнең үзәге итеп ике яньле челтәр алына, һәм аңа, бик килешле итеп, тәңкәләр тагыла. Челтәрләрнең рәвеше төрлечә булырга мөмкин, күбесенчә XVI—XVII гасыр ювелир әйберләренең формасы саклана. Кайбер челтәрләрдә гарәп хәрефләре белән бормалап-сырмалап язылган берәр изге теләкле сүз яки җөмлә дә булырга мөмкин. Баш бизәгечләреннән баш хәситәсе дип йөртелгән

---

[1] С. А. Авижанская, М. В. Бикбулатов, А. Г. Кузеев. Декоративно-прикладное искусство башкир. Рус телендә. Уфа. 1964 ел, 190 бит.

[2] А. Морозова. Машинная декоративная вышивка Узбекистана. Рус телендә. Ташкент. 1960 ел, 10 бит.

[3] Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Икенче басма. Казан. 1956 ел, 164 бит.




Чәч чулпысы.

әйбер дә филиграньлап, бик нәзек итеп эшләнеше белән игътибарны җәлеп итә.

Татар халык җырларында органик бер мотив булып кулланыла торган йөзекләрнең дә төрле-төрле техника белән эшләнгәннәре бар. Ирләр йөзеге гадәттә исемле була, ягъни аның кашына иясенең исеме, атасының исеме һәм кайсы авылныкы яисә шәһәрнеке булуы языла (мәсәлән, «Габдулла бине Мөхәммәтҗан әл-Казани»; «Сабирҗан бине Әхмәтгәрәй әл-Кышкари»). Мондый йөзек, кешенең шәхесен раслый торган мөһер (печать) буларак та кулланылып, юридик документларга да сугыла. Андый мөһерләрне иске китап битләрендә еш очратырга мөмкин.

Ахырдан татар ювелир әйберләрен эшләү өчен кулланылган материаллар һәм техник алымнар турында да берике сүз әйтеп китәсе килә. Асылташлардан күбрәк кызыл якут, ак якут, күк якут, фирүзә, гәрәбә һәм башкалар кулланылган. Асылташларны инкрустацияләү алымы бөтен бизәгечләрдә диярлек киң кулланыла. Асылташлар Казан, Мәкәрҗә, Эрбет һәм Минзәлә ярминкәләренә Уралдан китерелә торган булган. Металлардан көмеш, алтын, кургашын кулланыла. Аларга бизәгечнең тиешле формасын бирү өчен төрле техник алымнардан файдаланганнар: калыпка салып кою, чүкечләү, сызмалау, кискәләү һ. б.

Татар ювелирлык алымнарыннан, барыннан да бигрәк, игътибарны ф и л и г р а н ь җәлеп итә. Филиграньлап эшләнгән әйбер нәзек тимер чыбыклардан бәйләнгән челтәрне хәтерләтә. Башта юанрак тимер чыбыктан бизәгечнең кысасы эшләнеп, эче нечкә тимер чыбыклардан үрелгән спиральләр һәм йөгерек дулкыннарны хәтерләткән вак-вак бизәкләр белән тутырыла. Филигрань белән эшләнгән челтәр асылташлар белән инкрустацияләнә. Бу алымның «кабырчыклы филигрань» дип йөртелгән бер төре бар. Ул — татар ювелир сәнгатенең иң нәзек, зур осталык һәм түземлелек таләп итә торган бер алымы. Моны бик оста, югары квалификацияле ювелирлар гына башкара алган. Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, бу техник алым СССР халыклары ювелир сәнгатендә бары татарларда гына очрый.



Хәситә.

Филигрань бизәкләрендә гадәттә чәчәк саплары (сабаклары, яфракчыклары), бөреләр гәүдәләндерелә. Бу төр бизәгечләр сурәтенең килешлелеге, рельефлы булуы белән аерылып торалар. Ювелир әйберләрендә геометрик орнаментлар да очрый. Татар ювелир сәнгате әсәрләрендә очраган менә шундый орнаментика һәм техник эшләү алымнары халкыбызның гасырлар буе камилләшеп килгән иҗат осталыгын күрсәтә.

# Г. Иделлегә 60 яшь

## АЛТМЫШНЫ КАРШЫЛАГАНДА



Шушы декабрьнең 26 сында күренекле татар совет язучысы Газиз Иделлегә алтмыш яшь тула.

Алтмыш яшь! — Зур гомер һәм бай тормыш юлы. Әгәр дә инде бу зур гомернең яртысыннан күбе иҗатта узуын да искә алсаң, бик күп, бик күп киеренке көннәр, йокысыз төннәр, борчылулар, көенү-сөенүләр, яну-кабынулар кебек мең төрле иҗат ләззәте, иҗат газабы чигеп, ак кәгазь битләренә каләмең карасын йөгертеп кенә түгел, ә йөрәк каныңны салып та тудырган әсәрләреңне, аларның халыкка якты хисләр гүзәллеге һәм көрәш дәрте, искене җимерү, яңаны тудыру дәрте алып килү көчен дә күзалласаң, данлы бер хезмәт миссиясе бу.

Ә безгә, өлкән буын язучыларга, шуның өстенә, бер кулыңа каләм, икенче кулыңа автомат тотып, Маяковский әйткәнчә, «каләмне штыкка тиңләп», сугыш уты эчендә иҗат итәргә, илне дошман явыннан саклап калу кебек изге бер бурычны үтәргә дә туры килде.

Язучы Газиз Иделле дә үзенең алтмыш еллыгына әнә шундый иҗат һәм көрәш юлын үтеп керүчеләрнең берсе.

1915 елның зәңгәр аяз күкле яз башы булуын томанлы гына күзаллыйм, ә менә нинди көн иканлеген хәтерләү кыен. Тугыз-ун яшьлек балалар гына идек шул без ул язда. Нинди көн иде соң?! Әйтәм ич, ул көнне мин әле дә булса төгәл белмим, бары тик «Тукай кичәсе» итеп кенә хәтерлим, һәм ул көн миңа үзенең әнә шундый якты вакыйгага бәйләнештә булуы белән онытылмаслык та, изге дә...

Ул елларны Газиз (Габделгазиз) белән без, Әстерханның Бирге Тияк исемле эшчеләр бистәсенең ике малае, Камышлы мәчет мәхәлләсендәге «Дарельтәхсиль» мәдрәсәсенең тырыш шәкертләре булып саналабыз. Бездән дә тырыш, бездән дә сәләтлерәк, «әфтиякне су кебек эчкән» өченчебез дә бар — Габдрахман Мәгъҗәнев. Әдәби псевдонимы Мәгъҗән Эсперантский. Бәхетле очрактан файдаланып, бу исемгә, җәяләр эченә алып булса да, тукталып узасы килә. Әдәбиятка бездән алдарак, 20 нче еллар башында аяк басып, «Кызыл шарык яшьләре» журналы битләрендә хикәяләре белән танила башлаган талантлы замандашыбызның тормыш юлы бик кыска булды. Капитализм шартларында ярлы семьяда туып үскән һәм шуның социаль фаҗигасенә яшьләй дучар булган бу егет 1923—1924 елларда Казан комвузында укып-үсеп барган көннәрендә үпкә авыруыннан үлеп китте һәм бары тик «Алар соңгы мәртәбә җиңелделәр» исемле бер җыентыгын гына дөньяга чыгарып кала алды.

Без, бер бистәнең өч малае, менә шул Тукай кичәсендә таныштык, тагы дөресрәге, шул якты кичә таныштырды безне. Таныштырып кына да калмыйча, киләчәкнең бер уртак юлыннан атлап китәчәк өч яшүсмернең балаларча саф күңелләрендә әдәбият атлы сихри гүзәлгә беренче мәхәббәт чаткыларын кабызды...

Әле дә хәтеремдә... Мәдрәсә ялт иткән. Шәмдалләрдә бик күп шәмнәр яндырылган. Шул шәмнәрнең исе әле дә борын очында гына эленеп тора кебек һәм шул миңа бик ерагта, балачак көннәрендә калып онытылган кайбер детальләрне хәтерләргә ярдәм итә. Мәсәлән, шигырь уку... Ялгышмасам, без өчебез дә Тукай шигырьләрен яттан укыдык, аннары мәдрәсәбез белән «Туган тел»не җырладык...

Мэнә хәзер дә шул җыр, искә төшүгә, колак төбендә яңгырый да башлады, һәм бу яңгыраштa балачак дусларымның тавышларын ачык ишетәм төсле...

Әйе, әдәбиятның телисең икән, син чал чәчләне еллар артында калган балачагыңа, телисең икән, хыялың күгендә, сузылып җитә алмаслык биеклектә балкыган киләчәгеңә очыртып алып бара торган, канатландырып илтеп җиткерә торган шундый бер хикмәтле көче бар!.. Әнә шул көч — әдәбиятка мәхәббәт көче — мәдрәсәдә башлангыч белем алып, аннары рус-татар мәктәбен тәмамлаган 18 яшьлек Газизне зур тормыш юлына канатландыра. Егетнең хыял күге аяз. Кулындагы фанер чемоданы буш булса да, күңеле гаҗәеп бай аның — мең төрле берсеннән-берсе кызыктыргыч, берсеннән-берсе дәртләндергеч теләкләр, теләкләр, теләкләр...

Ләкин күңелең никадәр гына әйбәт теләкләргә бай булмасын, канатларың никадәр генә көчле җилләнүчән булмасын, тормышта теләгеңә ирешүнең туры гына, ансат кына илтеп куя торган такыр юлы булмый. Мондый юлны тырыш хезмәтең, кыенлыклар алдында чигенеп калмаслык ихтыяр көчең һәм нык ышанычың белән үзеңә салырга кирәк. Газизгә дә, «әдәбият мәккәсе» — Казанга килү өчен, башта Урал якларында, Уралның индустриаль үзәге булган Свердловск шәһәрендә укырга, эшләргә, кыскасы, чарланырга туры килә.

Газиз 1923—1926 елларда Свердловскиның индустрия техникумында укый һәм ул елларда Свердловскида чыга торган «Сабан һәм чүкеч» газетасы белән «Шәпи агай» журналында корректор булып эшли. Шул чорда аның беренче фельетоннары, хикәяләре языла. Редакциядәге иптәшләр яшь каләмдәге емет чаткыларын тиз күреп алалар һәм аңа, газета чыгудан вакытлыча туктап торган арада, Казанга баруны мәслихәт күрәләр. 1926 елда Газиз Казанга килә.

Казан.

Барысы да яшь монда. Кая карама яшьлек, яшьлек, яшьлек. Такташ та яшь, Сәйдәш тә яшь, Кутуй әле комсомол яшеннән дә чыкмаган, шуңадыр, ахрысы, шәһәр күләмендәге әдәбият түгәрәге дә «Яшь язучылар түгәрәге» дип исемләнгән, һәм атна саен «Кызыл яшьләр» газетасы, ай саен «Авыл яшьләре» журналы чыгып тора. Яшь язучылар, җылы вак яңгыр астында чәчрәп чыккан гөмбәләрдәй, туып кына тора. Бер Усмановлар гына да өчәү: Шамил Усманов, Хатип Усманов, Таһир Усманов һәм мәнә тагын бер Усманов — Газиз Усманов та килеп керә.

Әле дә хәтеремдә. Казанда укып эшләгән көннәребездә без, ике якташ, еш кына очрашып, әдәби темаларга әңгәмәләр алып бара торган идек. Мин инде бу чагында беренче хикәяләрем белән «Авыл яшьләре», «Безнең юл» журналлары битләрендә күренгәли дә башлаган яшь язучы. Әнә шундый бер очрашуыбызда Газизнең «Икмәк һәм хатын» исемле хикәясен бергәләп укып чыктык. Хикәя әйбәт иде. Киңәштек тә, хикәяне «Безнең юл»га тәкъдим итәргә булдык. Мәнә шунда инде «Безнең юл»ның редакторы тәнкыйтьче Гомәр Гали, хикәяне хуплап каршыласа да, әдәбиятка дүртенче Усманов фамилиясе кушылуын бик үк хупламагандай итә.

— Өчәү бер хәл әле ул. Әнә, театрда Камаллар да өчәү генә бит... «Камал дүртенче», «Камал бишенче» була алмый, — диган.

Нишләргә?

Шулай бер көнне Газиз белән шагыйрь Кутуйда утырганда, хәлне аңа сөйләдек. Үзенең тапкырлыгы белән танылган Кутуй да, «Усманов дүртенчене» өнәп бетермичә, берәр әдәби псевдоним табу фикерен әйтте. Һәм шунда ук, эзли торгач, Иделле псевдонимы туа.

— Үзе әйбәт, аңлаешлы, җиңел дә... Аннары сез Идел буе егете бит әле! — дип дәлилләгән иде Кутуй ул чагында моны.

Шулай итеп, әдәбиятыбызда хикәяләре, үткен публицистикасы, ә соңрак патриотик драма әсәрләре белән язучы Газиз Иделле үзенең иҗат эшчәнлеген җәеп җибәрде.

Газиз Иделле, барыннан элек, реалист язучы. Аның иҗатына хас төп сыйфат — реализм көче. Вакыйгаларны кешеләр язмышы белән бергә үреп гел үсештә, көрәшбәрелештә тасвирлаган реализм көче! Автор бу тасвирлауда, фотографларча, тышкы портрет сурәтләү методы белән эш итми, киресенчә, ул вакыйга үзәгенә кешене куя һәм аның эчке дөньясына юл таба. Шул рәвешчә, тегe яки бу әдәби образның психологиясе белән аны чолгап алган социаль мотивлар берлеген һәм шуның тормышча логикасын ача, художество чаралары белән күрсәтеп бирә. Бу яктан аның «Рәуфнең

балачагы» хикәясе аеруча характерлы. Бу хикәяне тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Хикәядә капитализм шартларында кешенең һәлакәте котылгысыз булуы, бу һәлакәтнең бик күп төрле юллары, шуларның берсе һәм иң хәтәре — эчкечелеккә сабышу юлы күрсәтелә. Шунысы характерлы, автор бу һәлакәттән котылу чарасын эчкечелеккә каршы көраш белән генә чикләнмичә, ә шуны тудырган капитализмның үзен юк итү проблемасын күтәрә, шуңа өнди.

Язучының иҗатында үз заманы киң урын ала. Аеруча 20—30 еллар хәрәкәте фонында язылган «Ерак Чытырманлыда», «Комсызлык», «Сәҗидәкәй» кебек хикәяләре бүгенге яшьләр өчен шул узган елларны күзаллауда, өйрәнүдә чын мәгънәсендә кыйммәтле бер художество әсәрләре булып торалар.

Газиз Иделленең совет чынбарлыгыннан илһамланып язган кайсы гына әсәрен алма, син анда, барыннан да элек, социализм төзүче кешеләрне, аларның көрәшләрен күрәсең. Бу яктан алганда, аның «Дәүләт Бәдриев» пьесасы аеруча бер этап әсәре булып тора.

«Дәүләт Бәдриев» пьесасы — Татар академия театрының совет тематикасына куелган күп санлы әсәрләренең иң яхшыларыннан берсе. Вакытында аны тәнкыйть тә, тамашачы да шулай бәяләде. Бу әсәрдә автор, кире образлардан Сәфәргали, Баязит кебек дошманнарны фаш итү белән бергә, эшчеләр арасыннан күтәрелеп чыккан большевик җитәкче Дәүләт Бәдриев образын иҗат итә. Җиңел баручы социализм төзелеше шартларында күтәрелеп үскән комсомолка Нәфисә, асраулыктан инженер булуга ирешкән Шәмсия кебек совет яшьләренең алдынгы вәкилләрен тудыра.

Газиз Иделле, язучы буларак, тормыш-эш практикасыннан аерылып иҗат итү белән берничек тә килешә алмый. Ул үзенең әдәби-җәмәгатьчелек эшчәнлеген үстерә бара. Ул «Безнең юл», «Атака» журналларында секретарь һәм «Совет әдәбияты» журналында редактор булып эшли. 1930—40 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп, дивизия газетасы редакторы вазифасына күтәрелә. Ә инде Бөек Ватан сугышы елларында Беренче Украина фронтында иҗади командировкада була. «Ватан намусы өчен» газетасында эшли һәм «Җиңү юлы» җыентыгын төзүдә катнаша. Шул ук елларда ул партия өлкә һәм Үзәк Комитетының пропаганда группаларында эшли. «Кызыл Татарстан» редакциясендә бүлек мөдире, Татрадиокомитетта баш редактор була. Соңгы елларда ул, озак вакыт, язучылар союзының партия оешмасында, правлениесе составында эшли, «Үсү юлы» альманахының редакторы вазифасын үти.

Газиз Иделленең яшь язучыларга күрсәткән ярдәме дә зур гына.

Газиз Иделленең иҗат эшчәнлеге күп кырлы. Ул язучы да, журналист та, тәнкыйтьче-рецензияче дә, тәрҗемәче дә, әдәбиятны өйрәнүче дә. Әле шушы 1965 елда язучының татар әдәбиятының күренекле каләм осталары иҗатын тикшерүгә багышланган «Язучы һәм аның китабы» исемле хезмәте аерым китап булып басылып чыкты. Бу китап әдәбиятны өйрәнүчеләр, әдәбият сөючеләр һәм шулай ук башлап язучылар өчен кирәкле бер кулланма була алырлык хезмәт.

Әйе, Газиз Иделлегә алтмыш яшь! Бер карасаң, картлык яше бу. Пенсиягә чыгар чак... Пенсиягә чыгып, җылы мич башына менәр чак...

Ләкин Газиз андыйлардан түгел. Чөнки мин бу алтмыш яшьлек якташны бал[...] чагымнан беләм. Аннары, моны Газиз Иделленең бүгенге эшчәнлеге дә ачык күрсә[...] Дөрес, ул менә шактый вакыт инде йөрәгеннән зарлана. Зарлана, сыкрый, әмма [...] хәрәкәттә үзе, редакторлык итә, рецензияләр яза, нәшриятка булыша, тәрҗемә[...] эшли... Театрның быелгы сезоны ул тәрҗемә иткән пьеса белән башланып китте [...] «Социалистик Татарстан» газетасы битендә бу спектакльнең уңышлы үтүенең сә[...] ләреннән берсе итеп Газиз Иделле тәрҗемәсенең югары сыйфатлы булуы әйтеп у[...] ды. Ә өстәлендә карасы кипмәгән һәм тиз генә кибәр төсле дә күренмәгән каләм[...] газь, башланган эшләр, тәгәлләнәсе әсәрләр, кыскасы, эш, эш, эш...

Алда яңадан-яңа эшләр, яңадан-яңа теләкләр, яңадан-яңа очрашулар... [...] бернечә көннән елыбызның да яңасы — 1966 сы башланып китәр. Шуңа к[...] үзенең алтмыш беренче яшен яңа — 1966 ел башларында каршылаучы ка[...] дустыбызны яңа ел белән дә котлыйсы килә.

— Яңа ел белән, яңа уңышларга таба, Газиз!

*ГАБДРАХМАН МИ[...]*

# Китап күзәтү

## ТАТАР СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ РУС ТЕЛЕНДӘ

Татар әдәбияты тарихы рус телендә! Зур кызыксыну уятырлык, гыйбрәтле һәм шатлыклы факт бу. 37 басма табактан гыйбарәт зур күләмле бу хезмәтне матбугат өчен СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих, А. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтлары коллективлары хәзерләгән[1]. Тарих китабының авторлары Казан институтының фәнни хезмәткәрләре Г. Халит, Б. Гыйззәт, Р. Башкуров, Х. Хәйри, Н. Гыйззәтуллин, Х. Хисмәтуллин, В. Воздвиженский һәм башка иптәшләр. Эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан яңа басма 1960 елда татар телендә чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы» (очерклар) китабын хәтерләтә. Шулай да бу яңа басма элеккеге татарча басманы кабатламый, фәнни материалның бирелеше һәм күләме буенча, ул үзенә башка, мөстәкыйль хезмәт.

«Татар совет әдәбияты тарихы» обзорлардан һәм монографик бүлекләрдән тора. Обзорларда әдәби процесс күзәтелә, монографик бүлекләрдә күренекле язучыларның иҗаты карала.

Китапның башында Октябрьга кадәрге татар әдәбиятына багышланган шактый зур кереш бирелгән. Бу бүлек әдәби процесска хас эзлеклелекне, социализм эпохасы әдәбияты белән элеккеге алдынгы әдәбият арасындагы бәйләнешне, традицияләр бергелгән күрергә ярдәм итә. Хезмәтнең беренче бүлеге егерменче еллар татар совет әдәбиятына багышланган. Икенче һәм өченче бүлекләрдә социалистик төзелеш һәм Бөек Ватан сугышы чорларындагы әдәби тормыш анализлана. Азакккы, дүртенче бүлектә сугыштан соңгы әдәбиятның яңа югарылыкларга юл алуы, күтәрелүе күрсәтелә. Совет әдәбиятын әнә шулай чорларга һәм этапларга бүлеп өйрәнү — безнең әдәбият белемендә күп хезмәтләрдә уңышлы кулланылган фәнни принцип. Рус, украин, белорус, чуваш һәм кайбер башка тугандаш халыкларның әдәбиятларына караган китаплар да шул принципка корылганнар.

Тикшерелә торган басманың тышкы структурасында чагылыш тапкан тарихилык принцибы аның эчтәлегендә, анализда, аерым язучыларның иҗатларына караган күзәтүләрдә тагын да ачыграк, тулырак сизелә. Инде әйтеп киткәнебезчә, беренче бүлектә 1917—1929 еллардагы әдәби хәрәкәт карала. Егерменче еллар — күп милләтле совет әдәбияты тарихында тирән эзләнүләр, иҗат кыенлыклары һәм идея чыныгуы белән аерылып торган авыр этап. Бу чорда совет әдәбияты формалаша, аякка баса, аның алга барышын тоткарлаучы киртәләрне җимерә-җимерә, социалистик реализм юлына чыга. Без искә алган бүлектә әдәби процессның әнә шул үзенчәлеге, дәлилле фактлар мисалында, тормыш позициясеннән торып карала. Бүлекнең гомуми обзор өлешен һәм поэзия белән проза турындагы махсус бүлекчәләрне Г. Халит язган. Ул үз алдында торган авыр иҗади бурычны тулысынча диярлек уңышлы үтәгән. Аның тасвирлавында егерменче елларның әдәби тормышы укучы алдына үзенең күп төрле һәм каршылыклы күренешләрендә, хәрәкәттә килеп баса. Обзорларда әдәби процессның ачыклауны сорый торган күләгәле яклары читләтеп үтелми, автор шул чорда калкып чыккан әдәби төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтнең характерын, төрле группалар тарафыннан алга сөрелгән концепцияләрнең асылын ачарга (футуризм, имажинизм, «Сулф», «Октябрь» һ. б.), татар әдәби тормышында аларның үзенчәлекле гәүдәләнешен күрсәтергә тырыша, милләтчелек идеологиясенең зарарлы йогынтысына каршы көрәшнең әһәмиятенә туктала.

Укучы М. Гафури, Г. Камал, Г. Ибраһимов, Ш. Камал кебек өлкән буын әдипләрнең катлаулы революцион чынбарлык шартларында үз урыннарын социалистик көрәшкә күтәрелгән халык массалары арасында табуларын һәм зур дәрт белән яңа, социалистик культураны, сәнгать һәм әдәбиятны төзү эшенә керешүләрен күрә, гражданнар сугышы утында идея-политик

[1] История татарской советской литературы. «Наука» нәшрияты. Мәскәү. 1965 ел.

чынгу үткән яшь талантларның ашкынулы, пафоска бай эшчәнлеге белән таныша. Шул рәвешчә, социалистик эчтәлекле татар милли әдәбиятының барлыкка килүендә, аның формалашуында Бөек Октябрь социалистик революциясенең, ул тудырган яңа совет чынбарлыгының хәлиткеч роле ачыла.

Егерменче еллар әдәбияты турындагы обзор бүлекчәләренең соңгысы драматургиягә багышланган. Бу обзор да яхшы тәэсир калдыра, татар драматургларының яңа совет театрын һәм драматургияне тудыру буенча эшләгән эшләре, аларның омтылышы, кыю эзләнүләре белән таныштыра. Обзорның К. Тинчурин, Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, М. Фәйзи, Ф. Бурнаш һәм Ф. Сәйфи-Казанлы әсәрләренә багышланган битләре зур кызыксыну белән укыла, драматургиянең төрле жанрларында социалистик реализмның төрле дәрәҗәдә гәүдәләнеш табуы, тарихи драмаларда критик реализм элементларының өстенлек алуы бик урынлы, дөрес искәртелә. Тикшерүче игътибарыннан театр тормышы да читтә калмаган. Берникадәр алга китеп, шуны әйтә алабыз: драматургиянең үсешен театр сәнгатенә бәйләп тикшерү башка бүлекләрдә дә эзлекле сакланган һәм бу уңышлы алым.

Моннан 60 ел элек «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле атаклы мәкаләсендә В. И. Ленин социализм җәмгыятендәге азат әдәбият турында язды, аның чын-чынлап халыкчан сәнгать булачагын искәртте.

Октябрьдан соңгы татар әдәбиятының ярты гасырга якын үсеш юлын күзәтү Ленин әйткән хакыйкатьнең дөреслеген раслый. Китапның социалистик төзелеш чоры әдәбиятына багышланган обзор өлешләрендә, аларга органик килеп өстәлә торган башка обзорларда илебездә социализм тантанасы шартларында әдәбиятыбызның югары идеяле, яңа сүз сәнгате булып формалашуы, социалистик реализм әдәбиятының җиңүе күрсәтелә. Әдәбиятның эчтәлегенә һәм милли формасына хас үзенчәлекләр, илебездәге иҗтимагый обстановкага нисбәтле, социализм өчен көрәш актылыгында, вакыйгалар эволюциясенә бәйләнешле каралалар. Кыскасы, әдәбиятка заман, тормыш йогынтысы истә тотыла. Авторларның уңышы (Н. Гыйззәтуллин, Р. Башкуров, Б. Гыйззәт, Х. Хисмәтуллин һәм Х. Хәйри иптәшләр), безнеңчә, әдәби процесска әнә шулай тарихи якын килә белүләрендә.

Совет әдәбиятында киң чагылыш тапкан р е в о л ю ц и я, г р а ж д а н н а р с у г ы ш ы, с о ц и а л и с т и к х е з м ә т темаларын алыйк. Әдәби үсешнең төрле этапларына караган әсәрләрдә бу темаларның яктыртылышында күренгән аермалы яклар, яңалык авторлар игътибарыннан читтә калмый, аның сәбәпләре аңлатыла. Яңа кеше, уңай герой проблемасы социалистик реализм әдәбиятының төп проблемаларыннан санала. Бу проблеманы хәл итүдә авторлар, фән эшендә нивелировкага китерә торган коры дәлилләү юлын кире кагып, яңа кеше образының сурәтләнешен әдәбиятта тупланган тәҗрибәгә, әдәбиятның проблематикасына бәйләнешле тикшерәләр. Бу исә уңай герой образының әдәбияттагы эволюциясен, язучыларның иҗат казанышларын күрүне җиңеләйтә һәм, тагын бер тапкыр, тарихилык принцибының өстенлеген раслый.

Китапта совет әдәбиятын үстерүдә Коммунистлар партиясенең җитәкчелек роле эзлекле яктыртыла. Әдәби тормыштан алынган җанлы фактлар мисалында культура мәсьәләләре буенча В. И. Ленин чыгышларының, 1925 елгы РКП(б) Үзәк Комитеты резолюциясенең «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңабаштан кору турында» ВКП(б) Үзәк Комитеты карарының, башка шундый документларның язучылар иҗатына, әдәби үсешкә уңай йогынтысы күрсәтелә.

Әдәби процессны күзәткәндә, авторлар андагы күләгәле якларны, язучылар иҗатындагы кимчелекләрне читләтеп үтмиләр. Классик мираска мөнәсәбәттә вульгар-социологизмның зарары күрсәтелә, уңай герой образын сурәтләүдә натурализмга тайпылыш, вак темалар тирәсендә тапталу, поэзиядә бернинди дифференциациясез романтизм традицияләрен кире кагу, кайбер драматургларның формализм йогынтысына бирелүләре, 30—40 еллар әдәбиятына шәхес культының зыяны дәлилле тәнкыйть ителә. Авторлар үткәндәге әдәби тәнкыйтьнең тәҗрибәсен, андагы казанышларны һәм ялгышларны да игътибардан читтә калдырмаганнар. Анализ барышында Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Сәгъди, М. Җәлил, Г. Кутуй һ. б. авторларның критик хезмәтләре китерелә һәм тәнкыйть карашыннан чыгып бәяләнә. «Совет әдәбияты тарихы»нда бик күп әдипләрнең — шагыйрьләрнең, прозаикларның һәм драматургларның иҗатына урын бирелә. Китап белән танышу нәтиҗәсендә укучы Г. Камал, Ш. Усманов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Толымбай һәм хәзерге каләм мастерлары турында җитәрлек белешмә ала. Бу исә совет әдәбиятын үстерүдә куплэгән талантлардан торган язучылар коллективының хәлиткеч ролен раслый.

Совет әдәбиятының үсеш процессын, аның конкрет күренешләрен яхшырак күзаллауда, обзорлар белән беррәттән, аерым язучылар иҗатына багышланган монографик бүлекләрнең дә әһәмияте гаять зур. Г. Ибраһимов, М. Гафури, һ. Такташ, М. Җәлил һ. б. күренекле татар совет язучылары турындагы бу бүлекләр әдәбиятыбызның бер-берсеннән нык аерылып торган зур талантларга байлыгын күрсәтүләре, төрле стиль иясләренең, род һәм жанр вәкилләренең эшчәнлеген характерлаулары белән игътибарга лаеклы. Моңа басманың эчтәлегенә туры килә торган фәнни-әдәби жанр сайлап алу ярдәм иткән булса кирәк. Монографик бүлекләр язучының иҗат портреты рәвешендә төзелгәннәр. Арада аеруча зур кызыксыну белән укыла торганнары — Г. Ибраһимовка һәм М. Җәлилгә багышланганнары.

Шуның белән бергә, монографик бүлекләрнең сан ягыннан бик аз булуларын да билгеләп үтәргә кирәк. Бүгенге күренекле язучыларыбыз турында бер генә монография дә булмау, ничектер, сәер тоела. Бөек Ватан сугышы беткән көннәрдән алып хәзергә кадәрге чор күп милләтле бөтенсоюз әдәбиятының яңа, зур үсеш этабы булып тора. Бу этап татар әдәбиятының халыкара әһәмияте, роле арту белән характерлы. Безнең әдәбият хәзер бөтенсоюз һәм дөнья аренасына күтәрелеп килә. Моның сәбәбен, беренче нәүбәттә, әдәбиятыбызның идея-художество сыйфаты үсү белән аңлата алабыз. Татар әдәбиятының гомумкешелек, интернациональ әһәмиятен үстерүдә хәзерге заман каләм осталарыбызның, аеруча прозаикларыбызның, роле бәхәссез. «Совет әдәбияты тарихы»нда Г. Бәширов, И. Гази, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Х. Туфан, Н. Исәнбәт, С. Хәким, Р. Ишморат һ. б. күренекле прозаиклар, шагыйрьләр һәм драматурглар иҗатының әһәмияте билгеләп үтелсә дә, бу эш, ничектер, артык тыйнак, констатация һәм гомуми характеристикалар рәвешендәрәк эшләнгән. Хәзерге өлкән мастерларыбызның новаторлыгына, метод, стиль, проблематика һәм жанрлар өлкәсендәге казанышларына акцентация көчлерәк ясалса, безнеңчә, отышлырак булыр, ул чакта әдәбиятыбыздагы яңалык тагын да ачыграк күренер иде.

Үз вакытында, татар telендә чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы»на язылган рецензияләрдә авторларның әдәбиятның спецификасына, әдәби осталык мәсьәләләренә игътибар биреп бетермәүләре күрсәтелгән иде. Хәзерге русча басмада художестволылык проблемасы әдәби анализның аерылгысыз ягы булып тора. Укучы китапта әдәби осталык турында уйлануларга этәрүче оста тотып алынган нечкә күзәтүләр, канәгатьләнү хисе уята торган нәтиҗәләр белән очраша. Шундыйларга гражданнар сугышы һәм егерменче еллар чоры поэзиясенең поэтикасы, Г. Камал, М. Гафури, һ. Такташ иҗатларының художество үзенчәлекләре, К. Тинчурин драматургиясендә сатираның функциясе, 30 еллар әдәбиятының стиле һәм жанрлары, әдәби характер, психологизм турындагы күзәтүләрне кертергә кирәк. Безнеңчә, болар барысы да авторларның активына язылырга тиешле казаныш. Хезмәтнең монографик бүлекләрендә әдәби осталыкка игътибар тагын да ачыграк күренә. М. Җәлилгә багышланган бүлектә шагыйрьнең идея-эстетик, художество эволюциясе, Моабит шигырьләренең поэтикасы турындагы тапкыр күзәтүләрне аерым рәвештә билгеләп үтәсе килә. М. Гафури әсәрләрендә антитеза белән аллегориянең роле, һ. Такташ поэзиясендә лирик герой образының поэтик функциясе дөрес билгеләнгән. «Язгы җилләр» романының композициясенә хас үзенчәлекләр дә матур күрсәтелгән. Кызганычка каршы, тарихи революцион романның хәзерге безнең әдәбиятта принципиаль казаныш булуы, андагы социалистик реализмның гәүдәләнешенә, жанр һәм сюжетикага хас үзенчәлекләр авторлар игътибарыннан читтә калган. Бу, мөгаен, югарыда әйтеп узылганча, хәзерге әдәбият турында авторларның киң җәелергә теләмәүләре белән бәйләнгәндер.

Билгеле булганча, язма әдәби традицияләре булган халыкларда социалистик реализмның формалашуы критик реализм тәҗрибәсе, классик традицияләр белән бик нык бәйләнгән иде. Бу момент «Әдәбият тарихы» китабында кат-кат, бик урынлы һәм дөрес акцентацияләнә. Шуңа карамастан, татар язучыларының Октябрьдан соң язылган кайбер әсәрләрендә критик реализмның метод буларак кулланылуы турында берни әйтелми. Бу, әлбәттә, авторлар ирке; өзеп әйтү, бәлки, урынсыздыр. Әмма, безгә калса, М. Гафуриның «Эшче», «Кара йөзләр» әсәрләрендә, Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда, тарихи үткәнгә багышланган кайбер башка хикәя, повесть һәм пьесаларда критик реализмның метод буларак кулланылуы турында сөйләргә ярар иде.

Татар совет әдәбияты тугандаш әдәбиятлар белән дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен торган саен ныгыта бара, үз үсешендә аларның ярдәменә таяна. Татар язучыларының рус әдәбияты белән бәйләнеше — күптәннән килә торган гүзәл традиция. Безнең авторлар, татар поэзиясенә, проза һәм драматургиягә милли классик традицияләрнең зур йогынтысын констатацияләү белән беррәттән, рус әдәбиятының уңай ролен күрсәтүгә зур игътибар биргәннәр. Китапта М. Горький, В. Маяковский, Д. Бедный, С. Есенин, А. Твардовский, М. Исаковский, М. Светлов, В. Лебедев-Кумач кебек күренекле рус каләм осталары традицияләренең татар әдәбиятында чагылышы, поэзия һәм проза, драматургия үсешенә ярдәме күзәтелә. А. М. Горькийның татар язучылары белән дуслыгы, аның татар әдәби көчләрен туплаудагы роле турында басым ясап әйтелә. Татар поэзиясен русчага тәрҗемә итүдә С. Маршак, С. Липкин, Л. Мартынов, Я. Смеляков, М. Луконин һәм башка рус совет шагыйрьләренең эшчәнлеге билгеләп үтелә. Болар барысы да хезмәтнең фәнни-теоретик, идея дәрәҗәсен күтәрәләр. Тик, сүз уңаенда, шуны әйтми булмый. Татар язучыларының иҗат элемтәләре элек-электән күпкырлы булып килде. Хәзер дә алар башкорт, казакъ, төркмән, кыргыз, башка тугандаш халыкларның әдипләре белән тәҗрибә уртаклашып яшиләр. Әдәби хезмәттәшлекнең әнә шул ягы «Совет әдәбияты тарихы»нда йомшак тасвирләнә. Фактта, эш организацион характердагы вакыйгаларны искә алудан арыга китмәгән.

Күп милләтле бөтенсоюз әдәбиятын пропагандалау, татар язучыларының тәрҗемә өлкәсендәге зур эше турында да фактларны теркәү, санап чыгу рәвешендәрәк кенә сөйләнә. Бу эшнең әһәмияте һәм характеры җитәрлек билгеләнми.

Китап турындагы фикерләребезне йомгаклау алдыннан, аны матбугатка хәзерләгән коллектив адресына, редколлегия белән редакторларга берничә җылы сүз әйтәсе килә. Китапта капиталь фәнни хезмәт-

ләргә хас традиция исәпкә алынган. Укучы басманың азагында илле елга якын вакыт эчендә булып үткән датаrange эчендә булып үткән даталарны эченә алган әдәби тормыш хроникасы, татар совет әдәбияты буенча фәнни хезмәтләр библиографиясе һәм исемнәр күрсәткече белән таныша ала. Алар фәнни материалны инләүдә укучының ориентациясен җиңеләйтәләр. Басманың редакторлары В. Воздвиженский, Л. Залесская, З. Кедрина һ. б. иптәшләр кулъязмаларны эшкәртү, стиль бирлеген тәэмин итү буенча зур тырышлык күрсәткәннәр. Китап киң катлау укучыларга аңлаешлы, әдәби телдә язылган, яхшы иллюстрацияләнгән.

Башта ук әйтеп узылганча, «Татар совет әдәбияты тарихы»ның рус телендә басылып чыгуы — бөтенсоюз культура тормышы масштабында куанычлы факт, зур фәнни казаныш. Ул әдәбият белеме өлкәсендә эшләүче галимнәребезнең өлгергәнлеген, җаваплы бурычларны хәл итәргә сәләтле булуларын, фәндә коллектив тырышлыкның зур файдасын раслый. Китап илебездәге тугандаш халыклар арасында культура бәйләнешләрен, дуслык мөнәсәбәтен ныгыту, күп милләтле совет әдәбиятын яхшырак өйрәнү эшенә хезмәт итәчәк.

*А. САЙГАНОВ.*

# «ХӘСРӘТ ДӘРЬЯСЫ»ның ТАТАРЧАСЫ һӘМ ТӘРҖЕМӘ ПРАКТИКАБЫЗ ТУРЫНДА

Матбугат битләрендә әдәби тәрҗемә хакында мәкаләләр басылмады дип әйтеп булмый. Заманында И. Гази, С. Әдһәмова, мәрхүм М. Максуд, үзләренең күп еллык иҗат тәҗрибәләре белән уртаклашып, тирән эчтәлекле берничә мәкалә бастырганнар иде. Ләкин ул мәкаләләр басылганнан соң да ун еллап вакыт узды инде. Һәм бездә байтак кына талантлы яңа тәрҗемәчеләр үсеп чыкты. Н. Фәттах, Я. Халитов, Қ. Миңлебаев, С. Сабиров, Р. Гайнанов һәм башкалар әдәби тәрҗемә практикасына яңа эзләнүләр, яңа алымнар алып килделәр. Димәк, эшләнгән эшебезгә берникадәр йомгак ясарга да вакыт җитте шикелле. Бу мәкаләдә мин, Кыям Миңлебаевның «Угрюм река»ны тәрҗемә иткәндәге эзләнү алымнарына тукталып, әдәби тәрҗемә принциплары турындагы кайбер фикерләрем белән уртаклашмакчы булам.

Вячеслав Шишковның «Хәсрәт дәрьясы»[1] — киң сулышлы әсәр, капитализм дәверендә Россия халыкларының кичергән газаплы авыр тормышны гаять зур колач белән сурәтләп биргән эпопея. Капитал дөньясының ерткыч табигатен автор бүре белән бер бүлмәдә яшәүче Прохор Громов образында сурәтли. Прохор сөйгәнен атып үтерә, мең бәладән коткарып калган иң якын дусты Ибраһимга нахак бәла ягып, аны сөргенгә озаттыра, хатыны Нинаны чәч пәкесе белән суярга керә, бер гаепсез эшчеләрне патша солдатларыннан аттыра. Бу әсәрдә үтерү-сую бар, байлык, алтын тудырган комсызлык, азгын, тук тормыш бар. Монда кырыс тайга, катлаулы язмышлар, җан тетрәнүләре бар, шуларның барысын бер төбәккә җыйган тормыш — хәсрәт дәрьясы бар. В. Шишков Россия капиталы тудырган мәрхәмәтсезлекне, аяусыз вәхшилекне кискен һәм усал тел белән — халыкның киң катлавыннан килә торган образлы, җанлы, дәһшәтле, — әгәр шулай әйтергә яраса — хәтта беркадәр дорфарак тел белән хикәяли.

Қ. Миңлебаев оригиналның әнә шул үзенчәлекләрен, тәэсир итү көчен татар укучысына ничек җиткерә алган?

Тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган бер мәкаләсендә күренекле рус язучысы һәм тәрҗемәче Николай Чуковский болай дип язган иде: «Әгәр син тәрҗемә итә торган әсәрнең авторы яшен яшьнәү күренешен укучының котын алырлык итеп сурәтли икән, син дә аны шулай сурәтлә, синең укучыңның да коты алынырлык булсын — бары тик шуның белән генә синең тәрҗе-

[1] В. Шишков. Хәсрәт дәрьясы. Ике китаплы роман. Қ. Миңлебаев тәрҗемәсе. Татарстан китап нәшрияты. 1963 ел.

мәңнең никадәр уңышлы икәнен бәяләп була» [1].

«Хәсрәт дәрьясы»нда Петр Громовның җиргә күмелгән хәзинәне эзләп табу күренешен искә төшерегез. Караңгы бер төндә, сибәләп яуган яңгыр астында, эт ияртеп, кулына фонарь тотып, Громов төпсез тайгага чума.

«...Ул әрәмәле чокырга төште, шаулап аккан су аша аргы якка чыкты. Монда сукмак юк иде. Юл авырлашты. Әрәмәлекне үткәндә, Петр кайсы якка барырга кирәклекне, бүре шикелле, сиземләп белде. Ул, караңгыда корыган чыбык-чабыкларны шатыр-шотыр сындыра-сындыра, турыга кыеп чыкты. Аның башы үтә тиз эшли, фикерләре гаҗәп кызу агыла. Әле гәүдәсе үсеп, җилкәсе киңәеп киткән кебек була, шул чагында аның күз алдына бай тормыш килеп баса: төшендә дә күрмәгән иркенлектә бөтен дөньяны шаккатырып яшәр иде, аны олылап быргы кычкыртырлар, чаң сугарлар иде. Әле хыялы төпсез упкынга төшеп китә: «сихерле сызык кебек булып йортны урап алган шул утыртма коймадан гомеремдә дә котыласым юк икән, раббем»,— дип уйлап ала да гәүдәсе янә бөрешеп, кечерәеп кала...» (Беренче китап, 11—12 битләр.)

Бу өзектән, бик төпченеп тикшерсәң, төзәтеп җибәрердәй берничә урынны табып була. Ләкин хикмәт анда түгел. Әсәрнең русчадагы хис бөтенлеге, драматик киеренкелек, Громовның комсызланып алтын эзләгәндәге кичерешләре төгәл сүзләр белән, аһәнле, тигез агышлы әйбәт тел белән тәрҗемә ителгән. «Хәсрәт дәрьясы»ннан мондый мисалларны күп китерергә мөмкин. Эшчеләр барагындагы хәерчелек, исереклек; зур бәйрәмнәрдәге шашкын типтерү; тайгадагы йөрәк яргыч пожар; Нижний Новгородтагы ярминкә һәм жуликлар тарафыннан таланган Прохор; аюлар үкерүе, еланнар сызгыруы һәм байгыш уфылдаулары белән күңелгә шом сала торган тайга төннәре, бер пот алтын юган саен гөрселдәтеп аткан туплар — болар барысы русчадагы эмоциональлеген, тормышчан кырыслыгын саклап тәрҗемә ителгәннәр.

Ләкин осталыкның чиге юк, диләр. Әнә шул ноктадан караган чакта, бер К. Миңлебаев өчен генә түгел, тәрҗемәгә азмы-күпме кагылышлы булган барыбыз өчен дә уйланырга тиешле кайбер нәрсәләр бар.

Зур елгалар һаман бертөсле генә акмыйлар. Аларның шаулап, баш түбән ташланган шарлавыклары, уймакланып бөтерелгән чоңгыллары булган кебек, бөтенләй тынып, уйга талып утырган камышлы тугайлары да була. Зур язучыларның әсәрләрендә дә, вакыйга барышына, кешеләрнең характерына, темпераментына карап, әсәрнең агымы үзгәрә. Зур художникларның, бәлки, зурлыгы да шундадыр, алар тормыш агымына, үсеш-үзгәрешләргә гаять дәрәҗәдә сизгер булалар. Шишковның сурәтләү алымы — чиркәс Ибраһимны тасвирлаганда уйнаклап торган җиңел; «мерикан немчурасы» мистер Кукның үз-үзен тотышын биргәндә гротескыга кадәр менеп җиткән саркастик ачы көлү; Громовларны сурәтләгәндә — имәннән юнып ясалгандай авыр һәм саллы. Хәер, Прохор Громовны сурәтләгән чакта да стиль үзгәрә. Үсмер Громов, саф күңелле, бер катлы Прохор, кояш нурларына, урман авазларына сөенә белә. Бу урында аның хисләре Себер тайгасының легендалары, хәсрәт дәрьясы өстенә сибелгән таңкә-таңкә ай нурлары белән үрелә, төнге пышылдаулар белән тулып ташы. «Сары шайтан» котырыгына бирелгән Прохорның исә күзләре ут булып яна, эшчеләрнең аһ-зарына, хәсрәтле сагышына аның исе дә китми. Бәйдәге бүре дә, ул да кеше хәсрәтенә тешләрен шакылдатып кына җавап бирәләр.

Әсәрнең лирик-романтик агымын, табигать авазларыннан һәм үсмер Прохорның күңел сафлыгыннан килгән урыннарны К. Миңлебаев русчадагы тәэсире белән үк тәрҗемә итә. Ерткыч Прохорга бәйле кырыс,

[1] Коллектив. Мастерство перевода. «Советский писатель» нәшрияты. Мәскәү, 1962 ел.

саллы, авыр картиналар да аңа әйбәт буйсыналар. Ә менә югары җәмгыять даирәләрен сурәтләгән бүлекләрдә әсәрнең эмоциональлеге русчасындагы кебек көчле яңгырамый. Башка урыннарда нык куллы, үткен сүзле тәрҗемәче бу урында, ягъни югаргы җәмгыять кешеләре алдында, гүя ки, каушап кала. Громов резиденциясендәге юбилей тантанасын алыйк. Шишков монда, минемчә, бер хакыйкатьне бик нык истә тоткан: Громов алтыны тирәсенә җыелган ак сөяк генераллар, губерна түрәләре, үзләрен дөньяның тоткасы дип санаган хаким кешеләр «югаргы штильдә», «благородный манерларда» сөйләшәләр. Әмма эшләгән эшләренә, кылган гамәлләренә караганда — алар бер тиен торгысыз буш куыклар, түбән җанлы, әдәпсез һәм тотнаксыз шарлатаннар булып калалар. Әнә шул капма-каршы ике төшенчәнең бергә кушылуыннан комедия туа.

«Чести быть приглашенным удостоился и Илья Петрович Сохатых»,— дип яза Шишков. Игътибар беләнрәк укысаң, кыска гына шушы бер җөмләдә дә зур мәгънә бар: автор үзенең хикәяләү алымын әлеге югаргы катлауның парадча купшылыгына, тантаналы манерларына якынлаштыра. Татарчасындагы: «Илья Петрович Сохатыхны да чакырганнар иде», — дигән җөмлә исә әлеге нәзакәтле даирәнең кыланышыннан, салон теленнән еракләша, бөтенләй гадиләшеп китә. Әсәрнең эчке агышындагы чак сизелердәй нечкәлекләр турында сүз башлаганбыз икән, ахыргача әйтеп бетерик инде. «Хәсрәт дәрьясы»ның икенче китабында Прохор Громовның акылдан шашуын сурәтләгән картина бар. Кайдадыр Прохор кабинеты белән янәшә Питер һәм Мәскәү коммерсантлары, алтын промышленниклары Громовның прискаларын алу турында киңәшмә үткәрәләр. Акылына зәгыйфьлек килгән Прохор да үз манарасында «киңәшмә» җыйган. Шкаф артларыннан, идән асларыннан аның янына коммерсантлар җыела: Прохорның исәр акылы чын киңәшмәдә катнашучыларның өрәкләре белән сөйләшә. Шул ук вакытта аның колагы урамда, күрше бүлмәдә ишетелгән реаль авазларны да тотып ала. Тик ул реаль авазлар инде тормыштагыча кискен, дорфа булып түгел, исәрнең тоныкланган аңында йомшартылып, нечектер, серле булып, томан эченнән ишетеләләр.

«...Звякнуло-брякнуло колечко» — диелгән русчасында (561 бит). Тәрҗемәче аны «...келә шакылдады» дип биргән.

Оригиналдагы «колечко» һәм «звякнуло-брякнуло» сүзләрендәге авазлар уйнатылуы шактый йомшак, серле булып, безне әллә кайчангы саф күңелле үсмер Прохор белән тоташтыралар; ә «келә шакылдады» бик коры, гади, табигый аваз булганга, тойгыларны еракка алып китә алмый.

Һәр телнең аңа гына хас үзенчәлекләре була. Татар теленең бик нык үскән көчле якларыннан берсе — ярдәмче фигыльләр. Татар теленең нечкәлекләрен озак еллар өйрәнгән тел галиме Фазыл Фасеев безнең телдә сүзләр унөч фигыльгә хәтле янәшә килә алуын һәм моның бик табигый хәл булуын исбат иткән иде. Тәрҗемә практикасында гаять мөһим бу фактны без кайвакыт истән чыгарабыз, шуңа күрә тәрҗемәдә телебезнең табигый агылышы, тәэсир итү көче кими. Тормыштан бер мисал китерәм. «Сукты» фигылен алыйк. Бу әле гамәлнең тынычрак башкарылуын белдерә. «Сугып җибәрде» булса, гамәл инде көчәя төшә. «Сугып торып җибәрде» — гамәлнең зурлыгын бөтен кискенлеге белән күз алдына бастыра.

Кыям Миңлебаев тәрҗемәсендә фигыльләр куллану, заманнар белән эш итү, нигездә, уңышлы башкарылган. «Петрның йөрәге каты гына бер тибеп алды да рәхәт кенә кысылып куйды, аннары тук-тук итеп, ашыгып-ашыгып тибәргә тотынды: менә көткән вакыт җитте, этисе аны череп чыккан бай итә». (Беренче китап, 9 бит.) Фигыльләр бу өзектә бик җайлы урнашканнар. «Йөрәге каты гына бер тибеп алды», «рәхәт кенә кысылып куйды» һәм, ниһаять, бер-бер артлы, янәшә,

шаулап килгән берничә фигыль — «тук-тук итеп, ашыгып-ашыгып тибәргә тотынды». Ә бит русчасында соңгы буын, ягъни янәшә килгән биш фигыль «быстро забилось» дип кенә әйтелгән. Русчада «ашкынып тибү»не бирү өчен шул ике фигыльдән башка берни кирәкми. Әгәр тәрҗемәче моны, сүз арттырудан куркып, бер тиенгә бер тиен рәвешендә «каты типте» дип кенә алган булса, русчадагы тәэсир бөтенләй югалып калган булыр иде. Русчада бу өзекнең соңгы җөмләләренә игътибар итик: «Наконец-то родитель в одночасье сделает сына богачом». Тәрҗемәче «наконец-то»ны ниһаять дип алмаган, «көткән вакыт җитте» дигән. Һәм әнә шул «көткән вакыт җитте»гә «одночасье» да бик әйбәт кереп урнашкан. «Сделает богачом»ны «бай итә» дип кенә калдырмаган, «череп чыккан бай итә» дип алып, бик дөрес эшләгән. Югыйсә укыганда авыз тулып җитмәс, оригиналда бик нык басым ясалган «богачом»ны без сизмичәрәк узып китәр идек.

Тәрҗемә ителә торган әсәрләрдә авторның үз хикәяләвен бирүдә безнең уңышларыбыз байтак. Өлкән буын тәрҗемәчеләрдән А. Шамов, М. Әмир, И. Гази, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Ш. Маннурның бай тәҗрибәләрен бүгенге тәрҗемәчеләребез өйрәнеп кенә калмадылар, Я. Халитов, Н. Фәттах, К. Миңлебаев иптәшләр бу өлкәдә оригинал рухын бирү ягыннан кысан-тыгызлыкка, оригиналдан читкә китмичә, «вакламыйча» эшләүгә кадәр үстеләр. Бу хакта әллә ни бәхәс куертып торуның кирәге юк. Ә менә персонаж телен, диалогларны биргән чакта бергәләп эшлисе, бергәләп киңәшәсе байтак нәрсәләр бар әле.

Аның беренчесе — рус әдәбиятына килеп кергән төрле милләт вәкилләренең сөйләме. «Хәсрәт дәрьясы»нда чиркәс Ибраһим сөйләвен тәрҗемәче аның үз телендәге элементларны катнаштырып, дөрес эшләгән.

— «Тфү, мылтыкка! Хәнҗәр сау болсун, шундан якын дост юк!..— дип сөйләнә-сөйләнә, чиркәс хәнҗәрен ялт-йолт уйнатты. — Капказ, төн уртасы, өйгә таба кайтам... Тау арасы, урман, ай. Күрәм — йолда ак кеше. Айтам китми, кычкырам — китми, тагы кычкырам — китми бит. Винтовканы салдым, атып җибәрдем — һич кузгалмады... Хәнҗәрне авызга кабдым, киттим шулай шуышыб. Барыб җиттим, кизенеб торыб кададым! Карыйм — ул кибереге элген катыннар күлмеги икен. Цых!» (Беренче китап, 7 бит.)

Кыям Миңлебаевның, иренмичә болкарлар телен өйрәнеп, шуны чиркәс Ибраһим теленә китереп кертүен, минемчә, тәрҗемәченең ансат юлдан китмәве, эзләнүе дип карарга кирәктер. Ләкин бу барлык тәрҗемәләр өчен бердәй яраклы, бердән-бер котылу юлымы? Ә менә Степан Злобинның «Салават Юлаев» романын татарчага тәрҗемә иткәндә нишләргә тиеш булабыз? Ярый ла, «Хәсрәт дәрьясы»нда чиркәснең сүзләре ул хәтле үк күп урын алмый. Злобин китабында Салават бит төп герой һәм аның сүзләре, китапның яртысын ук булмаса да, һәрхәлдә өчтән бер өлешен тәшкил итәләр. Бу очракта әлеге юл белән китсәк, тәрҗемә китабыбыз ярым татарча, ярым башкортча булып чыга түгелме соң?

Әйе, тәрҗемә өлкәсендә уйланасы, бергәләп хәл итәсе проблемалар байтак әле. «Тын Дон» романында Дон буе казакларына гына хас булган бик күп шивә сүзләр бар. Татар телендә дә әдәби тел нормаларыннан читкә киткән шивә сүзләр аз түгел. Урынчылык сөйләменең тәрҗемәчеләрне иң нык мавыктырганы — мишәр шивәсе. Ләкин бу юлдан китсәң, Дон казагына мишәр түбәтәе кидертү булып чыгар иде.

Персонажлар телен, диалогларны бирү татар тәрҗемәчесе өчен генә түгел, милли телләрдән тәрҗемә итүче рус тәрҗемәчеләре өчен дә хәзергә теш үтми торган каты чикләвек булып кала бирә. Менә шуңа күрә дә Г. Бәшировның «Намус»ы, Ф. Хөсни, Ә. Еники, И. Гази әсәрләре русча тәрҗемәдә оригиналдан төссезрәк булып чыгалар.

«Хәсрәт дәрьясы»нда бик күп төрле типлар һәм аларның үзләренә

генә хас, индивидуаль телләре бар. Ярым мужиктан күтәрелгән Прохор телен «патша җинаятьчесе» укымышлы Шапошников теле белән, салкын җанлы купец кызы Нинаның телен гаять нечкә табигатьле, тирән хисле Анфиса теле белән янәшә куя алмыйсың. Тайга сукбайлары Филька Шкворень һәм Тузик, шулер Приперентьев һәм урынлы-урынсыз фәнни терминнар кыстырып сөйләүче мәзәк Илья Сохатых, патша көчәге — исправник Амбреев һәм урядник, чатлы-ботлы сүзләргә, тормыштан килә торган зирәк акылга бай эшчеләр теле яки шуңа капма-каршы югары җәмгыять теле... Өстәвенә йөз еллар буена аерым юнәлештә чарланган дин әһелләре, изге китаплар теле. Яки рус-часы җимерек мистер Кук, пан Парчевский, аек акыллы инженер Протасовлар. Тунгуслар. Ничаклы бизәк, ничаклы уй борылмасы, фикер йөртү рәвеше! Боларның барысы тәрҗемәчедән бик нык эзләнү, уйлану, татар теленең барлык хәзинәсен эшкә җигүне таләп иткән. Нәфислек һәм үткенлек, сагыш һәм моң, дорфалык һәм каргыш сферасыннан тәрҗемәче күтәрелмәгән чирәмнәрне дә актарып чыгарган һәм, көче җитмичә, аударып киткән генә урыннары да калган. Китаптагы күп санлы атамалар, елга-күл исемнәре, авыллар, кошлар, үләннәр, җәнлекләр дөньясы, объект исемнәре шулай ук зур тырышлык белән, уйланып тәрҗемә ителгәннәр. Себердә «Угрюм река» дигән елга юк, автор аны шул заманның тормыш символы итеп ала. Бу нәүбәттән аның татарчага «Хәсрәт дәрьясы» дип тәрҗемә ителүе, минемчә, бик уңышлы, һәм ул әсәрнең төп идеясенә дә туры килә. «Гляди в оба» башнясының «ике күзең ут булсын» дип тәрҗемә ителүе, сукбайларга тагылган кушаматларның татарча алынуы, борынгы җырларның күп урында әйбәт тәрҗемәсе әсәрнең тәэсир итүен көчәйтеп җибәрәләр, аны аңлаешлы һәм әдәби-нәфис итәләр.

«Хәсрәт дәрьясы»ның татарчасы җиңел укыла, аңлашыла. Оригиналдагы тәэсорат югалмый, русчадагы матурлыгы белән үк татар укучысына килеп җитә һәм күңелдә зур тойгы калдыра. Татар укучысының матур әдәбиятка булган зәвыгын тәрбияләү ягыннан караганда, «Хәсрәт дәрьясы» — гаять кирәкле әсәр. Беренче тәрҗемәләрендә әле капшанып кына, курка-курка гына эшләгән Кыям Миңлебаевның бу китапны кыю һәм җитди тәрҗемә итүе аның алга таба тәрҗемәдә бик күп эшләр башкара алачагына ныклы ышаныч тудыра.

*ГАРИФ АХУНОВ.*

## МОРДВА МӘКАЛЬЛӘРЕ

**Дөреслекне сукыр да күрә.**
**Намус тешсез, ә кимерә.**
**Баткан чакта балтасын да бирә, котылгач — сабы да жәл.**
**Әгәр яманнан курыксаң, яман эшләр эшләмә.**
**Тешли торган эт өрми, ә өргән эт тешләми.**
**Кулы йомшак, ә тырнагы үткен.**
**Начар гадәт күлмәк түгел, салып ташлый алмыйсың.**

**З. Нури тәрҗемәләре.**

# Әдәби тәнкыйть

## НАЧАР ӘСӘР НИЧЕК ДӨНЬЯГА КИЛӘ

М. Шәйминең хикәяләре «укучылар тарафыннан җылы каршы алыналар... ә «Сынау» повестен укып чыккач, аның геройлары безнең белән реаль тормышта бергә яшәгән, бергә эшләгән танышлар кебек күз алдына килеп басалар...»

«Безнең шәһәр утлары» китабына кертелгән биографик белешмәдә шундый сүзләр укыйбыз. Мондый сүзләр ишетүне язучыларыбызның теләсә кайсы, әлбәттә, чиктән тыш зур мактау итеп кабул итәр иде. Ләкин нәшриятның матур әдәбият бүлеге биргән белешмә күрсәтүенчә, язучы М. Шәйми иптәшнең моннан башка да зур казанышы бар: ул әсәрендә гаять җитди һәм кыен тема — партия тормышы темасын күтәрә.

«Партия оешмасының оештыру ролен, коммунистларның яңа якты тормыш төзү юлында бөтен коллективны әйдәп баруларын эштә, тормыш вакыйгаларында күрәсең...» дип язылган бу хакта белешмәдә.

Безнең бу сүзләргә бик ышанасы килә. Әдәбиятыбызда чыннан да сирәк очрый торган теманың бу китапта шулай оста чишелүен күрәсе килә. Дөрес, тормышчанлык терминының кабатлануы сагаерга мәҗбүр итә. Газета-журналларда басылган күп кенә рецензияләрдә, әсәрне мактарга кирәк булды исә, дәлилгә «тормышчанлык»ны сөйрәп чыгару гадәт булып киткән. Бу-дәлил кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә, сүз таба алмаганга да, рецензентның әйтер фикере булмаганда да китерелә. Һәм, әлбәттә, аталып кына үтелә, исбат ителми. Бу очракта да тормышка ишарә еш кабатлана торган дежурный сүз генә түгелме? Тормыштагы танышларыбызга китапта нинди рухи байлык бирелгән дә, тормыш вакыйгалары кешенең эчке дөньясын ни дәрәҗәдә ача алган? Повестьтан шул сорауларга җавап эзлибез. Вәгъдә ителгән танышларыбызны очратырга тырышабыз. Аның берсе, әлбәттә, повестьның төп герое парторг Сабир Хәкимов булырга тиеш.

Менә Хәкимов обком бюросында сөйләр өчен доклад әзерли. Без әле аның белән танышабыз гына, шуның өчен, әсәрдә күрсәтелгәнчә итеп әйтсәк, «партия политик эш торышы» турында язып та, «дөнья күләм тарихи уңышлар»га күп урын бирүенә гаҗәпләнмибез. Без әле аның авызыннан ишетелгән беренче сүзләренә дә әллә ни игътибар итмибез. «Иртә торган — уңган», — дип җавап бирә ул ишек алды себерүчегә. Аннан соң, Бәдәр белән Әхмәтша картның әйткәләшүен күреп, Бәдәргә: «Нигә карт кешене рәнҗетәсең?» дип өсти. Хәкимовның бу сүзләреннән Әхмәтша картның уйга батуына, күңеле нечкәрүенә дә бармак аша карыйсың. Һәм мондый вакыйгалар бик еш кабатланып тормасалар, бәлки, авторны аның өчен дә гафу итәр идек.

Кызганычка каршы, Хәкимов адым саен «иртә торган уңган» кебек гап-гади хакыйкатьләр сөйләп йөри торган кеше икән. Аның шул хакыйкатьләрен тыңлаган һәр кеше эреп китә, күз яшьләрен сөртә икән.

«Иң көчле машина да кешедән башка җансыз ул»; «Кеше тудыра алмаган нәрсә бармыни дөньяда»; «Партия әйтә: «Яла ягучыларны рәхимсез җәзала»,— ди»; «Партия: «Кемнең кем булуына карамыйча тәнкыйтьлә» — ди»; «Эшчеләр сыйныфы иң куәтле сыйныф»; «Тыры-

шып эшләсәң күңелең дә пакь булыр, тамагың да тук булыр»; «Ышан, әмма тикшер!» — дип һәркемне өйрәтә. Һәм шунысы хикмәт— аны тыңлыйлар, хәтта Әхмәтша карт кебек, шул сүзләрдән тойгыга бирелеп, балавыз да сыгалар. Менә шуннан соң чынлап торып гаҗәпкә калырга туры килә. Андый кешеләрне тормышта кире типлар дип йөртергә гадәтләнелгән. Повестьның авторы исә, Хәкимов ул чынчыннан уңай герой дип, башкаларны «әйдәп баручы» булуына ышандырмакчы була. Сурәт чаралары белән дәлилли алуына шикләнгәч, бармак белән төртеп күрсәтә:

«Кешеләр белән аралашып, аларның шатлыкларын да, кайгыларын да уртаклашып яшәүче Хәкимов, үзенең соңгы сүзләре кызга охшамаганлыгын шунда ук сизеп алды...»

«Хәкимов, завод кешеләрен күз алдыннан кичереп, аларны күңеленнән коча-коча, механика цехына килеп керде», дип яза М. Шәйми. Мондый җөмләләр башка кинәт күсәк белән китереп органдай итәләр. Без бит аларны фәкать әдәби әсәргә язылган пародияләрдә генә очратырга күнеккәнбез. Әмма «Сынау» повестенда мондый аңлатма җөмләләр тулып яталар.

Бәлки, тормышчан герой дип мактаганда редакция икенче геройны — өлкә комитеты секретаре Филимоновны күз алдында тоткандыр? Филимонов образын автор Хәкимовка караганда укымышлырак, тирәнрәк фикер йөртә торган кеше итеп күрсәтергә тырыша. Ул сөйләгән сүзләр фәннилеккә, цитата булуга дәгъвалиләр. Әмма аңа карап Филимонов образы аз гына да җитдиләнми. Киресенчә, ул әйткән сүзләрнең я мәгънәсе юк, я алар әллә кайчан мәктәп баласына да мәгълүм хакыйкатьләр булып чыгалар:

« — Политикадан читләшсәң, запчасться әйләнәсең, хуҗалыктан ераклашсаң, коры политикан булып каласың, яле, иптәш Хәкимов, шуларның һәр икесен бергә бәйләп, кыска гына сөйләп бир әле...»

«Артка карасаң, алга атлап булмый. Безнең кайберләребез авыр промышленностьны, аерым алганда, машина төзелешен онытып ялгыш итәләр», дип башкаларны югарыдан торып өйрәтә Филимонов. Партия тарихы китабының элеккеге басмаларыннан алынган һәм гаять тә тирән фикер булуга дәгъваләгән бу җөмләнең Филимоновны нинди көлке хәлгә калдыруын әйтеп тору кирәк микән?

Менә Филимонов промышленность бүлеге мөдирен «нормага сыялар» дип сөйләгәне өчен ачулана — «эшчеләр күрсәтелгән вакытка машинаны өлгертәләр», — диярга куша. Заводка:

« — Эшчеләр сыйныфына сәлам!» — дип килеп керә. Ипатовны аркасыннан кагып үтә, Камали картка җиткәч, җитди төс ала. Баксаң, Камали картның карчыгы больницада авырып ята икән, ә секретарь, монда килгәнче, больницага кереп, карчыкның хәлен белеп чыккан, җитмәсә, врачларга тизрәк терелтергә кушкан.

Секретарьның тел чисталыгы өчен көрәшүе һәм эшчеләр хәлен белергә тырышуы, әлбәттә, бик мактаулы сыйфатлар. Әмма әсәрдә Филимоновның бу эшләре аның тиешле сыйфатларын санап чыгу өчен генә китерелгәне күзгә бәрелеп тора. Филимонов үзенчәлекле, җанлы кеше түгел, ул нибары акыллы сүзләр сөйләп йөрүче автомат кына. Шуңа күрә аның иң матур эшләре дә ышандырмый, мавыктырмый. Филимонов тормыш тудырган герой булудан бик, бик ерак тора.

Повестьта хәтта эпизодик уңай геройлар да бер сүз әйтү белән үзләренең шактый буш кеше икәнлекләрен белгертеп өлгерәләр.

Өлкә комитеты бюросы. М. Шәйми утырышның гаять эшлекле баруын сиздерергә ниятли һәм моңа кадәр дәшми-тынмый утырган бюро членнарын телгә китерә.

Горком секретаре Сөләйман Хәкимовтан:

— «Әйтче зинһар, соңгы өч ай ничә эшчене партиягә алдыгыз?» дип сорый.

Обкомның икенче секретаре ... лаловның калын тавышы яңгы

«— Горком секретареның шул турыда белмәве, чыннан да, гаҗәп.

Сөләйманов кызып:

— Татарга толмач кирәкми, — диде, — мин сорауны докладчыга бирдем, сиңа түгел, иптәш Билалов!

— Завод парткомындагы хәлне горком белмәгәч, кем белер?

— Фактсыз гаепләргә хакың юк...»

Нәтиҗәдә, автор теләмәсә дә, мәгънәсез ызгыш, талаш килеп чыга. Гафу итегез, тормышта безнең андый унай геройлар очратканыбыз юк. Безнең танышлар эчпошыргыч күңелсез, тар карашлы ясалма кешеләр түгелләр. Алар бүгенге көннең катлаулы мәсьәләләре турында акыллы итеп фикер йөртә, хәсрәтләнә, шатлана беләләр. Ярата, дуслаша алалар, шаярта һәм вакытында көлә беләләр. Һәм, ниһаять, алар интеллектуаль яктан М. Шәйми геройларыннан күп мәртәбә бай кешеләр.

Бәлки, повестьтагы кире типлар уңышлы, «тормышчан» чыкканнардыр, бәлки рецензентлар тормыштагы танышларыбыз турында сөйләгәндә шуларны истә тотканнардыр? Ләкин повесть белән танышып чыккач, тискәре геройларның да исең-акылың китәрлек мәгънәсез, ясалма икәнлекләрен, аларның бөтен эше уңай геройлар сөйләгән акыллы фикерләргә каршы килү, һәр яхшылыкка начарлык белән җавап бирү кебек гап-гади схемадан гыйбарәт икәнлеген күрәсең. Менә кысынкы, майлы күзле, соргылт, яңак сөякләре биешкән йөзле «сәер мышный» торган цех начальнигы Вәлишин. Вәлишин тәнкыйтьсөйми, консерватор, капитулянт, ялганчы, күз буяучы, хатынына хыянәт итүче. Ул эчә, өендә тупас сөйләшә, кеше семьясын боза, кешеләрне берсенә каршы икенчесен дә котырта, яла да яга. һ. б. һ. б... Дөньяда булган барлык юньсезлекләрне үзенә җыйган бу бәндәгә каршы повестьның башыннан ахырынача көрәшәләр. Аны фаш итәргә тырышалар. Һәм менә шул көрәш — повестьтагы төп конфликт булып оеша.

Шундый эштер-өштер генә әвәләнеп оештырылган я беркатлы, я буш, я ахмак образлар җитмәсә исең-акылың китәрлек мәгънәсезлекләр дә эшлиләр. Хәкимов хезмәт итә торган заводка «запчасть эшләү үткән этап» дип (запчасть эшләүнең нинди начарлыгы бардыр!), министрлык һәм партия өлкә комитеты яңа машина эшләп чыгару бурычын тапшыралар. Завод җитәкчеләре бу бурыч турында эшчеләргә сөйлиләр-сөйлиләр дә... оныталар. Яңа машина эшләсе урынга, һаман да запчасть эшләп ята бирәләр. Онытылу вакыйгасы әсәрдәге сюжетның нигез ташы булып хезмәт итә. Шуннан соң вакыйга яңа машинаны ашыгыч рәвештә төзеп бетерү тирәсендә бара.

Менә шул «нигез ташы», беренчедән, зур завод коллективының хөкүмәт һәм партия тапшырган бурычны хәтердән чыгарып, үтәмәү кебек адәм ышанмаслык уйдырмага корылган.

Икенчедән, бюрода секретарь: «Артка карасаң, алга атлап булмый», дип бик каты орышкач, завод җитәкчеләренең ялгышларын танып, кара кайгыга батулары гаҗәп. Чөнки Хәкимов бюрога барыр көнне генә ул яңа машинаның үзен түгел, сызымнарын да күргән кеше юклыгын, ул сызымнарның хәтта кайчан килеп җитүләрен дә белүче юклыгын укып үткән идек инде (73 бит). Ә бит бу вакыйга повестьның өчтән бер өлешен тәшкил итә!

Сюжет менә ничек үсә. Бюродан кайткач, парторг Хәкимов «килеп чыккан хәлне бер атна ачыклый». Иң башта ул яңа машина турында технолог Корбанов белән сөйләшә.

«Запчасть эшләгән җиһазлар белән «КФС»ны ясап буламы соң? Безнең станокларның теше үтәме андый машинага?» дип шик белгертә технолог (Моңарчы без махсус яңа станоклар кайтканлыгын укып үткән булсак та).

Хәкимов өчен бу сөйләшү мондый нәтиҗә ясарга этәргеч була: «Димәк, эшләргә теләүчеләр бардигән сүз!»

Шуннан соң Хәкимов эшчеләрнең ял сәгатьләрендә цехка керә һәм, туктап калган станокларга карап, иң көчле машинаның да кешесезнисез эшли алмаганлыгын күрә. Бу уйланулар аңарга икенче мөһим нәтиҗәсен ясарга ярдәм итәләр:

«Димәк, кешеләр белән эшләү үзәк мәсьәлә булып калуында дәвам итә».

Ул да булмый, парторг заводка колхоздан кешеләр килгәнлеген белә. Машина юк, ә аны эшләтергә өйрәнүчеләр килгән. Ни эшләргә?

Парторг тагын гаять акыллы нәтиҗә ясап куя: «Ашыгырга кирәк һәм ашыгырга».

Парторгның «ашыгу» процессы эшчеләрне артыннан ияртеп, эчләренә хезмәт уты салуы әсәрдә болай сурәтләнә.

Парторг, эшчеләрнең ял вакытында цехка кереп, алдынгы эшче Исламовны: «Яшь чак — йөрәкле чак, егәрле чак, диләрме әле,— дип, шаяртып» көлдерә. Аннары яңа машинаның картерына күз төшереп:

«Карап торсаң янына барырга куркыныч. Ә эшче курыкмый, шулардан машина ясап, колхозларга озата», «дөньяны хезмәт кешесе төзи... илнең хуҗасы ул», — ди. Менә шул сүзләр бөтен цех эшчеләрен парторг янына җыялар. Парторг «аягүрә басып, кулларын артка салып, әрле-бирле йөри», обком бюросында Филимонов әйткәннәрне сөйләргә керешә. Секретарьның: «Теләк әйбәт нәрсә, шулай да чынбарлык түгел әле ул», дип кисәтүен эшчеләргә җиткерү — агарту эшенең кульминацион ноктасы була. Кемдер, бу сүзләргә шаккатып, хәтта: «Здорово!» — дип куя. Нәтиҗәдә Хәкимов «бөтен смена эшчеләрен үзенә тарта».

Завод шул вакыйгадан соң ыргылып алга үрмәли башлый. Новаторлар туалар, уртача кире тип эчкече Калмурзинны иптәшләр судына чакырып төзәтәләр. Секретарьның: элек капитализм заманында яшәгән булса, Калмурзинны, көн дә эчкәне өчен, эштән куарлар иде, дип сөйләвеннән соң, Калмурзин елап җибәрә. Тәнкыйть сөйми торган консерватор, капитулянт, ялганчы, күз буяучы Вәлишинны фаш итү өчен исә, обком ярдәме кирәк була.

Сюжет менә шундый очы очка ялганмый торган кызыксыз, ләкин җитди нәтиҗәләргә дәгъва итә торган вакыйгалардан тора. Сәнгать әсәрендәге кечкенә генә фальш та, ясалмалык та — гафу ителми торган кимчелекләр. Монда исә фальш һәм ясалмалык бүлек саен, бит саен. Повестьта яңа образлар да, яңа сюжет борылышы да, яңа табыш, фикер дә очратмыйбыз. Һәм бу хәл бер «Сынау» повестена гына да хас түгел. Шундый ук кимчелекне авторның «Безнең шәһәр утлары» китабына кертелгән дүрт яңа хикәясендә дә очратабыз. Бу хикәяләрдә дә геройларның кичерешләре нигезсез, фикер йөртүләре сай. Хикәяләрендә газета мәкаләләрендә күп тапкырлар кабатланган темаларны автор аз гына да тирәнәйтмичә, кайчак хәтта мәкалә сюжетлары да сакланган хәлдә файдалана.

«Шайтан» мәхәббәте»ндәге темага һәм аның чишелешенә генә күз салыйк. Бик зур җинаятьче, шпана, элек үзе кебек үк, кыек юлдан йөргән кызны очрата. Кыз эшли башлаган, төзәлгән. Ул шпанага да төзәлергә куша. Һәм «Шайтан» шул сүзләрдән «акылга утыра». Шунда ук обком йортына китә.

«Миңа сездән бер генә нәрсә кирәк: ул да булса — ышаныч», — ди ул секретарьга.

Обком секретаре, тирән уйга калып, Шәйдуллага карый да:

— «Кешене үтерүче дә кеше, терелтүче дә кеше, — ди. — Әгәр син кешеләргә ышансаң, ә алар сиңа ышансалар, ул чагында синең өчен хәл итмәслек бернәрсә дә юк дөньяда. Ә инде ышанмасаң, беттең, үз кулларың белән кабер казы да, үз аякларың белән кереп ят! Ышаныч шундый көч ул: аяксызлар аяклы, канатсызлар канатлы була аның белән. Безнең фикеребезчә, сезгә нәкъ менә шундый канат җитми. Совет кешесенә ышанмаска безнең хакыбыз юк!» — ди.

Бу урында, әлеге дә баягы «Сынау» каһарманнары кебек акыллы

сүз әйтергә тырышучы геройларның берсен тагын очратабыз: артык яхшы булырга тырышып, секретарь монда гуманизм турында иң элементар төшенчәләрне дә боза, мәсьәләгә гаять дәрәҗәдә җиңел карый. Әмма шунысы гаҗәп: бу сүзләрдән соң җинаятьче дөрес юлга баса. Ул хәтта урамнан тапкан кошелогын да кесәсенә салмый — милициягә илтеп тапшыра.

Җинаятьчеләрне тәрбияләүнең мондый ялгыш ысулын берничә ел элек газеталарда очраткан идек инде. Аннан соң шактый гомер үтте, тәрбия ысулы турындагы фикерләребез нигездә үзгәрде. Ләкин, баксаң, шул иске карашны һаман пропагандалап ята бирәбез икән әле.

«Яшәрү» хикәясендә карт эшче Таҗетдин пенсиягә чыккач, эшләмичә, «куян куып» йөри. Ләкин бер мәлне ул кинәт: «Кешеләр коммунизм төзегәндә, куян куып йөрер хәлем юк» дигән уйга килә һәм заводка бара. Ә заводта, әлбәттә, тәҗрибәле картларның иң кирәк вакыты, чөнки «сабыр (?) табигатьле директор», яшьләрне үстерәм дип, практикага бай картларны пенсиягә озатып, ялгыш иткән. Һәм шуның аркасында «ике яр арасында чайкала» икән.

Картсыз заводның эше харап, ләкин штат юк. Директор ике яр арасында чайкалуын дәвам итә. Әмма Таҗетдин карт «Миңа акча кирәкми, иптәш Мәүлиев, эш кирәк, эш. Актык сүзеңне әйт тә, эшкә тотыныйм. Юкса кул кычыта...» — ди.

Директор икеләнә. Әмма карт тыкырдата гына:

« — Эш бирегез миңа эш, акчасы илгә булсын, эш кирәк миңа!»

Партком секретаре Смирнов Таҗетдин картны акчасыз эшкә алырга мөмкин дип саный, ләкин аның өчен картка завод кием-салым әйберләрен, ашау-эчүне бушлай бирсен, квартирасы өчен түләсен, менә бу картның коммунистик башлангычын үстерү булыр дип тәкъдим кертә.

Смирновның тәкъдиме директорга ошый. Аның «үрә торган чәчләре берәм-берәм яталар».

Картны эшкә алалар. Хикәя шуның белән тәмам була. Бу хикәянең сюжетына, безнеңчә, комментарийлар кирәкми.

Китапка кергән хикәяләрнең башкалары да сәнгатьчә эшләнешләре һәм эчтәлекләре ягыннан «Шайтан» мәхәббәте» һәм «Сынау» повестеннан аз гына да өстен түгелләр. Ә бит «укучылар тарафыннан җылы каршы алынган» дип, китапның белешмәсендә мактаган хикәяләр җыентыгы да, «Сынау» повестеның беренче басмасы да китап сәүдәсендә сатылып бетмәгәннәр, китапларның шактый өлешен макалатурага тапшырырга мәҗбүр булганнар.

Дөресен әйтик, бу очракта безнең авторга дәгъвабез юк. Язучы булмау җинаять түгел. Без аның чын күңелдән, файдалы, кирәкле эш башкарам дип, язганлыгына аз гына да шикләнмибез. Әмма, күңелсез булса да дөресен әйтик, язучылык эшенә М. Шәйминең талантлы да, күзәтүчәнлеге дә, хис байлыгы да, өстәвенә теле дә җитми.

«Менә хәзер кайтып керер, өстенбашын салыр да, аны-моны **шәйләп** тормастан, өстәл башына узар, һәм, шулай ук аны-моны **шәйләмичә** генә, сораулы караш ташлап, «Ясадыңмы? Чәең кайнармы?» дияр дә самоварга таба кулын сузар...»

«...нәрсә аны монда килергә мәҗбүр иткән? Әллә пенсиясен җиткерә алмыймы картлач? Алай дисәң, йөзендә мескенлекнең эзе дә күренми, ә горурлык, нәрсәдәндер бик канәгать булып дулкынлану, канаты таушала төшкән булса да җилпенеп очып китәргә әзер тору бөтен **мохиты** белән чагыла».

«Яшәрү»

«Куприянов, үз дәрәҗәсен белгән олы коштай, сабыр гына елмаеп, башын селки-селки утырды».

«Ә киресенчә кирәк иде, кыенлыкларны җиңә-җиңә тауга үрмәләргә, иңкүлекне артта калдырырга кирәк иде».

«Ә кеше дөньяга күз сала башлау белән, әй чаба, әй чаба, вакытны куып җитәргә тырыша, ләкин өлгерә алмый кала, менә куып җиттем дигәндә генә шарт — сына да төшә. Шулай булгач, нишләргә?».

«Аның (парторгның — А. Я.) йөрәге сулкылдап тибә, ә күңеле «Гарәфи энисе» ди иде». («Сынау»)

Мондый, сүзе урынсыз кулланылган, яки мәгънәсе булмаган, татарча төзелмәгән җөмләләрне мисалга дистәләп китерергә мөмкин булыр иде.

Әмма бу хакыйкатьне М. Шәймигә вакытында әйтмәгәннәр. Язган әйберләрен газета-журналларда, китап нәшриятында чыгара барганнар. Бу хәл белән кызыксынып, нәшриятка керегез. Беренче басмасы сатылып бетмәгән «Сынау» повестеның ни өчен шул арада икенче басмасы чыга алуын белешегез. Алдыгызга шалт итеп эчке рецензия чыгарып салачаклар.

— Рецензияне, гафу итегез, без язмадык, күренекле язучы язган! — диячәкләр.

Һәм бу очракта, кызганычка каршы, шулай булган. Эчке рецензиянең авторы — өлкән язучыларыбызның берсе шагыйрь Мөхәммәт Садри. Менә ничек бәяләгән Мөхәммәт Садри повестьны:

**«Бу повестьны ышанып, мавыгып укыйсың, андагы образлар, вакыйгалар, уңай характерларның хәрәкәтләре, яшәүләре, көрәшләре, тынгысызлыклары һәм тормышка актив карашлары, көчле тәэсир итеп, үзләренә теләктәшлек тудыралар.**

**...«Сынау» повестеның иң уңай ягы Коммунистлар партиясе вәкилләрен тормыштагыча итеп, кабатлап әйтәм, тормыштагыча дөрес гәүдәләндерүдә... Обком секретаре Игнат Захарович Филимонов образы язучы өчен гаять җитди, катлаулы образ, үзенең кешелеклеге, эшчеләргә игътибарлылыгы, аның завод коллективы тормышының күп яклары парторгтан да артыграк белүе укучыны сокландыра. Бу инде «Саз чәчәге»ндәге партия работнигы түгел (андыйларның характерлары җиңелрәк), ә партия тормышын, партия работникларын яхшы белгән, алар арасында коммунист булларак кайнаган язучы өчен типик образ...»**

Шундый озын цитата китерүебезнең сәбәбе — рецензия авторының үз эшенә ни дәрәҗәдә җавапсыз карaганлыгын исбат итү. Мөхәммәт Садри иптәш әсәрнең эченә керергә базмыйча, Филимонов образын гаять тә берьяклы, фәкать бер тышкы сыйфаты буенча гына бәяли. Җөмләләрендә гафу итмәслек фикер шапшаклыклары җибәрә. Һәм, әлбәттә, «тормышчанлык» бәясен төп бәя итеп файдалана.

Парторг Хәкимов образын да бик мактый рецензент, аның укучыны тәэсирләндергәнен әйтә. Әсәргә гомуми бәя биреп, анда поэзия барлыгын күрә. Ләкин М. Садри иптәш фикерләренең берсен дә исбат итми.

Эчке рецензиягә шундый салкын караш аның киң катлам халык өчен язылмавыннан килә булса кирәк. Ләкин гамәлдә менә шул халык укымый торган эчке рецензия газета-журналларда басылып чыккан рецензияләргә караганда әһәмиятлерәк. Ул китапның басылу-басылмавын хәл итә. Нәшриятның матур әдәбият бүлегеннән җаваплылыкның бер өлешен ала. Кызганычка каршы, эчке рецензия язу — ул рецензентнең кечкенә генә булса да сынау — намусы каршында сынау үтүе икәнлеген истән чыгарабыз.

Шундый ук сынауны рецензияне кабул итеп алучы нәшрият работниклары да үтмимени? Һәм мәсьәләгә партия таләбеннән килеп карасалар, принципиаль булсалар, нәшрият җитәкчеләре М. Садри иптәш язган кебек рецензияне кабул итеп алырга тиеш түгелләр иде.

Эчке рецензия язучыларга (ә аларны шул ук нәшриятның әдәбият бүлеге мөдире сайлый), аерым алганда, Мөхәммәт Садри иптәшкә, зур дәгъва белгертү кирәк дип саныйбыз. Ул мәсьәләгә җитди килмәгән, китапны чынлап торып аңларга тырышмаган, нәтиҗәдә, сәнгать эшләнеше ягыннан түбән, идеясе ягыннан сай китапның тагын бер кирәкмәс басмасының дөньяга килүенә сәбәпчеләрнең берсе булган.

Кызганычка каршы, «Сынау» повесте шул юл белән чыккан китапларның беренчесе, намусы каршында сынауда каушап калучылар берәү-икәү генә түгел.

Бу мәкаләне без шуңа яздык та.

**А. ЯХИН.**

# УЛ ЯРДӘМЧЕЛ КЕШЕ ИДЕ

1940 елның башында мине Оренбург techинститутына татар әдәбияты укытырга җибәрделәр. Баштарак мин шактый кыен хәлдә калдым. Татар совет әдәбияты курсы программасына Муса Җәлил иҗаты да кертелгән иде. Ул еллардагы татар матбугатында исә Мусаның тормыш юлы, иҗаты турында төпле бер фикер алырлык хезмәтләр һәм тәнкыйть мәкаләләре юк иде. Барлык җыентыкларын алып, шагыйрьнең иҗатын өйрәнеп, тикшереп чыгудан башка чара калмады. Эш барышында Муса Җәлил турында байтак материал тупланды, аның поэзиясенең үзенчәлекләре турында кызыклы гына фикерләр туды. Һәм мин, «Совет әдәбияты» журналы редакторы Имаметдиновка хат язып, М. Җәлил иҗаты турында мәкалә язарга теләгәнемне белдердем.

Казанга кайткач Язучылар союзындагы бер җыелышта, М. Җәлил минем яныма килеп: «Сез минем иҗатым турында язарга уйлыйсыз икән, сезгә материалларны үзем бирермен», — диде. Берничә көннән ул миңа бер кочак дәфтәр китереп бирде. Аларда М. Җәлилнең 1919 елдан башлап язылган шигырьләре тупланган иде. Һәр шигырьнең кайчан язылганы һәм кайда басылганы да күрсәтелгән. Материаллар арасында «Хат ташучы» поэмасының караламасы да бар иде. Мин бу материалларны бик кызыксынып өйрәндем һәм М. Җәлил иҗаты турында зур гына мәкалә яздым.

Билгеләнгән бер көнне, мәкаләне М. Җәлилнең үзенә укып күрсәтергә дип, Язучылар союзына килдем. Анда Гадел Кутуй да бар иде. Алар икесе дә мәкаләне яраттылар шикелле. Озакламый ул мәкалә, беркадәр кыскартылып, «Совет әдәбияты» журналында басылып чыкты.

Шул очрактан соң без Муса белән тагын да якыннанрак танышып, дуслашып киттек. «Хат ташучы» поэмасы аерым китап булып чыккач, Муса аның бер данәсен миңа бүләк итте. Шагыйрьнең үз кулы белән «Мәһинур Фәйзуллинага тирән ихтирамымның истәлеге» дигән сүзләр язылган ул китапны мин хәзер дә зур хөрмәт белән кадерләп саклыйм.

Муса Җәлилнең кулъязма дәфтәрләре турында сүз чыккач, тагын бер әйбер турында әйтеп китәсе килә. Әлеге дәфтәрләрне өйрәнгәндә кайбер шигырьләрне һәм поэмалардан өзекләрне мин үземә дә күчереп алган идем. Ул язмалар миндә хәзер дә саклана. Арада «Корсак» исемле шигырьдән дә бер өземтә бар (шигырьне тулы килеш «Кызыл йолдыз» газетасының 1919 елгы саннарының берсеннән табарга мөмкиндер). Менә ул өзек:

Өч-дүрт йөз еллар,  
Майлы казылыклар,  
Гел килеп торды  
Баллы азыклар.

Һич эш күрмәде,  
Арып йөрмәде,  
Баллар һәм майлар  
Килми тормады.

Үсте бу корсак,  
Рәхәт гомердә;  
Мичкәдәй булды,  
Кыен йөрергә.

. . . . . . . .

Заманнар үтте,
Дөнья үзгәрде,
Мескен киң корсак
Тарлыкта калды.

Көчле сөңгеләр
Эчне кайнатты.
Шулай кармакка
Килде дә капты.

Майлар килмиләр,
Сәгадәт бетте.
Йөз еллык корсак
Бер көн шарт итте.

Бу шигырь, ни сәбәптәндер, җыентыкларга кертелмәгән...

Шул ук 1940 елда күренекле язучы Ш. Камалның 30 еллык юбилее уздырылды. Юбилей уңае белән мин «Шәриф Камал драмалары» һәм «Таң атканда» романының социаль әһәмияте» дигән ике мәкалә язып, аларның берсен «Совет әдәбияты» журналына, икенчесен «Кызыл Татарстан» газетасына тапшырган идем. Ш. Камалның драмалары турындагы мәкаләм, ни сәбәптәндер, шактый вакыт басылмый ятты. Мәкаләнең редакциядә шулай озак ятуы мине инде борчый да башлаган иде. Ничектер җаен туры китереп, бу турыда Муса Җәлилгә әйттем. Ул, бер дә шикләнерлек урын калдырмыйча: «Кайгырмагыз, Маһинур апа, басачаклар», — диде. Шуннан әллә ни күп вакыт үтмәде, мәкалә журналда басылып та чыкты.

1941 елның башлары иде, бугай. М. Җәлил мине, бер әсәр укырга дип, Союзга чакырды. Шул кичне ул миңа үзе язган бер драма әсәре укыды. Драманың исеме хәтердә калмаган. Производство тормышыннан алып язылган ул драмада сүз бер алдынгы эшче кыз турында бара иде. Бу драманың караламасы сакландымы икән, белмим.

Сөекле шагыйребезне якыннан мин әнә шул бер-ике очрашып сөйләшү буенча беләм. Муса Җәлил белән очрашкан вакытларда мин үзем бер дә юкка нык кыйналган (шәхес культы көчәйгән еллар бит) һәм партиядән куылган бер кеше идем. Шундый бер кешегә танылган шагыйрь, Язучылар союзы председателе, шәһәр Советы депутаты зур ихтирам һәм игътибар күрсәтте. Һәм аның кешелекле мөнәсәбәте миндә яшәргә өмет, эшләргә дәрт уятты. Әйе, бик ягымлы, мөлаем һәм ярдәмчел кеше иде ул.

*М. ФӘЙЗУЛЛИНА.*

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ «АК ЧӘЧӘКЛӘР» РОМАНЫН ТИКШЕРҮ

Татарстан Язучылары союзы каршындагы проза секциясенең 8 октябрьда үткәрелгән утырышында язучы Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» исемле яңа романы тикшерелде.

Утырышны секция бюросы председателе А. Расих ачты.

— Бу романны тикшерү, — диде ул, — авторга да, башка иптәшләргә дә файдалы булыр. Шул ук вакытта бу безнең әдәби осталыкка карашларыбызга да үзенә күрә бер сынау булыр. Әсәр инде ел башында ук басылган булса да, аның турында җитди тәнкыйть мәкаләсе чыкканы юк әле. Бәлки, бу фикер алышу тәнкыйтьчеләргә дә этәргеч булыр...

А. Расихның кереш сүзеннән соң, сүз «Казан утлары» журналы редакторы Р. Мостафинга бирелде. Ул «Ак чәчәкләр»не укучылар яратып каршы алуын, бу романның 1965 елда басылган әсәрләр арасында иң популяр булуын, моның шулай икәнлегеннән редакциягә килгән хатлардан да, укучылар белән очрашкан вакытларда сөйләшүләрдән дә күренгәнлеген әйтте. «Ләкин, — диде ул аннары, — бу әле роман турында минем үз фикерем юк дигән сүз түгел. Мин һәрвакыт яңа әсәрне ике кат укырга гадәтләнгәнмен. Беренчесендә мин аны гади укучы буларак кына, гомумән әсәр белән танышу өчен генә укыйм. Икенчесендә исә һәр деталенә игътибар итеп, тәнкыйтьче күзлегеннән карап укыйм. Дөресен әйтим, беренче тапкыр укыганда әсәр миңа ярыйсы гына эшләнгән кебек тоелды. Әбүзәр абзый образы һәм язучының көндәлеге ошады миңа. Ә икенче кат укыганда мин әсәрнең йомшак якларын күбрәк күрдем. Автор үз әсәрендә сурәтләгән геройларны өч төркемгә бүлә: яхшылар, яманнар һәм уртача, ягъни ике арадагы геройлар. Ул үзенең яхшы геройларын гел яхшы якларыннан, тискәре геройларын гел начар якларыннан гына сурәтли. Кайвакытта автор бик төчеләнеп яза.

Г. Әпсәләмов — сюжет остасы. Ул сюжетны мавыктыргыч итеп төзи белә. Ләкин кайчакта аның әсәрендәге сюжет, геройларның характерын ачуга ярдәм итүдән бигрәк, детектив роль уйный башлый. (Р. Мостафин, үзенең бу фикерләрен дәлилләү өчен романнан мисаллар китерә.) Әсәрнең композициясендә дә җитди кимчелекләр бар. Романны укыгач, миндә шундый тәэсир калды: автор бу әсәрен язу өчен күп материал җыйган һәм ул шул материалның барысын да романга дыңгычлап тутырган. Мәсәлән, көндәлек. Ул үзе болай кызыклы гына эшләнгән. Әмма аны романнан алып ташлау һич тә әсәргә зыян итмәс иде, чөнки ул әсәрдән аерылып, бүленеп тора. Андый урыннар романда байтак. Аларны төшереп калдырганда, минемчә, бу әсәр әйбәт кенә бер повесть булыр иде. Әсәрдәге кайбер артык сентименталь урыннар булуын да искәртеп үтәсе килә. Мәсәлән, Мансурның Дилəфрүзгә өйләнергә карар кылу мотивы һ. б.

Ни өчен соң укучыларның күпчелеге бу кимчелекләрне күрми? Чөнки шундый укучылар бар, алар әсәрне нәкъ менә шул сентименталь, мелодраматик моментлары өчен яраталар да.

Әлбәттә, мондый характердагы әсәрләр дә яшәргә хаклы. Әмма, язучының профессиональ осталыгы киләчәктә тагы да үсеен күздә тотып, турысын әйтергә кирәк: роман сайрак, ашыгыбрак язылган, тормышның катлаулылыгын тулысынча чагылдыра алмаган».

— Мин, — диде Ф. Хөсни, — романны иренебрәк кенә укый башлаган идем. Укый торгач мавыгып киттем һәм ахырынача кызыксынып укып чыктым... Без авылларда еш булабыз һәм беләбез: Габдрахманны укыйлар, аның әсәрләре белән кызыксыналар... Габдрахман безнең әдәбиятта моңарчы язучылар кулы тимәгән темаларны кузгата. Бу юлы ул врачлар тормышы турында язды, шул өлкәне яхшы ук тирән каерып ташлады. Авторның кызыклы гына, күңелне ышандыра торган кешеләре бар. Миңа аның кечкенә кешеләре ошый. Әсәрдә әллә ни зур урын алмасалар да, күренеп-күренеп кенә китсәләр дә, аның кечкенә кешеләре хәтердә кала. Әбүзәр абзый квартирасындагы обстановканы, үзара мөнәсәбәтләренең пакьлеген, сафлыгын бик әйбәт күрсәткән Габдрахман. Әмма, шуңа да карамастан, роман миндә китап тәэсире калдырды. Әдәбият исе, ясалмалык исе килә.

чын мәгънәсендәге тормыш түгел. Нилектән бу? Беренчедән, уңай геройлар чиксез, чамасыз яхшы, алар ничектер пьедесталга бастырылган кебек тәэсир калдыралар. Икенчедән, кирәкмәс урында, гади генә итеп әйтәсе урында — пафос белән, артык «матур» итеп әйтергә тырышу сизелә. Ә Пушкин әйтә: прозаның бөтен матурлыгы гадилектә, ди. Романда гадилек житенкерәми, кирәк-кирәкмәскә купшылык артыннан куу бар. Өченчедән, бик четерекле күренгән ситуацияләрне автор ансат кына чишә дә куя. Мәсәлән, Гөлшәһидә-Мансур линиясе. Ансат аерылулар, ансат кушылулар. Без, язучылар, яшьләрне өйрәтәбез бит, мондый мәсьәләләрне күтәргәндә бөтен житдилеге, катлаулылыгы белән куярга кирәк. Гөлшәһидә авылга китеп ул кадәр нәрсәләр генә эшләгәндер, съездда делегат булып та катнаша, парторг та ул, тегене эшли, моны эшли, әйтерсең, аннан башка берәү дә ул эшләрне күрмәгән. Ә үзенең төп эшен ничек эшли ул? — монысы тиешенчә ачылмаган...

Ф. Хөсни романның теле турында да берничә искәрмә ясый. Калькалар, русча яңгырауч сүзләр, уңышсыз алынган фигыльләр булган җөмләләрдән мисаллар китерә.

— Автор, — диде аннан соң сүз алган М. Шәрифуллин, — романда зур тема күтәргән, материалны нык өйрәнгән. Ләкин әсәр мине мавыктырып китә алмады. Сюжет ныклыгы юк әсәрнең. Төп герой булган Әбүзәр абзый, билгеле, зур галим, ләкин аңа каршы көрәшерлек, аның белән бәхәсләшерлек кеше юк романда. Ә фән өлкәсендә бәхәссез, көрәшсез генә эшләмиләр. Мансур белән Гөлшәһидәнең мәхәббәтләрен күрмәдем мин. Аларның аерылышу сәбәбе зур сәбәп булырга тиеш иде. Янып-көеп йөрүләре дә ясалма кебек. Инде катлауланып китәргә тиеш дип көткән ситуацияләр дә бик ансат кына чишелеп куя...

— Романның миңа ошаган җире, — диде И. Гази, — көндәлекләр. Кызык итеп язылган. Шулай ук әсәрдәге публицистик моментларны да яратып укыдым. Әбүзәр абзый образы иң уңай образ. Авторның беренче романнарында романтизм бик көчле иде. Романтизмның хосусияте шул — анда образлар берьяклы итеп эшләнә. Әпсәләмовның соңгы романы да романтизмнан арынып җитмәгән. Бу романтизм аны коткарган да, батырган да. (Әбүзәр абзый образына туктала һәм аның эшләрендә ышанып җитмәслек моментлар булуын әйтә.) Доктор Әбүзәр үлеп барганны да, үлгәнне дә терелтә. Авторның Әбүзәр мәсьәләсендә киртә сикерүен күргәч, мин инде докторның эшләренә ирония белән, елмаеп карый башлыйм. Бу момент романның сыйфатына зыян китергән. Минемчә, реалистик әсәр шартлы романтизм методы белән язылу аркасында шулай килеп чыккан. Вакыт-вакыт автор чамадан тыш арттырып җибәрә, төчеләнә, геройларны артык кызылга буяп ташлый. Мансур белән Гөлшәһидә арасында мәхәббәт юк бит, егетләр. Ни өчен алар аерыла? Сюжетны шуңа корырга кирәк булганга, автор аларны мөмкин кадәр озаграк кавыштырмаска тырыша. Тискәре геройларның артык кара, ямьсез булулары да — шул ук романтизм баласе.

— Миңа, — диде Г. Бәширов, — бу җыелыш бик ошый. Секциянең, ниһаять, иҗат эшләре белән шөгыльләнә башлавы бик яхшы. Габдрахманның романын секциядә тикшерергә куюы ул үзенә күрә бер егетлек. Без монда, билгеле, зур әдәбиятка куела торган таләпләрдән чыгып сөйлибез. Г. Әпсәләмов, шәт, безне дөрес аңлар. Мин романны яратып укыдым. Шундый гадәтем барын да әйтим: мондый зур әсәрләрне укыганда әдәбиятка нинди яңа образлар алып килә икән бу дип тә уйлыйм. Миңа әсәрдәге «кечкенә» кешеләр күбрәк ошады. Мәсәлән, Диләфрүз үзенең сафлыгы, матурлыгы, самимилеге белән яхшы тәэсир калдырды. Артист та шулай ук истә калырлык итеп, яхшы бирелгән. Әбүзәр абзый борынгы татар интеллигенциясенә хас булган бик күп күркәм сыйфатлары белән ошый... Төп герой буларак Гөлшәһидә романда бик күп урын алган. Әмма кем ул? Зур образларның нәкъ үзләренә генә хас, үзенчәлекле сыйфатлары була. Гөлшәһидәнең дә шәхес буларак үзенә генә хас характерын, үзенчәлекле сыйфатларын калкурак итеп бирәсе иде. Әмма аның бу сыйфатлары күренеп җитмәгән. Ул гомумән матур хатынкыз, гомумән врач кына булып истә кала...

Роман яртысына кадәр бик җиңел укыла. Аннан соң, минемчә, тарту-сузу башлана, ясалмалык күбәеп китә. Янгураны гына алыйк: ниләр генә эшләп бетерми бу кеше! Аның әшәке кеше икәнлеге баштан ук билгеле, әмма ул шуннан соң да бик күп кабахәтлекләр эшли. Ул әшәкелекләрне берсе өстенә икенчесен өеп, ул кадәр күп итеп күрсәтү кирәкме икән? Яки Юматшаны алыйк. Әсәрдә киеренкелек тудыру өчен генә аны машинага таптатып, изепсытып бетерү кирәкмәс иде. Бу аның характерын ачуга ярдәм итми бит. Реалистик романның үз традицияләре бар. Тормышның үзенең катлаулы яклары бар, күбрәк шуларга таянырга кирәк иде.

Бу әсәрендә Габдрахманның теле элеккеге романнарындагыдан яхшыра төшкән... Бу ягы миңа ошады.

— Мин, — диде Г. Бәшировтан соң сүз алган Х. Хәйри, — иптәшләремнең күп кенә фикерләре белән кушылам. Әмма кайберләре белән килешеп булмый. Әпсәләмов биш роман язды һәм язучы буларак һаман үсә бара. Һәр язучының үз стиле бар. Алар бер-берсенә охшамыйлар. Әмма күп кенә язучылар Әпсәләмов стиле белән килешә алмыйлар. Сугыштан соң яңа бер үзенчәлекле стиль белән язылган, яңа төр әсәрләр бирә башлады Әпсәләмов. Күрәсең, моны кабул итәргә кирәктер. Укучылар күптән кабул итте инде аны. Публицистик романнар да яшәргә хаклы, минемчә... Әмма дөресен әйтим: Әпсәләмовның бу романы бик үк ошамады миңа. Аның үсешенең хәзергә югары ноктасы — «Сүнмәс утлар» романы. «Ак чәчәкләр»нең төп кимчелеге — авторның идеаль герой эзләвендә һәм аны пьедесталга утыртырга тырышуында. Гөлшәһидәне алыйк. Ул рухи үсештә, хәрә-

кәттә җитәрлек күрсәтелми. Автор аның алдындагы барлык киртәләрне алып ташлап, юлына чәчәкләр сибеп бара, шунлыктан образның характеры ачылып җитми кала. Әбүзәр абзый да пассиврак бирелгән... Романны яратып укырлар. Автор бу романын яхшырту өстендә тагын эшләр әле. Бу кимчелекләр, бәлки, ашыгучанлык аркасында килеп чыкканнардыр...

Аннары сүз Ә. Еникигә бирелде:

— Нинди критерий белән килергә бу әсәргә? Бер яктан, әсәрне яратып укулары турында укучылардан хатлар күп килә. Икенче яктан, мин үзем шактый аптырауда калдым. Мин башта романны яратып укыдым. Аннары акрынлап кызыксынуым сүрелә башлады. Нинди аршын белән килергә бу әсәргә? — дип аптырап калдым. Язучы күңелендә вакыйгалар, эпизодлар, картиналар йөзләрчә булырга мөмкин. Әмма шуларның иң дөресен, әһәмиятлерәген, зарури булганын гына әсәргә кертергә кирәк, минемчә. Бу романда шул нәрсә җитенкерәми булса кирәк. Умыртка сөяге йомшаграк шикелле моның. Әнә шул умыртка сөягенең — кирәген ала, кирәкмәсен рәхимсез рәвештә читкә ташлый торган үзәк сызыкның булмавыннан килә микән әллә бу йомшаклык? — дип уйладым.

Романда яхшы язылган кисәкләр бар. Авыл күренешләрен дә матур гына сурәтләгән автор... Әпсәләмов иҗатындагы новаторлык ике нәрсәгә кайтып кала, күрәсең: 1) заман өчен яңа булган теманы тотып ала белү; 2) яхшы кешеләр иҗат итү. Ләкин бу бит гомумән әдәбият алдына куелган бурычлар. Минемчә, менә бу дөрес тезисларны механик рәвештәрәк аңлау юк микән Әпсәләмовта.

Яхшы кешене ничек тудырасың? Аны ике төрле юл белән тудырып була. Яхшы кешене уйлап табасың да аны вакыйгадан-вакыйгага, ситуациядән-ситуациягә җитәкләп йөртәсең. Мондый метод бар. Икенче юл — тормышның бер катлаулы, өлгергән проблемасын үзәккә алу. Менә шул проблемага бәйләнешле вакыйгалар була, шул вакыйгалар эчендә кешеләрнең характеры ачыла. Минемчә, менә шулай. Иптәш Әпсәләмов беренче юл белән бармый микән дим мин...

Бу фикерләрен дәлилләү өчен, Ә. Еники Әбүзәр абзый образына тукталды, һәм аның прототибы белән үзенең танышлыгын, ул кешенең художниклар, артистлар белән еш аралашып торучы югары культуралы чын интеллигент булуын, әмма романда аның шул яклары тиешенчә күрсәтелмәвен әйтте.

*Утырышта катнашкан иптәшләрнең чыгышлары кыскартылып бирелде.*

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Мәгълүм булганча, 1941 елның октябреннән 1942 елның гыйнварена кадәр Муса Җәлил Минзәләдә хәрби-политик әзерлек курсларында укый. Ул чорда шагыйрь Минзәлә районы мәктәпләрендә, колхозларында укучылар белән очрашып, халык белән якыннан аралашып яши. Аның мавыктыргыч чыгышларын минзәләлеләр хәзер дә яхшы хәтерлиләр.

Атаклы шагыйребезнең Минзәләдә яшәгән көннәренә истәлек итеп, әле күптән түгел генә андагы элекке хәрби курслар йортына мемориаль такта һәм Муса Җәлилнең рәсеме куелды.

## ЮБИЛЕЙ КОМИССИЯСЕ УТЫРЫШЫ

1966 елның апрелендә халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 80 ел тула. Бу күренекле датаны билгеләп үтү өчен КПСС өлкә комитеты карары белән юбилей комиссиясе төзелгән иде. Октябрь аенда әлеге комиссиянең утырышы булды һәм анда Г. Тукай юбилеен үткәрү планы тикшерелде. Комиссия членнарыннан Х. Туфан, М. Әмир, И. Нуруллин, Х. Госман, Җ. Фәйзи, Г. Халит, А. Сайганов, Х. Гобәйдуллин, Ә. Исхак, М. Мөхәррәмов, утырышта чыгыш ясап, шагыйрь юбилеен киң итеп үткәрү, аның иҗатын тагын да ныграк популярлаштыру һәм исемен мәңгеләштерүгә карата әһәмиятле тәкъдимнәр ясадылар.

## ТЕАТР РАБОТНИКЛАРЫ КИҢӘШМӘСЕ

22 октябрьда КПСС өлкә комитетының конференц-залында театр работниклары киңәшмәсе булды. Анда узган сезонга йомгак ясалды, республикабыз театрлары алдында торган бурычлар турында сүз барды. Докладны Татарстан АССРның культура министры Б. Гыйззәтуллин ясады.

Фикер алышуларда Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе М. Булатова, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Р. Җиһаншина, профессор Г. Гоян, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының баш дирижеры И. Шерман, Мәскәү театр тәнкыйтьчесе К. Кривицкий, Республика күчмә театрының баш режиссеры Р. Тумашев, В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры артисткасы В. Павлова, Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясе председателе Б. Гыйззәт катнашты.

Соңыннан КПСС өлкә комитеты секретаре М. З. Тутаев чыгыш ясады.

## КҮЧМӘ КҮРГӘЗМӘ

Бу күргәзмәгә РСФСРның мөгнәрчә художниклары дүрт ел буе әзерләнделәр. Аңа 50 меңгә якын сынлы сәнгать әсәре тәкъдим ителде. Күргәзмәгә куелган әсәрләр башта урыннарда, аннары зоналарда сайлап алынып, аларның иң яхшылары бу елның февраль — март айларында Мәскәүдә күрсәтелде. Аннан соң, күргәзмәгә куелган әсәрләр белән халыкны мөмкин кадәр күбрәк таныштыру максатыннан чыгып, өч маршрут буенча күчмә күргәзмә оештырылды. Шуларның берсе октябрь аенда Казанда күрсәтелде. Барлыгы 150 экспонаттан торган бу күргәзмәгә төрле

жанрда язылган әсәрләр куелган иде. Күргәзмә казанлыларда жылы тәэсир калдырды. Ю. Беловның «1917 елның 28 октябрендә В. И. Ленин путиловчыларда», А. Бубновның «Пугачев восстаниесе», И. Симоновның «Минем геройларым», М. Лехачевның «Анлашу», М. Малютинның «Валя Смирнова портреты», А. Федотовның «Авачин култыгы», А. Заусаевның «Язгы ташу» исемле әсәрләрен тамашачылар аеруча кызыксынып карадылар.

Мондый зур масштаблы күргәзмәдә республикабыз художниклары әсәрләрен күрү дә бик куанычлы булыр иде, әлбәттә. Ләкин, кызганычка каршы, анда безнең художникларыбызның бары тик бер генә әсәре — Л. Фәттаховның «Шәһәрдән» исемле картинасы гына куелган. Мәскәү күргәзмәсендә югары бәя алган Х. Якупов полотносы ни өчендер Казанга китерелмәгән.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Сарман районының «Искра» колхозы идарәсе һәм парткомы чакыруы буенча, язучылардан Г. Ахунов, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин, С. Кальметов шул колхозда очрашу үткәрделәр. Алар үзләренең әсәрләрен укыдылар. Кичәнең икенче бүлегендә үзешчән сәнгать коллективы С. Кальметовның «Сизгер күләш» исемле бер пәрдәлек пьесасын күрсәтте.

* * *

27 сентябрьдә Г. Ахунов, Ә. Маликов, Р. Төхфәтуллин Сарман районы Иске Кәшер сигезьеллык мәктәбе укучылары һәм укытучылары белән очраштылар. Алар анда үзләренең яңа әсәрләрен укыганнан соң, тыңлаучыларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирделәр.

* * *

Әлмәт бүлеге утырышында очеркист Герман Крыловның «Рекордлар сере» дигән яңа очерклар җыентыгы укып тикшерелде. Тикшерүдә катнашучылардан Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, М. Зарипов, И. Винокуров һ. б. очеркларның уңай һәм йомшак якларын күрсәттеләр, тәзәтү өчен авторга киңәшләр бирделәр.

* * *

Шагыйрьләрдән Г. Паушкин һәм Р. Кутуй, «Знамя труда» газетасы каршындагы рус әдәбият берләшмәсе утырышында булып, Әлмәт авторларыннан М. Зарипов, И. Винокуров, Д. Матвеев, В. Мальцев һ. б. ларның шигырьләрен, очеркларын тикшерүдә катнаштылар.

* * *

Әлмәт бүлегенең чираттагы утырышы «Язучының эш культурасы» дигән темага багышланды. Анда күп кенә яшь авторлар катнашты. Язучылардан Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин әдәби осталыкка ирешү юллары турында кызыклы чыгышлар ясадылар. Ахырдан яңа әсәрләр укып тикшерелде.

## ТАТАРСТАН СӘНГАТЕ ТАШКЕНТТА

Шушы елның октябрь аенда Үзбәкстан башкаласы Ташкентта республикабыз художниклары әсәрләре күргәзмәсе оештырылган иде. Ташкентның рәсем сөючеләре художникларыбыздан Р. Кильдибековның «Челтәр бәйләүчеләр», Л. Фәттаховның «Яңа буралар», «Июнь», С. Лывинның «Кышкы сукмак», М. Майоровның «Китап укыганда», М. Прокопьевның «Хуш, иптәш!» исемле картиналарын зур кызыксыну белән карадылар. Газеталарда басылган мәкаләләрдә дә бу күргәзмәгә әйбәт бәя бирелде, аның Үзбәкстан художниклары өчен файдасы зур булачагы әйтелде.

## ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВАНЫ КОТЛАУ

22 октябрьдә Язучылар союзының Габдулла Тукай исемендәге клубында үзенең әсәрләрен «Гыйффәт туташ» псевдонимы астында бастырган шагыйрә Заһидә Бурнашевага 70 яшь тулуга багышланган әдәби кичә булды. Язучы Афзал Шамов алып барган бу кичәдә Казан тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни сотруднигы Рашат Гайнановның З. Бурнашева иҗаты турындагы кереш сүзеннән соң, юбиляр адресына килгән котлаулар укылды, бүләкләр тапшырылды. Аннары Татар дәүләт академия театры артисткасы Ф. Хәмитова З. Бурнашеваның шигырьләрен укыды һәм артистлар көче белән күңелле генә концерт бирелде. Өлкән язучыбыз Госман Бакировның юбиляр турындагы истәлеген дә кичәгә килгән иптәшләр кызыксынып тыңладылар.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Язучыларның Тукай исемендәге клубына 8 октябрь көнне әдәбият сөючеләр җыелды. Шулай итеп, җәйге каникулдан соң, традицион әдәби җомгалар башланып китте. Анда С. Хәким, Ә. Ерикәй, Г. Минский, Г. Афзал, С. Шакир, Г. Зәйнашева һәм башкалар соңгы вакытта иҗат иткән әсәрләрен укыдылар.

* * *

Хәрби шефлык эшенең йомгаклары буенча офицерлар йортында үткәрелгән җыелышта, Казандагы хәрби частьта әдәби кичәләр, очрашулар үткәрүдә актив катнашканнары өчен, язучыларыбыздан Г. Әпсәләмовка, М. Садрига һәм Г. Паушкинга бәяле бүләкләр бирелде.

9 октябрьда Г. Әпсәләмов Казан ветеринария институты студентлары һәм укытучылары белән очрашты. Җиде йөзгә якын кеше катнашкан бу очрашуда Г. Әпсәләмов үзенең иҗаты турында сөйләде һәм күп санлы сорауларга җаваплар бирде. Кичәдә китап сату да оештырылган иде.

* * *

10 октябрьда Г. Әпсәләмов Казандагы Суворов училищесы курсантлары белән очрашты. Ул СССР Верховный Советының VI сессиясендә каралган мәсьәләләр турында сөйләде.

* * *

Язучы Әмирхан Еники, Ташкентта булып, Үзбәкстан язучылары һәм Ташкент шәһәренең Ахунбабаев исемендәге клубында татар укучылары белән очрашты. Китап сөючеләргә хәзерге татар әдәбияты һәм үзенең иҗаты турында сөйләде.

* * *

Н. Дәүли, М. Садри һәм башкорт язучысы М. Кәрим октябрь аенда Чиләбе шәһәренә барып кайттылар. Алар ЧТЗның Үзәк китапханәсендә һәм Кунашак районы культура йортында үткәрелгән дуслык кичәләрендә катнаштылар, татар-башкорт китапханәсендә укучылар белән очраштылар, шәһәр телевидениесе аша һәм ЧТЗ эшчеләре алдында чыгышлар ясадылар. Троицк шәһәре китапханәсендә әдәби кичә үткәрделәр. Очрашуларда һәм кичәләрдә язучылар хәзерге татар башкорт әдәбияты турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар.

# Зыя Мансур



**Озакка сузылган авырудан соң, күренекле татар совет шагыйре Зыя Мансур иҗатының чәчәк аткан чорында, 49 яшендә арабыздан китте.**

**Бөек Ватан сугышы елларын намус белән үтеп әдәбиятка килгән талантларның берсе иде ул. Күп яшәгән карт кебек акыл иясе, бала кебек эчкерсез һәм гаҗәеп тыйнак Зыя тормышның яхшыяманын йөрәгенә якын ала, һәрнәрсәгә үзен җаваплы хис итә, дөньяга гашыйк күзләр белән карый иде. Әнә шул сыйфатларның җимеше һәм шаһите буларак, Зыяның китаплары бер-бер артлы дөньяга чыга торды: «Язгы ташкыннар», «Омтылу», «Казан җыры», «Уйланулар», «Ләйсән», «Ак розалар», «Сайланма шигырьләр» һ. б. Тирән самимилек, фәлсәфи уйлану һәм чын гражданлык тойгысы белән сугарылган бу китапларны укучылар яратып каршы алдылар.**

**Поэзиягә бөек һәм изге корал итеп караган шагыйрь-коммунист әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнарга тырышты. Доклад һәм чыгышларында, мәкалә һәм рецензияләрендә әдәбиятыбыздагы һәр уңышка чын күңелдән куана, әдәбиятны ямьсезли торган һәр күренешкә рәнҗеп һәм ачынып каршы чыга иде. Үзенә карата таләпчәнлеге һәм иҗат мәсьәләләрендә принципиальлеге белән ул каләмдәшләре арасында зур абруй казанды. Башлап язучы һәм яшь шагыйрьләрне тәрбияләү, талантлары ачылып китүгә ярдәм итү кебек мактаулы хезмәткә дә Зыя Мансур вакытын һәм көчен кызганмады.**

**Сугыш еллары сәламәтлеген җитди какшатуга карамастан, Зыя киләчәккә өмет белән карап, бөек коммунистик идеаллар белән рухланып яшәде, каләмен соңгы сулышына кадәр кулыннан төшермәде.**

**Аның якты образы каләмдәшләренең һәм мөңләгән укучыларының йөрәгендә озак сакланыр.**

*Татарстан Язучылары союзы идарәсе.*
*«Казан утлары» журналы редакциясе.*

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ 1965 ЕЛДА ЧЫККАН САННАРЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ


**Г. Тукай исемендәге премияләр турында КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы карары. № 12.**

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Булгаков А. **Язучы күпне белергә тиеш. № 3.**
Гази И. **Яңа журнал кирәк. № 3.**
Гыйззәт Б. **Бүгенге драматургиябез. № 4.**
Мәҗитов З. **Бүгенге поэзиябездә кайбер тенденцияләр. № 4.**
Нуруллин И. **Яңа урләргә таба. № 4.**
Тутаев М. **Татар әдәбиятының яңа уңышлары өчен. № 3.**
Әмир М. **Үсү юлында. № 3.**

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 20 ЕЛ

Ишморат Р. **Берлин көндәлегеннән. № 5.**
**Фронтовиклар хатлары:**
Муса Җәлил хаты. № 5.
Әхмәт Фәйзи хаты. № 5.
Фатих Кәримнең дүрт хаты. № 5.
Шәрәф Мөдәррис хаты. № 5.
Гамир Насрыйның ике хаты. № 5.
Мансур Гаязның өч хаты. № 5.
Шамил Гәрәйнең ике хаты. № 5.
Гази И. **Истә калганнарым.** Язучы Г. Кутуй турында истәлек. № 6.

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Галиев Г. **Бөгелмә имәнлеге.** Очерк. **№ 3.**
Галиев Г. **Землемер баганасы.** Очерк. **№ 6.**
Надиров И. **Тел, әдәбият һәм тарих институтына 25 ел.** Мәкалә. **№ 2.**
Надиев Р. **Борынгы шәһәрнең икенче яшьлеге.** Очерк. **№ 6.**
Рахманкулов Ш. **Татар театр сәнгатендә бер нәсел кешеләре.** Мәкалә. **№ 4.**
Шакир С. **Ялкынлы көрәшче.** Мәкалә. **№ 2.**
Әхмәдуллин А. **Көрәш һәм мәхәббәт.** Мәкалә. **№ 8.**
Ялкынлы еллар поэзиясе. **Шигырьләр. № 11.**

РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ В. И. ЛЕНИН ИСЕМЕНДӘГЕ КИТАПХАНӘСЕНӘ 100 ЕЛ

Делешова М. **Белем чишмәсе. № 1.**

МУСА АКЪЕГЕТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Гайнуллин М. **Беренче татар прозаигы. № 1.**

К. ЖАМАНАКЛЫГА 60 ЯШЬ

Жаманаклы (Решидов) К. **Диңгез буенда. Һәйкәл янында.** Шигырьләр. **№ 3.**

САЛИХ БАТТАЛГА 60 ЯШЬ

Баттал С. **Чирмешән якларында.** Шигъри роман. **№ 10.**

НУР БАЯННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Мәжитов З. **Илнең туры улы. № 6.**

Ш. БАБИЧНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Әдһәмова С. **Безнең Бабич.** Истәлек. **№ 1.**
Бөдәйли М. **Ул тормышны сөя иде. № 1.**

ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Гыйззәт Т. **Уйларым һәм хисләрем — халык белән.** Хатлар. **№ 9.**

Ә. ИСХАККА 60 ЯШЬ

Хәким С. **Мең кояшлар артына.** № 5.

Ш. МӨХӘММӘДОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Гайнуллин М. **Язучының иҗат мирасы. № 5.**
Сабитов Т. **Җизнәм турында берничә сүз. № 5.**

ЯН РАЙНИСНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Райнис Ян. **Ялкын һәм герой. Крестьян түземе. Яңадан килер. Кыюлык турында җыр. Куркыныч хөкем көне. Сынган наратлар. Римнан өстен. Сулда. Идеал. Бюрократ һәм орденнар. Партиясез политик. Шаян кызый. Хатыннар йөрәге. Романс.** Шигырьләр. З. Нури, Н. Арсланов, Ә. Баянов тәрҗемәләре. **№ 9.**

Г. ХАЛИТКА 50 ЯШЬ

Госман Х. **Тынгысыз 50 ел. № 6.**

Г. ИДЕЛЛЕГӘ 60 ЯШЬ

Минский Г. **Алтмышны каршылаганда. № 12.**

ХӘЙ ХИСМӘТУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Абилов Ш. **Хезмәттә яуланган хөрмәт. № 11.**

А. ӘХМӘТКӘ 60 ЯШЬ

Бакир Г. **Каләме очлы, хыялы бай аның. № 3.**

ДАНТЕНЫҢ ТУУЫНА 700 ЕЛ

Данте. **Илаһи комедия.** Өзекләр. **№ 12.**

## РОМАННАР, ХИКӘЯЛӘР, ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Бикчурин Ш. **Кайту.** Хикәя. № 7.
Вахит Х. **Карлыгач канат кага.** Комедия. № 7, № 8.
Гази И. **Гаепсез гаеплеләр.** Хикәя. № 2.
Гыйләҗев А. **Үги ана яфраклары.** Хикәя. № 5.
Еники Ә. **Коръәнхафиз.** Хикәя. № 6.
Маннур Ш. **Муса.** Роман. № 5, № 6, № 7, № 8, № 9, № 10, № 11.
Мөхәммәтшин Г. **Дулкыннар.** Хикәя. № 6.
Мөхәммәтшин Г. **Авылда бер...** Хикәя. № 12.
Маликова М. **Юлдашлар.** Хикәя. № 4.
Нуруллин И. **Көзге җилләр исәр алдыннан.** Хикәя. № 1.
Нуруллин И. **Фабрикант һәм шагыйрь.** Хикәя. № 4.
Рәхим Г. **Песнәк. Бөре тышчасы. Апрель. Алдауны яклау.** Лирик парчалар. № 11.
Салахов И. **Кукчәтау далаларында.** Романнан өзек. № 6.
Сабиров С. **Улым кайткач.** Хикәя. № 4.
Фәттах Н. **Артта калган юллар.** Хикәя. № 12.
Фәизов Р. **Тимер чәчәк.** Хикәя. № 4.
Хөсни Ф. **Ике агроном, бер овчарка.** Хикәя. № 8.
Хөсни Ф. **Бертуган Таһировлар.** Драма. № 12.
Хәмзин К. **Соңгы сый.** Хикәя. № 9.
Шәрифуллин М. **Көн алъяпкыч.** Хикәя. № 10.
Әпсәләмов Г. **Ак чәчәкләр.** Роман. № 1, № 2, № 3, № 4, № 5.
Әхмәт А. **Аның белән генә.** Пьесадан өзек. № 3.

## ПОЭМАЛАР, ШИГЫРЬЛӘР, БӘЕТЛӘР

Арсланов Н. **Туган илем.** Кантата. № 11.
Афзал Г. **Кышкы иртә. Урман сукмагы. Өянкеләр моңы. Ел буе. Без уйнаган көйләр.** Шигырьләр. № 2.
Афзал Г. **Ленинга карап.** Шигырь. № 4.
Афзал Г. **Моң. Онытыма хат. Әрем.** Шигырьләр. № 11.
Баянов Ә. **Мин туганмын... Онытма. Зарланыгыз кызлар. Яшен исе. Җавап бераз каты булса. Кичерер идем. Сөюеңне әйткәнең юк... Киләчәк көн. Кызым нигә елап уяндың?.. Күрешмисез тиз генә дип... Тәрәз кага берәү... Тавыш килә.** Шигырьләр. № 5.
Гайнатуллин К. **Ватан өчен.** Бәет. № 5.
Галиев Ш. **Аталы-уллы солдатлар.** Баллада. № 2.
Галиев Ш. **Бер кызга. Кара күзле бер кыз бар иде. Эт тормышы. Мәхәббәтемә. Ә кайчакта. Килмим дидем. Киңәш. Музейдагы рәсемгә.** Шигырьләр. № 3.
Галиев Ш. **Дүрткүз ник койрыксыз? Ике төрле Тәүфикъ. Энә карагы. Бәхет ачкычы. Маулихан. Уяулык. Солдатлар үткәндә. Кайнар коймаклар. Балыктан кайткач. Уң кул белән Сул кул. Сер бирми. Ясыйр. Калай бабка.** Шигырьләр. № 9.
Гатауллин Р. **Түземлелек. Без күрмибез. Кеше гашыйк. Яратам бугай. Ятлар бирде, ятлар алды. Роль биргәннәр. Исемнәр. Биеклекләр. Шикләнүең нигә. Шат күңеллеләр җыры.** Шигырьләр. № 7.
Гәрәева С. **Аяз таңым... Кызым үсә... Карамадым. Урам туфрагында. Беренче сөйгән кешем.** Шигырьләр. № 7.
Гәрәй Р. **Үзәннәрдә йөрим. Яшел чирәм кебек бәбкәләр. Ялан аяк чыгып чабарга. Болыт булсаң.** Шигырьләр. № 6.
Давыдов Ә. **Җиңү.** Шигырь. № 5.
Давыдов Ә. **Казанга чакыру. 9 май 1945 ел. Дәһшәт. Соңга калган яз... Ерак калган бер җыелыш. Иделдә. Җилдә агач яфраклары. Шәһәрдә явымлы ямьсез көн. Сина ничә яшь?.. Ничә тапкыр... Мин оныттым сине. Була шундый авыр чакларым да...** Шигырьләр. № 9.
Ерикәй Ә. **Сигез лирик шигырь.** № 3.

Зәйнашева Г. Ак челтәр уйларым. Язгы кичтә. Шигырьләр. № 11.

Камалов Г. Авылымның чишмәләре. Киттең. Шигырьләр. № 7.

Камалов Х. Туган җирдә. Эскизлар. № 6.

Латыйп Г. Озата һәм каршы ала. Атна түгел... Ай үтә, еллар үтә дә. Шигырьләр. № 11.

Маликов З. Дауларга телим. Әйтче. Упкын янында. Шаян таң җиленә. Сагыныр чак. Аңа әйтер сүз таптым. Шигырьләр. № 10.

Мансур З. Маршак. Хатын-кыз кардәшем. Бакчада. Әхмәт Исхакка, ягъни хөрмәтле мәсәлчебез Карахмәт агага 60 яшь тулу уңае белән. Шәфкать туташы. Минем адресым. Янар чәчәк. Депутат. Әйтте Хәйям... Зурлыйлар һаман Толстойларны. Җырчы арыслан. Китап киштәсе яки иске дус турында яңа җыр. Шигырьләр. № 9.

Мингалимов Р. Минем яшьлек. Иделдә. Әткәйгә. Кирәк идең. Казан аэропортында. Шигырьләр. № 10.

Мостафин К. Әни. Казан урамыннан Җәлил килә. Кеше яши. Озын чәчле сәфәрчене. Шигырьләр. № 10.

Мәҗитов З. Көнләшәм. Диңгез. Томан. Июнь кичендә. Чуртан һәм Сазан. Балык тотканда. Урын әкияте. Мәхәббәт уены. Дуска... Малай чактан бирле... Шигырьләр. № 5.

Нури З. Сүнмичә-сүрелмичә. Шигырь. № 2.

Нури З. Үлемгә-үлем. Шигырь. № 5.

Рәхим Г. Буыннар елъязмасы. Беренче күкрәү. Шигырьләр. № 7.

Садыйков М. Туган тел. Урал корычы. Шагыйрь үлми. Көзге бакчада. Кич килде. Шигырьләр. № 10.

Сирай Д. Кайберәүләрне балык кызыктыра. Көзге этюд. Сүрелми. Сандугач. Сөенечнең чиге бар микән... Күрсенми ул. Вышкалар. Шигырьләр. № 7.

Уткин Е. Яз да тамчылардан башлана. Урам тулы дәртле аваз... Мин читләтеп үттем... Тумагансың көзге айларда да... Пианист кызга. Шигырьләр. № 7.

Фәйзуллин Р. Нюанслар иле. Шигырьләр. № 11.

Фәйзуллина М. Таш, диеп, җавап биргән. Горчисны бал дип. Хат. Чыпчыклар. Песи баласы. Кыш бабай. Чебиләр. Суган турага̃нда. Казлар. Боз — сөңге. Тигәнәк. Шигырьләр. № 6.

Хуҗиев Г. Минем дә бар үз тәрәзәм. Тоеп торам сезнең сулышны. Кочаклардай булып тормышны. Өч сугышның солдаты сез. Күңел җилкәне. Шигырьләр. № 8.

Хуҗиев Г. Умырзаялар. Син тормышны җырлап киләсең. И шигърият, изге эшебез. Шигырьләр. № 4.

Хөснуллин Х. Хәтер. Авыллар керә. Болында. Тиде, диде. Шигырьләр. № 10.

Хәким С. Үрләр аша. Поэма. № 1.

Хәким С. Лирик шигырьләр. № 12.

Шәфигуллин Ф. Гомер. Карт чыршы. Шәфкать туташы. Бер уч печән. Шигырьләр. № 10.

Юныс Ә. Зур ашкыну, озын гомер турында җыр. (Бораулау мастеры М. М. Белоглазов истәлегенә багышланган шигырь.) № 7.

Әхмәтҗанов Р. Кызыл усаклар. (Лирик дәфтәрдән.) № 4.

Әхмәтҗанов Р. Лирик әкият. Каеннарны үт тә... Кар астында... Җирдә июнь. Шигырьләр. № 11.

Яшь шагыйрьләр тавышы. Ә. Гайнуллин, Ф. Яруллин, Җ. Исмәгыйлов, Ф. Хәсәнов шигырьләре. № 12.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Галиев Г. Уртак телэгебез. № 7.

Кашшаф Г. Леон Небенцаль Казанда. № 9.

Мостафин М. Барыр юлыбыз. № 8.

Рафиков С. Юл кешеләре. № 3.

Фәйзрахманова Ж. Китап бәхете. № 11.

## ҖИДЕЕЛЛЫК СӘХИФӘЛӘРЕ

Ишморатова Р. **Авылда бер көн.** Очерк. № 3.
Хәмитов М. **Биш ел үткәч.** Очерк. № 2.
Хөснимәрдәнов М. **Якташларым.** Журналист язмалары. № 1.

## ОЧЕРКЛАР

Маликов Ә. **Якташларыбыз Лена буенда.** № 10.
Мостафин Н. **Солдат язмышы.** № 5.
Мостафин Р. **Җирдә эзен калсын.** № 9.
Мостафин Ж. **Казанда үскән батыр.** № 8.
Сирай Д. **Төрле язмышлар.** № 12.
Седых Ю. **Кхмерлар илендә.** № 10.
Шәйхиев Г. **Матур туганда.** № 7.
Юныс М. **Истамбул һәм Суэеш каналы аша Ямәнгә сәяхәт.** № 4, № 5.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Галиуллин Т. **Балладаларыбыз турында.** № 2.
Мусин Ф. **Сөенеп тә, көенеп тә.** № 1.
Нуруллин И. **Әдипнең ике пьесасы.** № 8.
Халит Г. **Яңа герой ничек туды.** № 7.
Хәйри Х. **Бүгенге романнарыбызның жанр үзенчәлекләре.** № 10.
Юзиев Н. **Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән.** № 9.
Яхин А. **Начар китап ничек дөньяга килә.** № 12.

## ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Әнсәләмов Г. **Түгәрәк өстәл янына.** № 11.

## ТЕАТР

Мостафин Р. **«Бертуган Таһировлар».** № 10.
Илялова И. **Заман һәм театр.** № 11.
*Казан театрларында:*
Саликова З. Г. **Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының әдәбият бүлеге мөдире.** Мәкалә. № 4.
Ингвар И. **Качалов исемендәге рус Зур драма театрының әдәбият бүлеге мөдире.** Мәкалә. № 4.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Мостафин Р. **Алга барышлый.** № 8.
Сверигин Р. **Фатих Хөсни.** № 7.

## СӘНГАТЬ

Вәлиев Ф. **Казан татарларының ювелирлык сәнгате.** № 12.
Нигъмәтҗанов М. **Ерак чыганаклар.** № 1.

## КУЛЬТУРА ТАРИХЫННАН

Беркутов В. **Борынгы татар халык календаре.** № 2.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Госманов М., Мөхәммәдъяров Ш., Степанов Р. **Яңа ярлык.** № 8.
Ибраһимов Г. **Нәшриятка хатлар.** № 7.

Мәһдиев М. Коммунист булу — көрәшче булу. № 10.
Рәми И. Татарлар арасында революцион хәрәкәт көндәлегеннән. № 8.
Хисмәтуллин Х. Гаделлек һәм мәхәббәт поэзиясе. № 7.

## МУСА ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛАП

Лешнитцер Ф. «Моабит дәфтәре» безнең өчен дә язылган. Мәкалә. № 10.
Мостафин Р. Муса торган якларда. Фоторепортаж. № 11.
Фәйзуллина М. Ул ярдәмчел кеше иде. № 12.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Ахунов Г. «Хәсрәт дәрьясы»ның татарчасы һәм тәрҗемә практикабыз турында. № 12.
Госманов М. Мәкальләребез җыелмасының икенче томы. № 4.
Ибраһимова Ф. Яшь укучы образы. № 8.
Иделле Г. «Муса абый». № 7.
Иделле Г. Йолдызлар астында. № 8.
Малик Х. М. Җәлил турында истәлекләр. № 4.
Миннуллин Ф. Тормыш һәм характерлар дөреслеге. № 11.
Мозаффаров Р. Дин турында халык. № 2.
Насыйров Т., Белялов Г. Ленин һәм Татарстан. № 7.
Нуруллин В. «Үлемсез Акылгали». № 4.
Рафиков М. «Изге хәзрәт тарихы». № 7.
Сайганов А. Татар совет әдәбияты тарихы рус телендә. № 12.
Саттаров Г., Сәгыйтов М., Ибраһимов С. Кыйммәтле хезмәт. № 1.
Хатипов Ф. Шигырь төзелеше турында җитди хезмәт. № 7.
Хәмидуллин Ф. Кирәкле һәм файдалы китап. № 9.
Шәймөхәммәтов М. Шагыйрь белән очрашу. № 10.

## ИСТӘЛЕКЛӘР

Гыйрфанов К. С. Рәмиев турында кайбер истәлекләр. № 6.
Әдһәмова С. Галимҗан абый һәм аның белән узган көннәр турында. № 9.

## ЯҢА ТӘРҖЕМӘЛӘР

Альтман Ф. (Көньяк Африка Союзы.) Шимбә көн кич белән. Хикәя. С. Сабиров тәрҗемәсе. № 8.

Дингә каршы әкиятләр. Рус, украин, белорус, ингуш, төркмән, әзербәйҗан, башкорт, кыргыз телләреннән тәрҗемә. Тәрҗемәчесе З. Нури. № 7.

Исаев Е. Вөҗдан хөкеме. Поэмадан өзекләр. Г. Латыйп тәрҗемәсе. № 3.

Мишши С. Чуваш теле. Корыч ышаныч. Яңа чор басуы. Чәчү көннәрендә. Шигырьләр. Чувашчадан К. Латыйпов, Ә. Давыдов һәм Н. Арсланов тәрҗемәләре. № 1.

Палецкис Ю. Аббас Алиев. Яңа ел. Кояш һәм син. Җыр. Н. Арсланов тәрҗемәләре. № 8.

Петефи Ш. Кыр чәчәге. Кыш үткәндә. Мин һәм кояш. Бер нәрсәгә борчылам мин. Мактыйсың син. Король белән палач. Тимер юлда. Байрак. Шигырьләр. М. Садри тәрҗемәсе. № 4.

Топчий Л. Шигырьләр. Н. Арсланов тәрҗемәсе. № 12.

Халид Р. Идел. Бу гөлне. Күренмәс җепләр. Шигырьләр. Кырым татарлары теленнән. Н. Арсланов тәрҗемәсе. № 8.

Хатчинсон Э. (Көньяк Африка Союзы). Лиззиның гаебе. Хикәя. С. Сабиров тәрҗемәсе. № 8.

## КЫРГЫЗ ПОЭЗИЯСЕННӘН

Маликов К. **Памир юлы.** Шигырь. З. Нури тәрҗемәсе. **№ 4.**
Сатылганов Г. **Эшкә өйрән.** Шигырь. Зәки Нури тәрҗемәсе. **№ 4.**
Уметалиев Т. **Виноград.** Шигырь. Зәки Нури тәрҗемәсе. **№ 4.**

## САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Афзал Г. **Тел белән май язу.** Шигырь. **№ 1.**
Баттал С. **Мәдинәгә мәдхия. Шатландым.** Шигырьләр. **№ 5.**
Дусларча шаярулар. **8 март бәйрәме уңае белән С. Әдһәмова, Ә. Бикчәнтәева, Ә. Мөэминова, М. Фәйзуллина, С. Сөләйманова, Р. Ишморатова һәм Л. Ихсановага карата язылган юмористик** шигырьләр. **№ 3.**
Дәүли Н. **Өч кирпеч.** Парча. **№ 1.**
Нури З. **Зарланалар. Киресенчә теләкләр.** Шигырьләр. **№ 10.**
Фәттах Н. **Тамак шеште. Тәнкыйтьче.** Хикәяләр. **№ 10.**

## УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

Кутуева М. **Минем эти дә тәрәзәче иде. № 4.**
Таһирова Ф. **һәм башкалар хаты. № 2.**
**Хатлардан юллар. № 9.**
**Р. Вәзиев, Ә. Гайнанов, Ә. Фәтхиев, Х. Шәймөхәммәтов** хатлары. **№ 10.**

## ФОТОРЕПОРТАЖ

Абдуллин Ф. фоторәсемнәре күргәзмәсе.

## ЯҢА ҖЫРЛАР

Яңа ел җыры. **И. Шәмсетдинов** музыкасы, **Г. Латыйп** сүзләре. **№ 1.**
Кайтырсың бит. **С. Садыйкова** музыкасы, **М. Ногман** сүзләре. **№ 2.**
Кил, иркәм, гармунда уйнарга. **Ә. Фәттах** музыкасы, **Ә. Ерикәй** сүзләре. **№ 3.**
Синең саф мәхәббәтең. **Х. Вәлиуллин** музыкасы, **С. Хәким** сүзләре. **№ 4.**
Артиллерист Гыйлфан. **С. Садыйкова** музыкасы, **С. Хәким** сүзләре. **№ 5.**
Салават күпере. **Р. Әхмәтов** музыкасы, **И. Юзиев** сүзләре. **№ 8.**
Гөлшәһидә җыры. **Җ. Фәйзи** музыкасы, **Г. Әпсәләмов** сүзләре. **№ 9.**
Юллар. **Ә. Фәттах** музыкасы, **Ә. Ерикәй** сүзләре. **№ 10.**
**Партия.** Ә. Гайнетдинов музыкасы, З. **Нури** сүзләре. **№ 11.**

## ЯҢА КИТАПЛАР

**№ 1, № 7, № 11.**

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

**№ 1, № 2, № 3, № 5, № 6, № 7, № 8, № 9, № 10, № 11, № 12.**
**Журнал укучылар игътибарына. № 11.**

## Алдагы саннарда:

Ә. Еники. **Әйтелмәгән васыять.** Хикәя.
Г. Әпсәләмов. **Поши баласы.** Хикәя.
Г. Гобәй. **Корьән серләре.** Повесть.
Ш. Галиев. **Сөзгәк үгез маҗаралары.** Юмористик поэма.
Ә. Ерикәй, Б. Бикбай, Г. Афзал, Р. Гатауллин, К. Фәсәхов шигырьләре.
Р. Беляев, И. Дәүләтшин очерклары.
И. Нуруллин. **Г. Тукай иҗатын өйрәнү юлында.** Мәкалә.
Р. Мостафин. **М. Җәлил поэзиясе.** Мәкалә.
Ф. Әмирханның тууына 80 ел тулуга карата материаллар.
Язучыларның 1966 елга иҗат планнары.
Редакциянең сорауларына журнал укучыларының җаваплары.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 14/X-1965 ел. Басарга кул куелды 25/XI-1965 ел. ПФ 06390. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 20400 экз. Заказ Л-1322. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1965 ел.

Бэясе Цена 40 тиен коп.

Индекс 73367

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ